МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№11 / ноябрь 2013

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

Биләрне төзекләндерү.
Ф.Халиков рәсеме

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№11 (23) / ноябрь 2013

12 +

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары —
җаваплы сәркатип —
Рамил ХАННАНОВ
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Бүлек мөхәррирләре:
Илдус ЗАҺИДУЛЛИН
Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә НӘҮРҮЗОВА
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректорлар:
Дания ФӘЙЗУЛЛИНА
Алия МӨБАРӘКШИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ №С-2450
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 x 108 1/16
Басарга кул куелды: 30.10.2013
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Бәясе ирекле

Эчтәлек

ТАРИХ

4 **Идел буе болгарларында ислам хокукы үсеше.** *Алмаз Мөхәммәдиев*

10 **Татарларның Финляндия Бөек кенәзлегенә күченү сәбәпләре һәм биредәге тормышларының кайбер сәхифәләре.** *Илдус Заһидуллин*

18 **«Ватанпәрвәрлек хисе кече Ватаннан башлана».** *(Түгәрәк өстәл)*

29 **Шигърият.** *Салисә Гәрәева*

30 **Татарларның Шәрекътәге күчемсез милкенең язмышы нихәлдә?** *Азат Ахунов*

36 **Кырым һәм Идел-Урал татарлары арасындагы бәйләнешләр.** *Филүсә Арслан*

44 **Тылсымлы төбәк музее.** («Бәкер» шифаханәсенә — 80 ел) *Ленар Гобәйдуллин*

ӘДӘБИЯТ

56 **Йосыф Баласагунының «Котайткыч белек» әсәре — татар телендә.** *Рифкать Әхмәтҗанов*

66 **Гаяз Исхакый хатлары.** *Лена Гайнанова*

80 **Яралы язмышлы шагыйрә.** (Гөлшат Зәйнашеваның тууына 85 ел). *Марс Гаитов*

86 **«...Тик гармуннар гына уйчан калган, бәхилләшеп киткән егетләр...»** *Шәүкәт Галиев*

88 **Олуг шәһәрдә кунакта.** *Рухия Ахунҗанова*

96 **Тугандаш халыкларның язмышы.** *Бәтүл Җошкун*

102 **Финляндиядә татар әдәбиятының үсеше.** *Кадрия Бәдретдин*

108 **Тукай энциклопедиясенә.** *Эльмера Галимҗанова, Гөлназ Хөснетдинова*

СӘНГАТЬ

113 **Без кайчандыр Ләйлә белән Мәҗнүн идек.** (Айдар Хафизга 70 яшь) *Луара Шакирҗан*

120 **Яңа китаплар.** *Хатыйп Миңнегулов*

Безнең журналга
54132 ИНДЕКСЫ
буенча Татарстанның һәм
70275 ИНДЕКСЫ
буенча Россия төбәкләренең
һәр элемтә бүлегендә язылырга
мөмкин.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Тышлыкның 1 нче битендә — Җәмигъ мәчет манарасы (XIII гасыр) һәм Көнчыгыш төрбә (XIV гасыр). *rusplaces.ru*

Бу санда авторларның, Л.Гобәйдуллин, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Истинное наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Тарих

Дәвам итә тормыш: алмашына
Берөзлексез һаман буыннар.
...Чал вакытның кыска мизгелендә
Янып без яшәгән урын бар!

Салисә Гәрәева

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРЛАРЫНДА ИСЛАМ ХОКУКЫ ҮСЕШЕ

АЛМАЗ МӨХӘММӘДИЕВ,
тарих фәннәре кандидаты,
Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтының
өлкән фәнни хезмәткәре

ИДЕЛ БУЕНА 922 ЕЛДА ГАРӘП ИЛЧЕЛЕГЕ КИЛГӘНЧЕ ҮК, БОЛГАРЛАР ИСЛАМ ДИНЕ БЕЛӘН ТАНЫШ БУЛА. ЭТНОС БУЛАРАК БОЛГАРЛАР ХӘЗӘР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИҢ ЭРЕ КАБИЛӘ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕНЕҢ БЕРСЕН ТӘШКИЛ ИТКӘН. ШУҢА ДА КАРАМАСТАН, ХӘЗӘР КАГАНАТЫНЫҢ РӘСМИ ДИНЕ ИУДАИЗМ БУЛЫП САНАЛГАН, ХӘЗӘР ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ ЮГАРЫ ДАИРӘ ВӘКИЛЛӘРЕ, ШУЛ ИСӘПТӘН КАГАН ҮЗЕ ДӘ ЯҺҮД ДИНЕН ТОТКАН. БУ ЗУР ДӘҮЛӘТТӘ ХРИСТИАННАР ДА, МӨСЕЛМАННАР ДА КҮП БУЛГАН. БОЛГАРЛАР, КАГЫЙДӘ БУЕНЧА, ИСЛАМ ДИНЕ ТАРАФДАРЛАРЫННАН БУЛАРАК САНАЛГАН.

IX гасырда ук, Хәзәр каганатының чәчәк аткан дәверендә, биредә ислам хокукы таралган була. Болгар сәүдәгәрләре, илчеләре, түрәләренә хәзәр мөселманнары, хәтта аларның иң югары даирәдәгеләре белән еш кына очрашырга туры килгәнлеге ачыктан-ачык мәгълүм. X гасырның могтәбәр тарихчысы әл-Мәсгуди раславынча, Хәзәр илендә хәким үзе һәм аның яраннары — яһүдиләр, ә күпчелек халык, киңәшчеләр һәм хәрбиләр — барысы да мөселман булган. «Хәзерге вәзирнең исеме — Әхмәд ибне Куба. Шуның өчен Хәзәр илен мөселманнарның кулында, дип әйтергә мөмкин» [1]. Әл-Бәкри шулай ук: «Аларның мунчалары, базарлары, мәчетләре, имам һәм мөәзиннәре бар. Күпчелек хәзәрләр мөселманнар һәм христианнар», — дип язып калдырган [2].

Ибне Рустә «мөселманнар яшәгән, мәчет, имам, мөәзин һәм башлангыч мәктәпләре булган» Хабнела һәм Сарашен исемле хәзәр шәһәрләрен телгә ала. Аның бу фикерләре ибне Фазлан һәм әл-Мәсгуди язмалары белән тәңгәл килә. Алар мөселманнарның шәһәрнең көнчыгышында яшәвенә шаһит була һәм хәзәр гаскәриләренең патша резиденциясендә, ягъни шәһәрнең көнбатыш өлешендә урнашканлыгын төгәлләштерә. Ул вакытларда гаскәрнең зур өлешен, һичшиксез, мөселманнар тәшкил иткән [3].

Әл-Мәсгуди хәзәр мөселманнары заманында Хәрәзмдә яшәгәннәр, ә

анда чума эпидемиясе башлангач, Хәзәр иленә качканнар, дип яза. Бу мөселманнар көчле, чыдам, курку белмәс затлар булган, аларны халык телендә «ларшилар» («ларсилар») дип атап йөрткәннәр. Соңрак әлеге атама дәүләтнең барлык мөселманнарына да күчә. Бу категория халык каганның таянычы булган һәм ярдәм иткәннәре өчен ул аларның түбәндәге таләпләрен үтәгән: 1) мөселманнарга дини йолаларын ачыктан-ачык башкарырга, мәчетләр, мәдрәсәләр ачарга, бәйрәм намазларын укырга, азан әйтергә мөмкинлекләр биргән; 2) каган киңәшчесенең «ларши» булуы мәҗбүри булган; 3) Хәзәр каганы мөселманнар белән сугышканда, җирле мөселманнар бу сугышка катнашмый, ә башка халыклар белән сугышканда, ларшилар аңа барлык ярдәмне дә күрсәтә.

Дөрестән дә, Хәзәр иленең башкаласында мөселманнарның күп кенә мәчетләре, мәдрәсәләре булган, алар анда Коръән укырга өйрәнгән, төп җамигъ мәчетнең манарасы каган сарае тарафына караган. Мөселманнар сугыш өчен коралга һәм башка кирәк-яракларга ия булган, «һәм әгәр дә мөселманнар христианнар белән каганга каршы берләшсә, каган аларга каршы тора алмаган» [4]. Ислам дине Хәзәр каганлыгы халкында киң таралуына да карамастан, рәсми дин рәвешендә ул бары тик X гасырның азагында гына кабул ителә.

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине рәсми рәвештә X гасырның башында (922 елда) кабул ителә. Болгар җәмгыятендә ислам таралу белән, шәригать нигезендә хокук фәне дә үсә, киң халык массаларына кеше һәм җәмгыять эшчәнлеген бар яктан да җайга сала торган мөселман хокукы кануннары үтеп керә башлый. Фикъһе һәм шәригать кануннарын гамәлдә куллану буенча теоретик хезмәтләр языла. Дин кануннары һәм хокукы буенча могтәбәр галимнәр барлыкка килә.

Шул чордагы чыганакларда болгар фәкыйһләренең, казыйларының исемнәре сакланган, әйтергә кирәк, алар фәннәрнең башка тармакларында да белгеч булган. Мисал өчен болгар казые Якуб ибне Ногман әл-Болгари (XII гасыр) — Болгар тарихы турындагы китапның авторы. Әбү-Хәмид әл-Андалусиның 1134 елда Болгарда булуы һәм хәтта «Болгар тарихы» китабының авторы белән очрашуы да билгеле. Шул сәбәпле ул үзенең әсәрләрендә әлеге шәхес сүзләреннән цитаталар да китерә. Зәкәрия ибне Мөхәммәд әл-Казвини бу китапның авторы 1163 елда бакый дөньяга күчкән Әбү әл-Мәгали Габделмәлик ибне Габдулла әл-Җаваәйни белән дус булганлыгы турында яза [5].

Тагын бер танылган галим — Әбү әл-Али Хәмид ибне Идрис әл-Казый әл-Болгари (XII гасыр) [6]. Шулай ук имам казый Гамадеддин Әбүбәкер Мөхәммәди ибне әл-Хәсән ибне Мансур ән-Нәсәфи, имам фәкыйһ Әбүбәкер Мөхәммәд ибне Гомәр әл-Баззар исемнәре мәгълүм. Шәех Әхмәд әл-Быргыри (Болгари) (XII гасыр) да бөек галимнәрдән, шәригать кануннары белгечләреннән саналган [7]. «Хөкемдар» кушаматы белән болгари Ягъла ибне Исхак әл-Хәрәзминең исеме сакланып калган [8].

Кайбер болгар фәкыйһләренең исемнәрен безнең көннәргә кадәр борынгы кабер ташлары китереп җиткергән. Мәсәлән: «шәех, данлыклы имам, галим, Аллаһ колы, дәрвиш, фәкыйһ Садреддин әш-Ширвани [9]».

X гасырның азагына инде Идел буе Болгарстаны иртә феодаль дәүләткә хас барлык билгеләргә дә ия булган. Аның бердәм мәдәнияте, территориясе, үзәкләштерелгән хакимияте формалашкан. Соңгысына дәлил булып Киев Русе белән төзелгән шартнамәләр тора. Килешүләрдә болгариларның таләпләре барлык дәүләт исеменнән дә тәкъдим ителгән [10]. Бу вакытка илдәге җәмгыять һәм кеше тормышының барлык өлкәләрен дә җайга салган,

шәригать кануннарына корылган ныклы хокукый нигез дә формалаша.

Әгәр дә X гасыр — XII йөз башына Киев Русендә йола буенча килгән хокуктан, кенәзләрнең кануннар җыелмасы барлыкка килү нәтиҗәсендә, язма хокукка күчү төгәлләнеп, «Закон русский» Бөек Киев кенәзләренең төп кануны «Русская правда»га әйләнсә, Идел Болгарстанында бу мөнәсәбәттә вазгыять берникадәр башкачарак җайга салынган. X гасырда ислам динен рәсми рәвештә кабул итү белән, Идел болгарларында, борынгы төрки-татар традицияләренә нигезләнеп, йола буенча килгән хокук кануннарын акка кара белән язуның кирәге калмый. Болгар хакименең хакимиятне ныгытуы күптән әзер булган гарәп-мөселман хокукы нормалары җыелмасын дәүләт дәрәҗәсендә кертү һәм кабул итү аша булган. Борынгы Рус дәүләтенә мөнәсәбәтле, шуны искәртергә кирәк: йола буенча килгән хокукның хокук чыганагына әверелүе, христиан диненең (православие чиркәвенең) дә күтәрелүенә йогынты ясаган, әмма бу процесс акрынрак барган.

Болгар җәмгыяте һәм дәүләте үсү, ислам динен кабул итү белән борынгы төрки рун язуы урынына шул чорда дәүләт үсеше өчен кирәклерәк булган гарәп алфавиты гамәлгә керә башлый. Идел Болгарстанында борынгы төрки рун язуының киң таралган Төньяк Кавказ варианты белән бергә, биредә бик еш кына рун алфавитының төрки-орхон һәм болгар вариантлары да очраган. Рун язуы шунда ук гамәлдән төшеп калмый, иң соңгы дип табылган рун язмалары XII гасырга нисбәтле. Бу вакытта төрки рун хәрефләре тамга функциясен башкара, алар белән күп очракта ыруг, кабилә, теге яки бу һөнәр вәкилләре билгеләнгән. Әлеге мөнәсәбәттә рун тамгалары Урта Идел буенда Болгар дәүләтеннән соң барлыкка килгән төрки-татар дәүләтләре өчен дә хас, аеруча аларны Җучи Олысы, Казан ханлыгы дәверенә нисбәтле һәм аннан соңгы чыганакларда очратырга мөмкин [11].

Дәүләти һәм хокукый мөнәсәбәтләрнең ил эчендә һәм тышкы багланышларда алга таба үсеше, гомумболгар мәдәнияте, теле нигезендә берләшүгә ихтыяҗ бердәм графиканы һәм бар кешегә дә аңлаешлы язуны гамәлгә кертүне таләп иткән. Бердәм язу үзәкләштерелгән дәүләт аппаратына, урындагы түрәләргә, аеруча халык санын исәпкә алганда, салым җыйганда, финанс эшләрендә, сәүдәдә һәм халыкара мөнәсәбәтләрдә таләп ителгән. Гарәб язуын файдалана башлау белән, хокукый мөнәсәбәтләр яңа югарылыкка күтәрелгән.

Ислам дәверендәге Идел Болгарстанында дәүләти һәм шәхси җирбиләү системасы булган. Милеккә һәм матди булмаган әйберләргә хокук (яшәүгә, яшәү урынын саклауга, шәхси тормышның кагылгысызлыгына хокук) канун белән сакланган. Милеккә булган хокук милекне күчемле һәм күчемсезгә бүлеп караган. Йөкләмәле хокук (обязательственное право) сату-алу, алмашу, бүләк итү, бурычка алу, вакытлыча файдалануга алу шартнамәләре белән чикләнгән. Моңа беренче борынгы төрки дәүләтләрдән килгән хокук нормалары белән беррәттән, Идел буе болгарларының мөселман хокукы нигезләреннән хәбәрдарлыгы мөмкинлек биргән.

Идел буе болгарларының ислам динен кабул иткәнчегә кадәр үк мөселман хокукы нигезләре белән таныш булуы турында болгарларның үз риваятьләре дә сөйли. Әл-Гарнатый Бохарадан килгән мөселман сәүдәгәрләренең берсе — хокук галиме, медицинаны бик яхшы белүченең — болгарлар илендә булуы, хакимнең нык авырган хатынын һәм патшаның үзен ничек итеп дәвалаганлыгы турында сөйли. Болгар патшасы да, аның хатыны да савыга «һәм исламны кабул итәләр, ил халкы да исламны кабул итә» [12]. Моңа охшаш вакыйгаларның булуы Идел буе Болгарстанында дөньяга исламча

Әхмәт ибн Фадлан Багдад хәлифе Әл-Мөктәдирнең хатын укый.
Р.Шәмсетдинов рәсеме

карашның XII гасырга ныклы тамыр җибәрүен дәлилли.

Болгарда булган әл-Гарнатый күп кенә мәгърифәтле кешеләр, галимнәр, фәкыйһләр белән аралаша. «Болгар» сүзенең мәгънәсен «укымышлы кеше», дип аңлата, бу турыда ул «Болгар тарихы» китабыннан укый. Әлеге китапны Нишапур фәкыйһе Габделмасәли Җүвәйнидә белем алган болгар казые күчереп язган, ул ислам хокукы белгече генә түгел, ә бер үк вакытта суфый да булган [13]. «Аңлыларга бүләк һәм сирәкләрне сайлау» исемле язмасында әл-Гарнатый, Болгар шәһәрендә хөкемдар Якуб ибне Ногман авызыннан ишетеп, болгар алыплары турында сөйли [14]. Б.Дорнның фикеренчә, бу казый «Болгар тарихы» китабының авторы булган да инде [15].

Барыннан да бигрәк, әл-Гарнатый төрки-болгарлар арасындагы гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләрнең шаһиты була. Гарәп сәяхәтчесе Саксин каласында вакытта, кыйммәтле әйбер табып, аны ни эшләтергә белмәгән картка бу беләзек бәясенә «төркиләрнең колларыннан әсирләрне» сатып алырга киңәш бирә һәм: «Сиңа биредә моңа охшаш мәсьәләдә хөкем чыгарырлык галимнәр юкмыни?» — дип сорый. Карт: «Мондагы галимнәр аны безгә бир, без ни эшләтергә икәнен белербез, дип әйтәләр, ә чынбарлыкта, аны үзләштерергә телиләр», — дип җавап кайтара [16]. Чынлыкта сүз ислам хокукы нормалары турында бара: табыш аны тапкан кешенең шәхси милкенә әйләнми, әгәр дә ярты яки бер ел эчендә хуҗасы табылмаса, табышны хәйрия максатларына тотарга тәкъдим ителә.

Мөселман дәүләте һәм хокукының берникадәр идеаллаштырылган формасын Караханилар дәүләтенең хан сараенда баш министр булган Й.Баласагунинның «Котадгу билик» («Котайткыч белем» (1069-1070)) хезмәтендә очратырга мөмкин. Әсәрнең максаты XI гасырдагы мәгърифәтле төрки-мөселманнарның шул замандагы әхлак, хокук, дәүләт төзелеше һәм хокукый структурасы турында традицион күзаллауларын тасвирлау, шулай ук бу традицияләрне ачу һәм аны идарәчеләргә һәм башка дәүләт ирләренә төшендерү була. Бу очракта безнең өчен вакыйгаларны тасвирлау түгел, ә әңгәмә һәм бәхәсләр, төгәлрәге, аларның социаль-сәяси, әхлакый һәм хокукый мәсьәләләргә багышланган тематикасы мөһим.

Әлеге әсәр, Көнчыгыш Төркестанда ислам дине таралып, йөз ел үткәннән соң язылуына да карамастан, кайбер тикшерүчеләр фикеренчә, авторның иҗтимагый тормыш, әхлаклылык,

дәүләт белән идарә итү турында уйланулары тулысы белән төркиләрнең исламга кадәрге чордагы күзаллауларына нигезләнгән. Әсәргә ислам йогынтысын алар өстән-өстән генә булды дип билгели. Әйтик, «Кытай Төркестанындагы төркиләр исламнан тыш, ә бәлки аннан ныграк та, будда дине йогынтысына дучар ителгән. Хәтта XI гасырда Кытай Төркестанында бу динне тотучы кешеләр дә булган. Башка халыкларның фәлсәфи карашларында бары тик Конфуций идеяләре йогынтысы гына сизелә. Әмма, барлык йогынтылар да автор рухына хас төрки күзаллауларда «эрегән» [17]. С.Максудиның уйгыр дәүләте төркиләре турындагы бу фикере безгә Идел буе болгарларында йола хокукы ислам динен кабул иткәннән соң да озак вакытлар сакланган дип уйларга нигез бирә.

Урта гасырларда камил төрки дәүләт төзү принциплары Йосыф Баласагуни тарафыннан шактый ачык билгеләнгән. Дәүләт хокукый булырга, бары тик канунга һәм гаделлеккә генә нигезләнергә тиеш. Ил белән танылган нәселдән чыккан, әхлакый яктан намуслы хан идарә итү шарт, аның өчен югары гаделлек — канун, канунны файдалану кыры — дәүләт. Беренче чиратта ул үз хакимлеген түгел, ә канун хакимиятен күтәрергә тиеш. Дәүләт белән гадел идарә итәр өчен, аңа укый-яза белгән һәм уңган ярдәмчеләр кирәк. Хаким өчен мөһим булган төп шәхси сыйфатлар: гаделлек, тәвәккәллек, киң күңеллелек, акыллылык, юмартлык, хәбәрдарлык һәм үзенә дәүләт белән идарә итәр өчен ярдәмчеләр сайлый белү. Дәүләтнең җитәкчесе хакимиятне өч сәбәп аркасында югалтырга мөмкин: җәбер-золым кылу, урнашкан кагыйдәләрне бозу, үз вазифаларына салкын карау.

Идел Болгарстанында ислам рәсми дәүләт дине буларак игълан ителгәннән соң, өстенлекле позицияне ала. Тәңречелек дине, күзаллаулары һәм традицияләре шунда ук юкка чыкмаса да, кайбер гадәтләр элеккеге тәңречелек күзаллауларыннан кабул ителә. Тулаем алганда, Идел буе болгарлары өчен тәңречелек чоры тәгәлләнә. Дөнья төзелешенә караш алышына, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр үзгәрә, яңа гадәтләр, традицияләр, йолалар барлыкка килә. Болгарларның яшәү рәвеше һәм үз-үзләрен тотышлары шәригатьтәге юридик нормалар, принциплар һәм кагыйдәләр ярдәмендә җайга салына, аларны үтәү дөрес, Аллаһ рөхсәт иткән яшәү рәвеше кергәнлеген аңлата. Иң мөһиме — мөселман болгар ислам дине кануннарын, гадәтләрен төгәл башкарырга, хак иманны үзләштерү өчен бар көчен куярга тиеш булган.

X гасырдан башлап барлык мөселман дөньясында фәкыйһләр һәм мөтәкаллимнәрнең рәсми исламыннан суфыйчылык исламына күчү күзәтелә. Шулай да суфыйчылыкның һәр регионга һәм һәр дәвергә хас булган үзенчәлекләре булган. Монголларга кадәрге һәм Алтын Урда чорындагы Идел Болгары төрки сәнгать ядкәрләрендә суфыйчылыкның мотивларын һәм кыйммәтен өйрәнгән Г.Галиәхмәтова фикеренчә, бу регионда суфыйчылык идеяләренең үзенчәлекле рационалистик аспекты булган, аның вәкилләре һәм табынучылары мистик тәҗрибәне рационализаштеру һәм этизацияләү, турыдан-туры кичерешләрдән читләшүләре белән аерылып торган [18].

Монголларга кадәрге Көнчыгыш Европаның көньяк далаларындагы күчмәннәр — кыпчаклар арасында да акрынлап ислам хокукы тарала башлый. Г.Гобәйдуллин кыпчакларның бердәнбер язма чыганагын («Команмәҗмугасы») тикшереп, без күп кенә ислам хокукына караган гарәп терминнарын табабыз, ди. Бу XII гасыр азагына христиан дине белән бергә исламның да киң таралуы һәм мөселман фикъһе үтеп керүе турында сөйли [19].

Әмма Көнчыгыш Европа төркиләренә

монголларның һөҗүме ислам хокукы таралуны ярты гасырга тоткарлый. Монголлар үзләре белән Чыңгыз ханның кануннар җыентыгын — «Яса»ны алып киләләр. «Яса» монгол-төркиләрнең йола хокукы кодексы булса да, аның бу вакытка инде ислам динен тотучы башка күчмә халыклар — гарәпләр, болгарлар хокуклары белән шактый күп уртак яклары булган. Ярты гасыр дәвамында, Алтын Урда мөселман дәүләте булганчыга кадәр, бу ике хокукый система бергә яшәгән.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: ислам дине болгарларга Идел буе Болгар дәүләте оешканчы ук мәгълүм була. Шунысы игътибарга лаек: төрки-татар дәүләтләрендә ислам хокукы яһүд дине, тәңречелек, христиан дине һәм монголлар алып килгән «Яса»ның кануннары белән уртаклык таба. Билгеле булганча, төрки дәүләтләрдә борынгыдан бирле төрле дин, милләт вәкилләре арасында мөнәсәбәтләр толерантлык нигезенә корыла. Идел буе Болгарстанында да хәл нәкъ шулай тора. Күп кабиләләрдән торган болгар җәмгыятен бер көндә генә ислам дине белән таныштыру мөмкин булмаган. Шәригать нормаларын куллану процессы да бөтен җирдә тигез башланмый, гади халык арасында кайбер мәсьәләләр күпмедер вакыт элеккечә, йола хокукы буенча чишелә.

Гомумән алганда, Идел буе Болгарстаны мөселман цивилизациясе орбитасына кергәч, ислам хокукы халык арасында киң тарала башлый. Моңа болгарларның элеккедән килгән йола хокукы нормаларының ислам хокукы нормаларына туры килүе дә сәбәп булып тора. Күргәнебезчә, XII гасырда Идел буе Болгарстанында ислам дине һәм хокукы инде ныклы тамыр җибәрә. Болгарлар арасында шәригать кануннарына нигезләнгән могтәбәр хокук белгечләре, фәкаһәтле галимнәр барлыкка килә.

Әдәбият

1. Марджани Ш. Извлечение вестей о состоянии Казани и Булгара (Мустафад ал-ахбар фи ахвали Казан ва Булгар). Часть I. — Казань: Издательство «Фэн» АН РТ, 2005. — С.72-73.
2. Куник А. Розен В. Известия ал-Бекри и других авторов о Руси и славянах. Часть I. — Санкт-Петербург: Типография Императорской Академии наук, 1878. — С.60.
3. Хвольсон Д.А. Известия о хозарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и руссах Абу-Али Ахмеда бен Омара ибн Даста. — СПб: Типография Императорской Академии наук, 1869. — С.17, 68.
4. Марджани Ш. Извлечение вестей о состоянии Казани и Булгара… — С.73.
5. Марджани Ш. Извлечение вестей о состоянии Казани и Булгара… — С.101.
6. Измайлов И. Распространение и функционирование ислама в Волжской Болгарии // Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье: история и современность. Очерки. — Казань: Изд-во «Фэн», 2006. — С.45.
7. Марджани Ш. Извлечение вестей о состоянии Казани и Булгара… — С.101-103.
8. Измайлов И.Л. Великий волжский путь и распространение ислама в Поволжье // Великий волжский путь: История формирования и культурное наследие. Материалы III-го этапа Международной научно-практической конференции «Великий Волжский путь». Часть II. — Казань: Институт исто-рии АН РТ, 2004. — С.36.
9. Мухаметшин Д.Г., Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники города Булгара. — Казань: Татарское кн.изд-во, 1987. — С.108.
10. Казаков Е.П. О становлении государственности Волжской Болгарии IX-XI вв. // Актуальные проблемы истории государственности татарского народа. — Казань: Изд-во «Матбугат йорты», 2000. — С.25.
11. Давлетшин Г. Булгарская письменность (раннебулгарский и домонгольский периоды) // Эхо веков. — 2008. — №1. — С.26.
12. Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную Европу и Центральную Европу (1131-1153). — М.: Главная редакция восточной литературы, 1971. — С.27.
13. Шунда ук.
14. Шунда ук, С.61.
15. Шунда ук, С.87.
16. Шунда ук, С.58.
17. Садри Максуди Арсал. Тюркская история и право. Пер. с турецкого Р.Мухамметдинова. — Казань: «Фэн», 2002. — С.97.
18. Галиахметова Г.Г. Ислам в Золотой Орде: традиции религиозного опыта. — Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2007 — С.130-133.
19. Мухамадеев А.Р. Шариатская комиссия при Народном комиссариате юстиции ТАССР. — Казань: Издательство ДУМ РТ, 2009. — С.21.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин***
тәрҗемәсе

ТАТАРЛАРНЫҢ ФИНЛЯНДИЯ БӨЕК КЕНӘЗЛЕГЕНӘ КҮЧЕНҮ СӘБӘПЛӘРЕ ҺӘМ БИРЕДӘГЕ ТОРМЫШЛАРЫНЫҢ КАЙБЕР СӘХИФӘЛӘРЕ

ИЛДУС ЗАҺИДУЛЛИН,
тарих фәннәре докторы, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының урта гасырлар тарих бүлеге мөдире

СЕМБЕР ҺӘМ ТҮБӘН НОВГОРОД ГУБЕРНАЛАРЫ АВЫЛЛАРЫНДА КӨН КҮРҮЧЕ ТАТАРЛАРНЫҢ ХУҖАЛЫГЫ, ЯШӘҮ РӘВЕШЕ, МЕНТАЛИТЕТЫ КҮРШЕ ГУБЕРНАЛАРДАГЫ МӨСЕЛМАННАРНЫКЫННАН АЕРЫЛМАГАН.

Аларның хокукый хәле XVIII гасыр башында, дәүләт сәясәте нәтиҗәсендә, кискен үзгәреш кичергән. 1718 елны моңарчы хәрби хезмәт башкарган татар морзаларының һәм йомышлы татарларның дәүләт алдындагы йөкләмәсе Россия флотына төзү материаллары әзерләү өчен урман кисү һәм чыгару, ягъни лашман хезмәте белән алыштырылган. 1724 елда император Пётр I татар морзаларын һәм йомышлы татарларны, хөкүмәт биргән җирләренә милек хокукын саклаган хәлдә, җан башыннан салым түләргә тиешле дәүләт крестьяннары сословиесенә күчергән.

Идел-Урал төбәгендә зур суммаларда алыш-биреш итү һәм гильдия сәүдәгәре булып язылу Казан һәм Вятка губерналары мөселманнарына, аларның Оренбург һәм Себер губерналарына күченгән нәсел дәвамчыларына хас булган. Этнографлар аларны «казан татарлары» субэтносы дип атыйлар. Алар, касыйм татарлары белән берлектә, Урта Азия һәм казах даласында сәүдә итүдә үз монополияләрен урнаштырганнар.

Сембер һәм Түбән Новгород губерналарында яшәгән йомышлы татарлар исә терлекчелек, игенчелек белән шөгыльләнгән, лашман хезмәтен үтәгән. Алар арасыннан эре сәүдәгәрләр чыкканлыгы билгеле түгел. Киресенчә, тирә-як авыллардагы рус, чуваш һәм башка халыклардан, алпавытлардан тире, йон һәм башка авыл хуҗалыгы товарларын аерым-аерым түгел, ә төркемләп, артель ясап җыйганнар һәм кайвакытта үзләре үк беренчел эшкәртеп сатканнар [1].

XIX гасырның икенче яртысында Идел буйларында модернизация көчәйгәч, йомышлы татарлардан чыккан Акчуриннар, Алиевлар, казна заказы буенча солдатларга шинель тегү өчен, заманча җиһазландырылган каты йон тукыма җитештерүче капиталистик предприятиеләрен аякка бастырганнар, бу шөгыльдә зур уңышларга ирешкәннәр. Ләкин андыйлар күп булмаган.

XIX гасырның беренче яртысында, татар сәүдәгәрләреннән һәм азсанлы татар дворяннарыннан кала, лашманнар рус мохитендә үз урынын тапкан мөселманнар катламы саналган. Биредә аларның чит мохиткә җайлаша алуында төп рольне уйнаган берничә факторны билгеләп үтәр идем.

1) Сембер төбәгенә йомышлы татарларны күчерү хакимият контролендә тормышка ашырыла. Яңа урында алар руслар һәм башка халыклар белән күршеләр булып көн итә башлый, хуҗалык эшләре буенча, базарларда рус телендә аралашу гадәти күренешкә әверелә. Оренбург, Уфа, Казан, Вятка губерналарында исә тулысы белән татарлардан торган янәшә волостьлар урнашкан. Биредә көн итүче төрле милләт вәкилләренең үзара аралашу теле функциясен татар теле үтәгән. Сембер (Буа өязеннән кала), Түбән Новгород губерналарында яшәгән мөселманнар, өязләрдә азчылыкны тәшкил иткәнгә күрә, көнкүреш ихтыяҗларын үтәү өчен рус телен үзләштерергә тиеш булган.

2) 1821 елда Сембер губернасында лашман хезмәтен үтәүче 27 550 ир-ат (1856 елда – 29 966), Түбән Новгород губернасында 8 631 ир-ат (1856 елда – 9 427) саналган [2]. Якын-тирәдә кораблар төзерлек, яхшы агач материалы бирерлек урманнар киселеп беткәч, алар бу авыр һәм еш кына гарипләнүгә сәбәп булган дәүләт йөкләмәсен туган авылларыннан берничә йөз чакрым читтә үтәргә мәҗбүр булган. Шулай итеп, ел саен яки берничә елга бер тапкыр октябрь-ноябрь айларында, артельләргә берләшеп, хезмәт куйганнар. Урман кисү йөкләмәсе 1859 елга кадәр дәвам иткән. Күрәбез, XIX гасырның беренче яртысында Урта Идел буенда яшәгән крестьяннар арасында лашманнар, бу төбәктә читкә китеп эшләү вакытлы паспорт алу кыенлыгы белән чикләнгән бер вакытта, хөкүмәт йөкләмәсен үтәп, руслар һәм башка халыклар белән даими аралашуда булган. Нәтиҗәдә, туган авылларыннан читкә китеп эшли алырлык, чит мохиткә ияләнгән урман кисүче эшчеләр артельләре, азмы-күпме русча сөйләшә белгән игенчеләр катламы формалашкан.

Замандашлары 1860 елда лашман хезмәтен башкаручы татар, рус һәм чувашларның башка милләттәшләренә караганда зиһенлерәк, көчлерәк, тормышлары яхшырак булуын язып калдырган [3].

3) Рус шәһәрләренә барып урнашуга төп этәргечне илнең иң зур ярминкәсендә (1816 елдан Түбән Новгородта август уртасында башланып, бер ай дәвам иткән) катнашу биргән. XIX гасырның беренче яртысында барлык йөк ташу, ярминкәдәге балаганнарда хезмәт күрсәтү Сембер губернасыннан килгән татарлар кулында булган.

Күрәсең, ярминкәне оештыручыларга тырыш, авыр эшкә чыдам, эчми-тартмый торган эшчеләр кулай тоелган. Мондый үзара

1. Липинский. Материалы для географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба. – СПб., 1868. – Ч1. – С.330.

2. Файзрахманов И.З. Лашманы // Научный Татарстан. – 2012. – №3. – С.88.

файдалы хезмәттәшлек дәвамлы һәм кануни нигезгә корылган. Әйтик, 1821 елда ярминкәнең ат сараена төрле эшләр башкарырга вакытлыча 40 татар ялланган була. Ат җигеп, йөк ташучыларның исемлеге Түбән Новгород өлкәсе архивында саклана. Алар — Кучкай Пожары (Кочко-Пожарки), Сафаҗай (Собачий Остров), Кече һәм Олы Рбишча (Малое и Большое Рыбушкино), Краснай (Красный Остров), Суыксу (Ключищи) һәм башка авыл игенчеләре. Август аенда аларның бер өлеше чирләп киткәч, Ярминкә комитеты, шушы авыл җәмгыятьләре белән алдан төзелгән килешүләр нигезендә, кирәкле санда өстәмә эшчеләр китерткән. Вакытлы эшчеләр торак урыны белән тәэмин ителмәгән, шунлыктан август-сентябрь айларында ачык һавада төн кунарга мәҗбүр булганнар [4].

Безнең уебызча, бер-ике сезон дәвамында эшне җиренә җиткереп башкарган йөк ташучы татарлар читтәге төбәкләрдән, бигрәк тә Мәскәү, Санкт-Петербург кебек зур шәһәрләрдән килгән приказчиклар, сәүдәгәрләр, башка алып-сатарлар белән яхшы мөнәсәбәтләр урнаштырып, эш эзләп, Россиянең үзәк һәм төньяк-көнбатыш губерналарына юнәлгәннәр. 1851 елда «Петербург-Мәскәү» тимер юлы ачылу, 1862 елда тимер юлның Мәскәүдән Түбән Новгородка килеп җитүе аларның юлда булу вакытын һәм чыгымнарын киметкән.

4) Яңа урыннарга күченеп, игенчелек белән шөгыльләнү элекке йомышлы татарлар арасында киң җәелмәгән. Шуңа күрә аларның авыллары зурлыгы ягыннан башка мөселман торак пунктларыннан аерылып торган, биредә 2, 3, 4, 5 һәм аннан да күбрәк мәчетләр булу гадәти күренешкә әверелгән. 1910-1911 елларда Кормыш өязе игенче хуҗалыкларында җан исәбен алу мәгълүматларында татарлардан торган Чәмбеле волостена караган Кече Рбишча авылында — 3 983, Олы Рбишча — 1 991, Медәнәдә — 4 558, Чәмбеледә 4 713 кеше яшәгәнлеге теркәлгән. Алты татар авылын берләштергән Петряки волостендагы торак пунктлары тагын да зуррак булган. Әйтик, Сафаҗайда — 5 694, Питрәксәдә — 5 202, Краснайда 4 377 кеше көн күргән, Яңа Мучалы авылында 841 хуҗалык исәпләнгән [5]. Зур авыллар феномены әле яхшылап өйрәнелмәгән. Ләкин шунысын тәгаен әйтергә мөмкин: зур авылларда яшәгән халык үзен зур көч итеп тойган. Башка төбәкләрдәге крестьяннарның протест чыгышларын өйрәнү шуны күрсәтә: зур авыл җәмгыятьләре хакимияткә каршы кыюрак чыгыш ясаган.

Шунысы кызык: XIX гасырның икенче яртысында — XX йөз башында Түбән Новгород һәм Сембер губернасы татарлары арасында урбанизация процесслары бу төбәктәге шәһәрләргә түгел, ә илнең үзәк һәм төньяк-көнбатыш регионнарына юнәлгән була. Моны статистика мәгълүматлары раслый. 1897 елда Курмыш шәһәрендә 4 ир-ат татар, Сингәләйдә — 30, Сызраньдә 200 чамасы татар яшәгәнлеге билгеле [6]. 1912 елда Корсуньда, Курмышта урнашып яшәгән татарлар булмый, Сингәләйдә аларның саны — 71, Сызраньдә — 653кә, Алатырьдә 32 кешегә җитә [7]. 1910 елда Петряки волостеннан — 249, ә Чәмбеле волостеннан 126 татар чит губерна шәһәрләрендә эшләгән [8].

5) Инде 1820 елларда Петербургта Сембер һәм Түбән Новгород

3. Липинский. Материалы для географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба. — СПб., 1868. — Ч1. — С.272.

4. Сенюткина О.Н., Загидуллин И.К. Нижегородская ярмарочная мечеть — центр общения российских и зарубежных мусульман (XIX — начало XX вв.). — Нижний Новгород, 2006. — С.48-50.

5. Подворная перепись Симбирской губернии 1910-1911 гг. Вып.6. Курмышский уезд. — Симбирск, 1914. —С.126-127.

губерналарыннан килгән мөселманнарның зур булмаган общинасы оеша. Алар 1822 елда мәхәллә имамы итеп Кормыш өязе ахуны улын — булачак мөфти Габделвахит Сөләймановны раслатуга ирешәләр. Мәхәллә муллага торырга арендага фатир ала, бирегә җомга намазларына җыела башлый. 1869 елда беренче мәхәллә мулласы Мөхәммәдәмин Хантемиров, канун бозып никах укуда гаепләнеп, эштән алынгач, аның урынына шәһәргә Сергач өязе Овечий Овраг авылы мулласы Мөхәммәтшакир Юнысов китерелә.

1870 елда башкалада икенче мәхәлләне Касыйм шәһәре һәм өязеннән күченеп килгән мөселманнар оештыра — имам итеп Гатаулла Баязитов сайлана.

Галимнәр 1860 елларга кадәр шәһәргә күбрәк хәлле крестьяннар күченгән, аннан соңгы елларда җир азлыктан, атсызлыктан, авыр тормыштан интеккән ярлы кешеләр эш эзләп килгән, дигән фикердә тора. XIX гасырның беренче яртысында Петербургка килеп чыккан Сембер һәм Түбән Новгород игенчеләренең беренче буыны кырык тартмачы яки төрле махсус квалификация таләп итми торган эшләргә — урам себерүче, ат караучы һ.б. булып — ялланган. 1869 елны Петербургта җан исәбен алу мәгълүматлары буенча, татарлар 1377 ир-ат һәм 208 хатын-кыз булган. Ягъни күпчелеге килеп, вакытлыча эшләгән. Аларның 11% — хәрбиләр, 77% — крестьяннар. Араларында шулай ук 25 купец (23 ир-ат), 37 мещан булган. Татарларның зур группалары шәхси йортларда (441 кеше), Кышкы сарайда (40) хезмәтче, урам себерүче (78), каравылчы (10) булган, 357 кеше, йөреп, вак-төяк белән сәүдә иткән [9].

Чит шәһәргә күченүдә һәм ияләшүдә туган-тумачалык һәм землячество принциплары мөһим роль уйнаган. Татарлар туганнарын үз яннарына алдырган, дини һәм гаилә бәйрәмнәрен бергә үткәргән, артельдә яки бизнеста бергә эшләгән, туган авыллары турында кайгыртып яшәгән. Әйтик, Кормыш өязе Чәмбеле авылыннан чыккан эшмәкәрләр 1912 елда Петербургта туган авылларына мәгърифәт тарату җәмгыяте оештыралар һәм беренче оештыру җыелышында ук 1 мең сум иганә акчасы җыялар [10].

Россиядә крестьяннарга дәүләт салымнары күләмен игенче хуҗалыкларның табышын исәпкә алмыйча, хакимияткә күпме кирәк, шулай билгеләү, азҗирлелек, еш кабатлана торган корылык еллары, мал-туарның санын киметкән төрле авырулар һ.б. авыл кешеләре арасында игенчелек белән шөгыльләнеп кенә тормыш шартларын яхшыртып булмый, дигән фикерне ныгыткан. Яңа урынга барып урнашкан татар кешесе, җай булу белән, беренче чиратта, якын туганын яки авылдашын үз янына алдырган. Шәһәр шартларында шулай бер нәсел яки бер авыл кешеләрен берләштергән артельләр гадәти күренеш булган. Шулай итеп, алар чит җирдә яннарына ышанычлы хезмәттәшләр туплаган, бергә яки күршеләр булып тормыш итәргә тырышкан һәм үзләренә күрә туган як мохитен тудырган.

6) Мәгълүм булганча, 1808-1809 елгы швед-рус сугышы нәтиҗәләре буенча, Финляндия Россиягә бирелә. Россия императоры Финляндия Бөек кенәзлегенең (1809-1918) бөек кенәзе дип игълан ителә, төбәк белән ул билгеләгән генерал-губернатор идарә

6. Первая всеобщая перепись населения в Российской империи 1897 года. — Т.39. Симбирская губерния. — СПб., 1904. — С.162-171.

7. РГИА, ф.821, оп.133, д.510, л.28.

8. Подворная перепись Симбирской губернии 1910-1911 гг. Вып.6. Курмышский уезд. — Симбирск, 1914. — С.126-127.

9. Загидуллин И.К. Исламские институты в Российской империи: Мусульманская община в Санкт-Петербурге. XVIII — начало XX вв. — Казань, 2003. — С.35-54; 82-94.

10. Мир ислама. — 1912. — Т.1. — №3. — С.463 .

итә. 1811 елда Финляндия Бөек кенәзлегенә Выборг губернасы өстәлә. Россия империясендә Финляндия күп кенә өстенлекләрдән, автономиядән файдалана: аның үз таможнясы була, халыктан җыелган салымнар Россия казнасына тапшырылмый, 1860-1870 елларда Финляндиядә мөстәкыйль акча системасы кертелә, 1863 елны швед һәм фин телләре тигез хокуклы дип игълан ителә. Халкы рус армиясендә хезмәт итүдән һәм хәрби чыгымнардан азат булган Финляндиядә 1820 еллардан икътисад үсеше башлана, бу өлкәдә Россия белән сәүдә һәм хуҗалык мөнәсәбәтләре мөһим роль уйный. 1870 елларда Санкт-Петербургтан Финляндия шәһәрләренә тимер юл сузылгач, икътисади элемтәләр тагын да ныгый.

Финляндия Бөек кенәзлеге җирле халыкның тормыш рәвеше, илдәге коммуникацияләр, мәдәният ягыннан Россиядән аерылып торган. XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында Финляндиядәге яшәү рәвешенә югары бәя бирелә. Финнар мәдәният, мәгариф вә сәнгатьтә бик тәрәккый иткәннәр, дип, татарлар аларны алдынгы милләт санаганнар [11]. Әйтик, 1909 елда Финляндиянең Выборг губернасына сәяхәт кылган бер милләттәшебез «Шура» журналында болай дип яза: «Мин йөргән җирләрне типичный Финляндия диеп булмый… Шунлыктан бу губерна халкына эчке финнар кырын күз илән карыйлар, бозылганга хисап итәләр… Бөтен халык газета вә журнал укый! Бунда һичбер хата юк. Мин зур авылда тордым. Газетасыз берәүне дә күрмәдем. Иң ярлы арендатор Йоханн бер газета, җир эшенә даир бер журнал ала иде… Зурлар өчен авылларда халык академиясе бар. Крестьянны һәртөрле җир машиналары вә орлыклар илән таныштыралар. Җир эшендә фән вә тәҗрибә кирәкле тапкан аслан хатларны фин крестьяннары бу лекцияләрдә ишетәләр, күрәләр һәм үзләре шулай эшләргә керешәләр» [12].

Күрәбез, Россиядән караганда, Финляндия Бөек кенәзлеге Көнбатыш Европа иле буларак кабул ителгән һәм Россиягә караганда да алдынгырак төбәк булып күренгән.

ФИНЛЯНДИЯ БӨЕК КЕНӘЗЛЕГЕНДӘ ТАТАР ХӘРБИЛӘРЕ ҺӘМ ВАК СӘҮДӘГӘРЛӘР

Беренче татарлар Финляндия Бөек кенәзлегенә хәрби хезмәт үтәгәндә киләләр. Билгеле булганча, Балтыйк флотының портлары һәм хәрби базалары булып Кронштадт, Ревель (хәзерге Таллин), Свеаборг (Суоменлинна), Либава (Лиепа) торган. Балтыйк флотында хезмәт итүче татарлар, әлбәттә, бу портларда булганнар.

Кавказ сугышы вакытында хөкүмәт, татар рекрутларын хәрби хезмәткә билгеләгәндә, аларның дини һәм милли үзенчәлекләрен исәпкә алып эш йөрткән. Әйтик, Кавказ сугышы барганда, 1833 елдан аларны Аерым Кавказ корпусына билгеләми башлаганнар, ә төрле җинаять җаваплылыгына тартылган Казан, Сембер һәм Оренбург губерналары татарларын каторгага Себергә түгел, ә Финляндиядәге крепостьларга арестант роталарына хезмәткә җибәргәннәр [13]. Бу сәясәт 1860 елларның икенче яртысында империядә хәрби округлар оештырылганчы яисә 1874 елгы хәрби

11. Ф.К. Финляндиядә мөселманнар // Русия сәүдәсе журналы. — 1917. — №10. — Б.71.

12. Яров М. Финляндия хатиратлы // Шура. — 1909. — №22. — Б.700-702.

хезмәт турындагы яңа устав кабул ителгәнче дәвам иткән дип фаразларга була. Әйтик, 1860 елларда Свеоборг кирмәнендә кеше талаган яки кеше үтергән өчен каторгага хөкем ителгән татарларның хәрби хезмәттә булганлыгы төгәл билгеле. 1864 елда аларга кирмән коменданты, уңай характеристика биреп, үзләрен тәртипле тоталар, бернинди начар гамәлләр кылганнары юк, хәрби мулла бер казах зимагурын мөселман диненә күндерде, дип хәбәр итә [14].

Финляндиядә хәрби хезмәттә булган мулла кирмәннәрдәге дин кардәшләренең дини ихтыяҗларын үтәгән. Аны хәрбиләр үз арасыннан сайлап куйган. Кенәзлекнең башкаласы булган Гельсингфорс янындагы утрауларда урнашкан Свеоборг кирмәнендәге хәрби муллага, хатыннары ияреп килгән сотдат яки җинаятьче гаиләләрендә туган балаларны, үлем-китем, аерылуларны теркәү өчен, 1836 елда беренче тапкыр метрикә кенәгәсе җибәрелгән. 1837 елда бирелә мулла булып 6 нчы Ластов экипажында хезмәт итүче Бикчәнтәй Бикбов торган. Хезмәттәше Гыйззәтулла Тимергалин аны 1841 елда вакытлыча алыштырган була. Бикчәнтәй Бикбов исә 1850 елларга кадәр хәрби мулла вазифаларын башкарган [15].

4 нче номерлы Финляндия линейный батальоны рядовое, Гельсингфорс шәһәрендә имам вазифаларын башкаручы Әхмәтсафа Бакировның 1858 елның 25 августында Мәхкамәи Шәргыя Ырынбургиягә (Диния нәзарәте) язган гаризасында үзенә, Гельсингфорс, Свеаборг һәм башка кирмәннәргә урнашкан 58 мөселман солдаты һәм матросының 1857 елның декабрендә кабул иткән сайлау карары нигезендә, аңа кадәр хәрби имам булган Бикбов һәм башкалар кебек үк, Уфага килеп имтихан бирергә рөхсәт сорый [16]. Уфага килеп, 1859 елның 18 мартында имтихан тапшыргач, ул, императорның 1860 нчы ел 26 февраль Указы нигезендә, хәрби мулла итеп билгеләнә, ә 1864 елда Финляндия хәрби округы оешкач, 34 яшьлек имам хәрби округ мулласына, соңрак хәрби ахунга әйләнә.

Выборг кирмәнендәге инвалид һәм этап командасында хәрби хезмәттә булган мөселманнарның имамы Йосыф Субукаев исеменә Уфа шәһәреннән беренче тапкыр метрикә кенәгәсе 1843 елда җибәрелгән [17]. 1860 елларда Выборг кирмәнендә булган 40 хәрби, комендант белән килешеп, намаз уку өчен аерым бүлмә алуга ирешә. 1869 елны Финляндия хәрби округы ахуны Бакиров, хәрби диндәшләрен яклап, Выборг комендантына имам вазифасын башкаручы солдатны хәрби йөкләмәләр үтәүдән азат итүләрен сорагач, округ җитәкчелеге, гыйбадәтханә бүлмәсен ябып, мәсьәләне «хәл итеп» куя [18].

Әлбәттә, кирмәннәрдә, казармаларда яшәгән түбән чиннарга җирле халык белән аралашу мөмкинлеге зур булмагандыр. Шулай да алар арасында гаилә корып яшәүчеләр хакында мәгълүматлар бар. Әйтик, 1861 елда Мәхкамәи Шәргыя Ырынбургиядән Петербургтагы Аерым Гвардия корпусы имамы Х.Халитовка, Хиссельдорф имамы Әхмәтсафа Бакировка метрикә кенәгәләре җибәрелү моңа дәлил булып тора.

Гомумән алганда, Финляндия хәрби округларында татар

13. Свод военных постановлений. Изд. 1838 г., ч.2, кн.1, ст.271, 272, 288.

14. Башкортстан Республикасының Үзәк тарих архивы, фонд И-295, 4 нче тавирлама, архив эше №6037, 2-нче бит.

15. Viaporin ja Viipurin imaamien tataarinkieliset metrikkairjat 1836-1850. Suomentanut ja toimittanut Harri Halen. — Helsinki, 2012. — S.5-11.

16. Башкортстан Республикасының Үзәк тарих архивы, фонд И-295, 4 нче тавирлама, архив эше №3263,1-нче бит.

17. Viaporin ja Viipurin imaamien tataarinkieliset metrikkairjat 1836-1850. Suomentanut ja toimittanut Harri Halen. — Helsinki, 2012. — S.21.

хәрбиләре аз булган (1904 елда — җәмгысе 150 кеше) [19], аларның саны Беренче Бөтендөнья сугышы елларында арта.

Бер үк вакытта Петербургка килгән татарлар тирә-як шәһәрләргә дә барып урнашкан. Ни өчен бирегә күчеп килүчеләрнең күпчелеге сәүдә белән шөгыльләнә башлаган? Күрәсең, финнарның тормыш үзенчәлекләре, зур байлар булмау хуҗалыкларда хезмәтчеләргә ихтыяҗны нык киметкән. Икенче сәбәп — дачага килүчеләр рус эшчесен ялласа, җирле халык аны ничек тә Питерга кайтып китәргә мәҗбүр иткән [20]. Күченүче татарлар, күрәсең, үзләренең Урта Идел эшмәкәрләре белән элемтәләрен кулланып, Финляндиядә сәүдә өлкәсендә үз урыннарын табуга ирешкән һәм, яннарына туганнарын яки авылдашларын алдырып, чит-ятлар арасында бердәм колония булып, туган якларындагы сыман тормыш корып яшәргә омтылган. Гельсингфорс мәхәлләсендә 1911 елда Сергач өязе Аткул авылыннан чакырып китертелгән Сәмигулла Садретдинов Нюланд губернаторына, мөселманнар тарафыннан сайлану уңаеннан, Финляндиядәге барча мөселманнарның имамы итеп билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән. Бу статуска билгеләү хокукы Финляндия генерал-губернаторы кулында булганлыктан, мәсьәләне хәл итү тоткарланган. Күрәсең, татарлар канун буенча таләп ителгән ислам дини җәмгыятендә кимендә 200 ир-ат булырга тиеш дигән кагыйдәне үтәргә һәм шул юл белән рәсми рәвештә мәхәллә оештырырга омтылганнар. Архив документлары буенча Сәмигулла Садретдиновның язмышын ачыклап булмаса да, аның мулла итеп расланмаганлыгын беләбез. Сәбәбе — Финляндия Бөек кенәзлеге кануннарында мөселман мәхәлләсен теркәү шартлары һәм тәртибе язылмау — димәк, мондый гамәлне кылу мөмкин булмау.

Вәлиәхмәт Хәким (1882-1970)

1915 елдан Гельсингфорста рәсми билгеләнмәгән имам һәм татар мәктәбенең (укулар иртәнге сәгать 8дән сәгать 3кә кадәр барган, Россиядән чакыртылган мөгаллимә кечкенә балаларга дәрес биргән) мөдире булып Сембер губернасы Олы Рбишча авылыннан Мәскәүдә Әсәдуллаев мәктәбендә мөгаллимлек иткән Вәлиәхмәт Хәкимов торган [21]. Аны 1914 елда, бирედә мулла вазифаларын башкарган Кадыйр исемле кеше үлгәч, Актүк авылыннан килгән сәүдәгәрләр махсус чакырган [22].

Татарларның 1915 елда Гельсингфорста хәйрия җәмгыятен теркәүләре аларга дәүләт алдында үз мәнфәгатьләрен яклау өчен кирәк булган, күрәсең. Чөнки әлеге иҗтимагый оешмалар, гадәттә, төрле төбәкләрдән килеп урнашкан яки вакытлыча эшләүче дин кардәшләренә аралашуны, кыен тормыш шартларында яшәүчеләрен нинди дер күләмдә матди ярдәм белән тәэмин итү өчен төзелә. Мондый ихтыяҗ Гельсингфорста көн күрүче татарларда булмаган, чөнки туган-тумачалар арасындагы үзара ярдәмләшү

18. Башкортстан Республикасының Үзәк тарих архивы, фонд И-295, 4 нче тавирлама, архив эше №3263, 5-нче бит.

19. Россия дәүләт тарих архивы, фонд 821, 8-нче тасвирлама,1064-нче архив эше, 127-нче бит.

20. Яров М. Финляндия хатиралы // Шура. — 1909. — №22. — Б.702.

21. Солдат Габдерәүф Вәлидев. 25-27 октябрьдә булган Областной съездымызның карарлары. Бөтен Финляндия мөселман солдатлары өчен хәрби ахун сайлау //

традицияләре ниндидер рәсми оешма таләп итмәгән, барлыкка килгән мәсьәләләрне алар, туган авыллары мәхәлләсендәге сыман, тиз арада хәл иткән, шул сәбәпле беренче вакытта бу иҗтимагый оешма тулы мәгънәсендә хәйрия җәмгыяте буларак эшләп китә алмаган, ул күбрәк дини-мәдәни оешма функциясен үтәгән, мулла, мәчет, балаларны укыту өчен мәктәп турында кайгырткан.

Фатих Кәрими, 1917 елны Финляндиягә килгәч, Гельсингфорста 25тән артык мөселман сәүдә фирмасы булганын күргән, күбесенең чыгышы Түбән Новгород губернасы авылларыннан икәнлеген ачыклаган. Таммерфорст шәһәрендә тупланган татар общинасы, нигездә, Актүк авылы кешеләреннән торган. Алар, туган авылларындагы кебек мәктәп ачып, балалар укыткан, мәчет тоткан. Галимҗан хәзрәт Баруди шәкерте Галлә Шәмсетдинев имамлык иткән. Беренче Бөтендөнья сугышы башланып, сәүдә эшләре начарайгач, күпчелек сәүдәгәрләр вакытлыча, сугыш беткәч кире кайту уе белән, Петроградтан ике генә сәгатьлек җирдә урнашкан Териоки шәһәренә күченгән. Яңа урында да мәчет һәм мәктәп ачып яшәгәннәр, җәмгыяте хәйрия оештыганнар, анда җыелган акчаны туган авылларына да җибәреп торганнар. 1917 елда аларны барып күргән Фатих Кәрими Актүк авылы кешеләре турында, сокланып, болай дип яза: «…авылларын онытмыйлар, анда уку вә хәйрат юлына һәрвакыт иганә җибәрә торалар, җәмгыяте хәйрияләренең 10 мең сум кадәр суммалары бар, иганә вә хәйрат эшләренең башында шушы борадәран Җәмалетдиневләр тора вә гомумиять илә Финляндиядә торучы бу мөселман сәүдәгәрләре үзара бик тату, иттихад (берләшү) вә иттифак белән киченәләр, бер-берсенә ярдәм вә могавиндә (ярдәмче) булыналар икән» [23].

Сугыш башлангач, элекке Кронштадт хәрби мулласы Галиәкбәр Алтынбаев 1915 елда Финляндия хәрби округы ахуны итеп билгеләнә һәм 1917 ел Февраль революциясеннән соң солдатлар тарафыннан эшеннән алына. 1917 елның 25-27 октябрендә булган Финляндия мөселман солдатлары съездында Гельсингфорста имам вазифаларын башкаручы Вәлиәхмәт Хәкимов Финляндия мөселман солдатлары һәм матросларының ахуны итеп сайлана [24]. Шулай итеп солдатлар үзләренең дини автономияләрен булдырырга тырышкан.

1917 елда хәрбиләрнең шәһәр татарлары белән аралашуы көчәя. Сәүдәгәрләр җыеп биргән акчага Гельсингфорста татар китапханәсе ачыла, бирегә русча, татарча газета-журналлар алдырыла башлый. Гельсингфорс мөселман хәрби комитеты шәһәрнең Николаевская урамындагы 18 нче йортта урнашкан була. Китапханә дә шушы бинада булган дип фараз кыла алабыз.

Россиядә совет хакимияте урнашкач һәм 1918 елда Финляндия Бөек кенәзлеге мөстәкыйль дәүләт дип игълан ителгәч, күченеп килү шартлары һәм мөмкинлекләре үзгәрә. Ләкин элеккечә үк мигрантларның юлга чыгу сәбәпләре булып туган яктагы тормыш авырлыгыннан котылып яки гаилә башлыгы белән кушылып, бергә тормыш итү кала, дисәк, ялгыш булмас. Совет елларында татарларның Финляндиягә күченү тарихы — махсус эзләнүләрне сорый торган тема… ■

Гельсингфорс хәбәрләре (КФУ, Сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлеге, №79 Т (кульъязма)).

22. Сенюткина О. Иманы өчен шәһит киткән // Идел. — 2013. — №9. — Б.60.

23. Ф.К. Финляндиядә мөселманнар // Русия сәүдәсе журналы. — 1917. — №10. — Б.70-71.

24. Солдат Габдерәүф Вәлидев. Военный лазарет // Гельсингфорс мөхбире. — 1917. — №1. — 10 ноябрь.

«ВАТАНПӘРВӘРЛЕК ХИСЕ КЕЧЕ ВАТАННАН БАШЛАНА»

(түгәрәк өстәл)

РОССИЯ ТАРИХЫ БУЕНЧА УРТА МӘКТӘПЛӘР ӨЧЕН «КАМИЛ РУС ТЕЛЕНДӘ, ЭЧКЕ КАРШЫЛЫКЛАРЫ ҺӘМ ИКЕ ЯКЛЫ ШӘРЕХЛӘҮЛӘРЕ БУЛМАГАН» БЕРДӘМ ТАРИХ ДӘРЕСЛЕГЕ ЯЗУ ИДЕЯСЕН РФ ПРЕЗИДЕНТЫ В.В.ПУТИН 2013 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ МИЛЛӘТАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘР СОВЕТЫ УТЫРЫШЫНДА ӘЙТТЕ.

Дәреслекнең концепциясен әзерләү эшен РФ Дәүләт Думасы рәисе С.Е.Нарышкин җитәкчелегендә Россия тарих җәмгыяте башкара. 2013 елның 27 февралендә җәмгыятьнең идарә рәисе С.М.Шахрай җитәкчелегендә дәреслек төзү мәсьәләсе буенча утырыш уздырылды, анда дәреслекнең темалары, максат-бурычлары тикшерелде. 2013 елның 25 апрелендә РФ Президенты В.В.Путин тарафыннан Россия тарихы дәреслегенең бердәм концепциясе һәм үткән вакыйгаларга рәсми бәясе булырга тиеш, дип әйтелде. Казан (Идел буе) федераль университеты мөрәҗәгате нигезендә, Казанда Россия тарих җәмгыятенең бүлекчәсе төзелде. Шулай итеп, Татарстан тарихчылары да бердәм Ватан тарихы буенча яңа укыту-методик комплексы концепциясенең «Тарихи-мәдәни стандарт» дип аталган документына тәкъдимнәр кертү эшенә җәлеп ителде.

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре, бу документны камилләштерүгә юнәлдерелгән фикерләрне туплап, концепцияне әзерләүче эшче төркемгә юллады. Октябрь башында Мәскәүдә, килгән тәкъдим-теләкләр нигезендә, тулыландырылган «Ватан тарихы» яңа укыту-методик комплекс концепциясенең проектын тикшерү буенча киңәшмә уздырылды. Хәзер әлеге документны камилләштерү соңгы этапка керде. Агымдагы елның 1 ноябрендә документ РФ Президенты Администрациясенә тәкъдим ителергә тиеш. Шул уңайдан 9 октябрь көнне «Чын мирас» журналы редакциясе бу мөһим документны камилләштерүдә фикер-тәкъдимнәрен керткән галимнәрне «түгәрәк өстәл»гә чакырды.

Катнашалар: Рафаиль ХӘКИМОВ — ТР ФАнең вице-президенты һәм академигы, тарих фәннәре докторы, ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры, Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ — ТР ФАнең әгъза-корреспонденты, тарих фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университетының татарны өйрәнү кафедрасы мөдире, Илдус ЗАҺИДУЛЛИН — тарих фәннәре докторы, ТР ФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының урта гасырлар тарихы бүлеге мөдире, Марат ГЫЙБАТДИНОВ — педагогика фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Х.Фәезханов исемендәге милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге җитәкчесе.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Әзерләнә торган бердәнбер «Ватан тарихы» дәреслеге урта һәм өлкән буын вәкилләре тарафыннан еш кына Совет тоталитар җәмгыятенең бер элементы, төрле фикерләрне кысу юнәлешендә ясалган адым буларак кабул ителә. Совет чорында бердәнбер «Ватан тарихы» дәреслеге ул, патриотик һәм тәрбия ягыннан караганда, мөһим чара булган. Ләкин, шуңа да карамастан, СССР таркалды, бердәм «Ватан тарихы» дәреслеге дәүләтнең сакланып калуын тәэмин итә алмады.

Россия һәм рус халкы тарихын гына өйрәнүче яшь буында, кече Ватан тарихын белмәгән һәм аның белән горурланмаган очракта, Олы Ватанга мәхәббәт тәрбияләп булырмы икән? Тагын бер мөһим сорау: Россия Конституциясендә дәүләтнең Федерация икәнлеге язылган шартларда, бердәнбер «Ватан тарихы» дәреслеге булырга тиешме икән? Методик яктан караганда да, сораулар туа: гуманитар профильле урта мәктәпләрдә тарих буенча тирәнтен язылган альтернатив дәреслеккә ихтыяҗ бар. Милли республикаларда региональ компонент белән бердәнбер Ватан тарихы дәреслеге ничек «килешер»? Алар арасында фикерләр каршылыгы бар бит.

Без илдә Ватан тарихын укытуның өч дәверен беләбез: империя чоры, Совет еллары һәм хәзерге заман — соңгы чирек гасыр. Бу чорларда Ватан тарихы мәктәпләрдә ничек укытылган икән?

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. Әгәр дә без империя чорындагы дәреслекләрне карасак, бу дәвердә бердәнбер дәреслек булмаган. Шулай да, төрле авторлар язган дәреслекләрнең концепцияләре бер булган диярлек. Аларда, нигездә, рус тарихына басым ясалган, рус дәүләтчелеге тарихы гына өйрәнелгән. Кайберләре мәдәнияткә тәфсиллерәк урын бирсә дә, нигездә, ул рус мәдәнияте тарихы булган. Әлбәттә, төбәкне өйрәнү дәреслекләре дә басылган, әмма алары да шовинистик рухта язылган. Мәсәлән, Спасскийның «Очерки по родиноведению. Казанская губерния» (1912) исемле китабында шундый юллар бар: «В Казани везде можно встретить эти странные фигуры татарского бабья». Бу инде хатын-кызга гына карамый, ә татар халкына булган гомуми карашны аңлата. Автор фикеренчә, татарлар — сәер, тупас, кыргый һәм мәгърифәтсез, мәдәниятсез халык, алар бары тик Россия дәүләтенә кереп, Европа, христиан мәдәниятенә тап булганнан соң гына, бәхеткә ирешә. Шундый ук фикер-карашлар белән башка авторларның да дәреслекләр язуы мәгълүм.

Революциядән соң мәктәпләрдә тарих укыту берникадәр туктап тора,

бары тик 1934 елдан гына тарих яңадан предмет буларак кайтарыла башлый. Бөек Ватан сугышыннан соң халыкларның рухы күтәрелү һәм шуның нәтиҗәсе буларак, үз тарихларын яза башлаулары да моңа яңа этәргеч биргән. Шул сәбәпле тарих дәреслекләренә мөнәсәбәтле яңа карарлар да барлыкка килә. Союздаш республикаларда тарих язуда берникадәр иркенлек күзәтелсә дә, 40 нчы еллар ахырында республикаларда язылган дәреслекләргә яңа басым башлана. Мәсәлән, СССР Фәннәр академиясе әгъзалары «Казах ССР тарихы» дәреслегенә бәяләмә биргәндә, Казахстанны Россия империясенә кертүне негатив яктан күрсәтергә ярамый, бу тискәре күренеш түгел, ә прогрессив юнәлеш, дип әйтәләр. Гомумән, бу елларда Россия халыкларына субъект буларак түгел, ә бары тик объект буларак кына карарга дигән концепция барлыкка килә. Димәк, кайбер халык — «тарихлы халык», аларның үз тарихы бар, ә кайбер халык «тарихсыз халык» дигән фикер туа. Аларның Россия империясенә кергәнче бернинди милли тарихы булмаган һәм бу тарихны өйрәнергә хаклары да юк дигән караш алга сөрелә. Әмма, бер яктан, рәсми идеологиягә ияреп, интернационализм тәрбияләү һәм «Совет — төрле милләтләр гаиләсе» дигән фикерләргә алар күз йома алмаган. Шуның нигезендә «СССР тарихы» дәреслекләрендә Урарту дәүләте тарихы кебек аерым кисәкләр генә булган, әмма төп тема — рус тарихы, рус дәүләтчелеге тарихы. Хәтта безнең региональ уку әсбабы — «ТАССР тарихы» китабында да шундый җөмлә бар: «Казанны алу ул прогрессив күренеш булган, чөнки, Россия дәүләтенә кергәч, татар халкы киләчәктә Бөек Октябрь революциясенең җимешләренә ирешә алган». Акка кара белән шулай язылган.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Ул заманда: «В плане исторической перспективы», — дип әйтәләр иде.

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. 1990 еллар безгә ирек бирде, тарих укыту да регионнарның үз карамагына гына калды, төрле төбәкләр үз тарих дәреслекләрен язды. Кайберләре шәһәр тарихы — «Москвоведение», «Петербург тарихы», ә кайберләре төбәк тарихлары — «Урал тарихы», «Себер тарихы» дәреслекләрен иҗат итте. Безнең «Казановедение» дәреслеге дә әзерләнде, әмма ул мәктәпләргә кертелмәде. Үзебезнең дәреслекләрдә милли тарихны да, региональ тарихны да бергә кушып язып карадык. Барлык экспертлар да, тәнкыйтьчеләр дә безнең дәреслекләрдә тарихи чынбарлыкка каршы килә торган бер генә факт та күрмәде. Алар бары тик исламга зур басым ясала, татар халкы тарихы күпертеп, матурайтып, горурланып языла, диделәр. Шуның кебек эмоциональ күренешләрне генә гаеп иттеләр, әмма ялган фактлар, вакыйгаларны фальсификацияләү дигән әйберләрне тапмадылар. Кызганыч ки, хәзерге яңа Федераль дәүләт стандартлары һәм «Мәгариф турында» яңа закон кабул ителү белән, безнең милли-төбәк компоненты бөтенләй юкка чыгарылды, хәтта исеме дә бетте. Хәзер федераль һәм мәктәп компонентлары гына калды. Ул компонентлар эчендә инвариатив һәм вариатив өлешләр, ягъни мәҗбүри булган, барлык мәктәпләрдә укытылырга тиешле сәгатьләр һәм сайлап алырга мөмкин булган өлешләр генә калды. Биредә мәктәпләргә бик зур мөмкинлек бирелә. Әмма кайсы гына мәктәптә артык сәгатьләрне татар

халкы тарихына бирәләр икән? Хәтта рус тарихына да бирмәячәкләр, чөнки бу сәгатьләр чит телләргә, информатика дәресләренә һәм БДИга әзерләнүгә китә. Шулай итеп, формаль яктан карасак, әгәр дә ата-аналар теләсә, мөмкинлекләр дә, сәгатьләр дә бар. Белем бирүнең Федераль дәүләт стандартларында: «Һәрбер бала үз халкы тарихын, җирле тарихны, үз төбәгенең милли үзенчәлекләрен белергә тиеш», — дип язылган. Әгәр дә стандартларны укып карасак, ул йөрәккә май булып ята. Әмма чынбарлыкта, мәҗбүри сәгатьләр бирелмәү сәбәпле, стандартларның бу таләпләрен тормышка ашырып булмый. Бүген без татар тарихына гына түгел, ә дөнья тарихын укытуга да зыян килүен беләбез, чөнки укытучылар БДИга потка табынган кебек табына, алар балаларны БДИга әзерләргә мәҗбүр. Ә БДИда татар тарихы гына түгел, дөнья тарихы да юк диярлек. Шул сәбәпле укытучылар, дөнья тарихын да читкә куеп, төп басымны Россия тарихына гына ясый.

Ә хәзерге бердәм тарих дәреслеге турында әйткәндә, ул, гадәт буенча, ашыгыч эшләнде. Өстән әмер килгәч, тиз генә нининдидер бер концепция проекты төзеп, бернинди киңәшмәләр, фикер алышулар уздырмыйча... Бигрәк тә монда, методистлар, укытучылар белән киңәшләшмәделәр. Бер дәреслектә Россиянең йөзләгән милләте тарихын тулаем яктырту мөмкин түгел. Механик рәвештә татар, башкорт, чечен һәм башка милләтләрнең тарихыннан берәр кисәкне ябыштырып, нининдидер бер курс ясау — бу бер уйдырма булып чыгачак һәм аның бернинди дә киләчәге булмаячак дип уйлыйм.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Без бүген Ватан тарихы буенча яңа укыту-методик комплексы концепциясенең проекты турында сөйләшәбез. Бу инде икенче документ. Аның беренчесе — Бердәм Ватан тарихы буенча яңа укыту-методик комплексы концепциясенең «Тарихи-мәдәни стандарт»ы дип аталганын — тикшерү 1 июльдә башланды. 25 сентябрьдә Мәскәүдә бу документны тикшерүгә багышлап уздырылган киңәшмәдә Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Рафаиль Сибгат улы Хәкимов та катнашты. Агымдагы елның 26 октябренә кадәр Ватан тарихы буенча яңа укыту-методик комплексы концепциясенең проектына тәкъдимнәр кабул итү дәвам итә. Рафаиль әфәнде, Мәскәүдәге киңәшмәдән алган тәэсирләрегез белән уртаклашсагыз иде.

Рафаиль ХӘКИМОВ.

Мин эксперт буларак, Тарих институты исеменнән тәкъдимнәремне керттем. Башка институтларның һәм интернет аша укытучыларның да тәкъдимнәре булды. Без тәкъдим иткән зур гына төзәтмәләрне игътибар белән кабул иттеләр. Алтын Урданы йомшартып бирделәр. Бу кыргый дәүләт түгел, ул зур империя, рус тарихын ансыз аңлап булмый, дигән карашлар кабул ителде. Кабул ителмәгән өлешләрнең дә сәбәпләрен аңлатырга тырыштылар. Сөйләшкәндә, ихтирам белән тыңлыйлар, ә дәреслек нәрсә булып чыгар, әйтүе кыенрак. Киңәшмәдә милли республикалардан Татарстан һәм Башкортстан вәкилләре генә катнашты, әйтерсең, бу проблема башка милләт вәкилләренә гомумән кагылмый.

Минем чыгышымда төп тема толерантлык һәм милләтара дуслык турында иде. Халыклар, бу дәреслекне укыгач, бер-берсе белән сугышмасын, тату гына яшәсен иде, дидем һәм мисал да китердем. Әйтик, 1552 елда Казанны Явыз Иван яулап алу сюжеты. Без бу вакыйганы, ике милләтне бер-

берсенә кара-каршы куймыйча, дөрес итеп аңлатып бирергә тиешбез, чөнки бүгенге Казанда ике як буынның да вәкилләре яши. Күп мәсьәләләрне, фәнни хезмәтләргә таянып, объектив анализламасаң, чишеп булмый. Шул ук вакытта бер дәреслек язып кына, бөтен кешенең дә аны гына кабул итүенә ышанырга ярамый, чөнки интернет бар, барлык яшьләр фәкать интернетны гына укый.

Россия тарихына күз салсак, евроцентризм ачыктан-ачык күренеп тора. Гомумән, Россия нинди дәүләт соң? Ул Европа дәүләтеме? Евразия дәүләтеме? Аның бит территориясе Европаны гына түгел, Азия белән Себерне дә үз эченә ала. Дәреслекләрдә Себер тарихы Ермак белән башлана. Аннан элек бу җирләрдә нәрсә булган соң? Кеше яшәгәнме, юкмы? Аны бит Ермак басып алган? Басып алгач, анда дәүләт булган дигән сүз. Әлеге дәүләтләр тарихы төшеп кала. Кечкенә генә бер төбәктән — Новгородтанмы, Киевтанмы (әле анысын да ачык кына әйтмиләр) — Рус дәүләте башлана. Ул дәүләт киңәя-киңәя, хәзерге Россия барлыкка килә, дигән фикерне дәреслеккә кертергә омтылалар. Славяннар килгәнче, хәзерге Россия территориясендә Һуннар империясе, Төрки каганлыгы, Хәзәр илләре кебек төрки-татар дәүләтләр булган. Без һич кенә дә Россия дәреслегендә моны кире кага алмыйбыз. Безнең бу фикерләребез дә өлешчә кабул ителде.

Шулай ук милли төбәкләрне «окраина», «периферия» дип кимсетмәү тәкъдимен керттек. «Үзәк» кая да «окраина» кайда соң? Бу бит шулай ук бәхәсле мәсьәлә.

Әмма зур мәсьәлә ачык калды: Россия дәүләте тарихы ул биредә яшәүче барлык халыкларның тарихымы, әллә русныкы гынамы? Әгәр дә русныкы гына дип чагылыш тапса, ул, Киевтан яки Новгородтан башланып, колонизация, башка халыкларны яулап алу, кушу тарихы дәреслеге генә булачак. Моның инде бернинди мәгънәсе булмаячак. Бу — Н.М.Карамзинга кире кайту дигән сүз. Әлеге мәсьәләне ничек итеп чишәргә икәнлеген әлегә алар тәгаен хәл итә алмыйлар.

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. Әмма алар бит колонизация дип тә әйтергә теләмиләр.

Рафаиль ХӘКИМОВ. Заманында В.О.Ключевский, яшермичә: «Россиянең тарихы — колонизация тарихы», — дип ачыктан-ачык язды. Дөрес, галимнәр безне тыңлый, алар белән уртак тел табуы ансат. Бу 7 томлык татар тарихының 5 томын туплаганда да ачык күренде. Әлеге томлыкларны язуда 300дән артык галим катнашты. Аларның да күбесе — чит төбәкләрдән һәм төрле милләт вәкилләре. Әлеге томлыкларда язылганнар безнең генә фикер түгел, ә объектив, бүгенге тарих фәнендәге фикер. Дәреслек төзегәндә, алар бу фикерләрне тәнкыйтьли дә, кире кага да, кабул итә дә алмыйлар.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Мин «Тарихи-мәдәни стандарт» белән бүген тикшерелә торган яңа документны чагыштырып чыктым. Яңасында мөһим үзгәрешләрнең берсе — «XIII-XV гасырларда Евразия халыклары һәм дәүләтләре» дигән бүлек барлыкка килгән. Күрәбез, Алтын Урда чоры аерып чыгарылган. Биредә Алтын Урданың дәүләт буларак төп аспектлары чагылыш тапкан.

Беренче вариантның ашык-пошык эшләнгәнлеге күренә, ә яңасында аерым бүлекләрне киңәйтеп эшләгәннәр. Биредә хәтта Россия тарихын да яңа чорларга бүлеп карау күренә. Моңарчы ил тарихы Октябрь инкыйлабына һәм аннан соңгы чорга бүленсә, хәзер 1914-1922 елларны «Россия Бөек тетрәнүләр елларында» дип аерым бүлек итеп аерып чыгарганнар. Без биредә Европа тарихы белемενә якынаюны күзәтәбез. Европада, белүебезчә, тарихның яңа дәвере 1914 елдан — Беренче

Бөтендөнья сугышыннан башлана. Документта XVI-XVIII гасырлар, XX йөз башы, Бөек Ватан сугышы һәм 1990 еллардан соңгы дәвер шактый баетылган, ә XIX гасыр, 1920-1930, 1945-1980 еллар үзгәрешсез, элеккечә калган диярлек.

Рафаиль ХӘКИМОВ. Җыелышта XIX гасыр тарихы һәм Сталин чоры буенча шактый тәнкыйди фикерләр булды. Аннары яңа вариантка күп кенә шәхесләрнең исемнәре кертелгән. Ә бит дәреслек зур булмый, барлык исемнәрне анда кертү мөмкин түгел. Кертсәң дә, аңлатып бетереп булмый. Мәсәлән, анда Жириновский исеме кергән, аны гына аңлатыр өчен дә күпме урын кирәк.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Минем фикеремчә, шушы кадәр тикшеренүләрдән соң да, әле бу документ һаман да камил түгел. XIX гасыр — Россия империясе чәчәк аткан чорны һәм Сталин дәверен эшләп бетерү зарур, чөнки бу чорларның бүгенгә кадәр тәэсире бар.

Без тикшерә торган документ галимнәр даирәсендә генә өйрәнелә. Галимнәр алар бер-берсен аңлый. Ә дәреслекнең сәяси яктан нинди үзгәреш кичерәсен без төгәл генә әйтә алмыйбыз.

Киев Русеның халыкара мөнәсәбәтләре турында язган урыннарда Көнчыгыш Европа юк. Көнчыгыш Европа булмагач, Бөек Болгар, Хәзәр каганлыгы, Идел буе Болгары дәүләтләре дә төшеп кала. Әйтерсең, безнең Идел буе төбәкләренең дәүләтчелек тарихы булмаган. Болар бит бик мөһим әйберләр. Шул ук вакытта күчмәннәр цивилизацияләре дә чагылыш тапмаган. Киев Русе оешканчыга кадәрге вакытка ике генә бүлек бирелгән. Аларда Һун, Кимәк каганатлары, финнар белән аланнар да юк. Киев Русена кадәрге күчмәннәр тарихы да чагылдырылса, яхшы булыр иде.

Рафаиль ХӘКИМОВ. Даланың төшеп калуы турында да мин үз чыгышымда әйттем. Алар үзләренең хаталарын таныды һәм концепциягә кертәчәкләрен белдерде.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Борынгы чор буенча янәдән берничә фикер әйтәсем килә. Документка Идел сәүдә юлы кертелгән, ләкин Евразия төрле халыкларның аралашу мәйданы буларак каралмаган. Тагын бер шаккатмалы күренеш — документ Россия дәүләтчелеге һәм мәдәнияте тарихы булып килеп чыккан, русларның этник тарихы, аларның милләт буларак оешу тарихы ачылмаган.

Россиянең төрле дин һәм халык вәкилләреннән торганын күрсәтү өчен, барлык бүлекләргә дә «Россия халыклары» дигән бүлекчәләр кертергә кирәк. Совет чоры буенча һәр этапка «Халыклар һәм республикалар...» дип куярга кирәк, чөнки Совет чорында республикаларда да искиткеч зур эшләр башкарылган. Бу мәсьәләнең гамәли ягы да әһәмиятле. Бүген безгә бик күп мигрантлар килә: казахлар, үзбәкләр, таҗиклар... Аларның ата-аналары Советлар Союзын төзүдә катнашкан, аның азатлыгын яклап Ватан сугышында кан койган. Әлеге милләт вәкилләре хәзер Мәскәү, Санкт-Петербург калаларында бихисап, ә балалары монда белем ала. Объектив бәяләгәндә, СССР мөселман республикаларын үстерү өчен зур эшләр эшләде. Бүген аларның икътисади потенциалы Советлар чорындагы башлангычларга нигезләнгән. Бу аспектлар да исәпкә алынмаган, аларны бүлекләр итеп аерып чыгару сорала.

Программада «Россия мәдәниятенең көмеш гасыры» дигән бүлек бар. Игътибар итегез: Россия мәдәниятенең! Монда XX гасыр башы турында сүз бара. Руслар өчен бу шулай, ә бит татар халкы өчен XX гасыр башы «алтын» чор булган. Чувашлар, марилар өчен Совет дәвере «алтын» чор. Ни-

чек инде монда Россия мәдәниятенең «көмеш» гасыры турында сүз алып барырга мөмкин? Бу бит яңа миф тудыру дигән сүз! Ни өчен шулай килеп чыккан соң? Монда бары тик исемне генә алыштырганнар, ә эчтәлек буенча сүз бары тик рус мәдәнияте турында гына бара. Терминологиягә бәйле мәсьәләдә дә шундый ук күренешләр күзәтелә. Анда «җәдитчелек», «конфессиональ дәүләт», «феодаль дәүләт», «диния нәзарәте» дигән терминнар юк. 1861 елгы реформага кадәрге чордагы вакыйгалар бары тик сәясәтне сурәтләүгә генә кайтып калган, икътисад турында язылмаган. Хәтта крепостное право сүзеннән дә качканнар. Уңайсызланганнармы шунда... Ә бит крепостное право хокукый термин гына түгел, ул — икътисади һәм социаль мөнәсәбәтләр дигән сүз. Икътисади проблемалардан башка тарихны язып булмый.

Шәхесләр мәсьәләсенә килгәндә: Н.И.Ильминский төшеп калган, югыйсә, бүгенге рус булмаган халыкларның мәктәпләрендә укыту аның системасына нигезләнгән. Тюркологлар, көнчыгышны өйрәнүче галимнәр юк. И.Гаспралы, Й.Акчура, Топчебашев, Агаев төшеп калган, ягъни XX гасыр башындагы төрки халыкларның лидерлары чагылыш тапмаган. Габдулла Тукай, Фатих Әмирханнар турында әйткән дә юк инде. XIX гасыр буенча тагын бер-ике әйбергә тукталасы килә. Беренче вариантта милли халыкларның тормышы «Милли һәм дини сәясәт» дигән бүлектә чагылыш тапкан иде. Аны хәзер «Империя җирләре һәм Россия халыклары» дип исемләгәннәр, ләкин регионнарны гына тасвирлап биргәннәр, ә халыкларның исемнәре юк. Поляклар да, яһүдләр дә, әрмәннәр дә, татарлар да һ.б. да... Барысы да аерым төбәк исемнәре белән алыштырылган. Бүлек «...Россия халыклары» дип атала икән, аның исеме җисеменә туры килергә тиеш.

Тагын бер мөһим әйбер: «Идарә итү системасы» дигән төшенчәне дә төшереп калдырганнар. Мин моны махсус эшләгәннәр дип уйлыйм, чөнки Россия империясендә идарә итү системасы күптөрле булган. Анда рус төбәкләре — губерналар да, чик буйларында хәрбиләр идарә иткән өлкәләр (областьлар) дә, наместничестволар, комитетлар да булган. Польша патшалыгының Россия белән мөнәсәбәтләре конфедерация мөнәсәбәтләренә тиң булса, Бөек Финляндия кенәзлеге белән мөнәсәбәтләр, хәзергечә әйткәндә, федератив мөнәсәбәтләргә корылган. Ә Бохара белән Хива ханлыклары, вассал буларак, Россиягә сәяси яктан буйсынганнар, әмма салымнарны үзләрендә калдырганнар. Менә бу төрлелек — дәүләт төбәкләрендә яшәүче халыкларның үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, эчке вазгыятьне кору — гомумән, яктыртылмаган. Документны укыган кеше Россия империя чорында фәкать унитар дәүләт булган дип күз алдына китерә. Ул хәтта СССРның оешуын да сәер, көтелмәгән күренеш булган дип уйларга мөмкин. Ә бит федератив төзелеш башлангычлары империя дәверендә үк салынган, калыплашкан була.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Марат Гыйбатдинов бу мәсьәлә белән күптәннән шөгыльләнә, Рафаиль Сибгатович әлеге концепцияне төзүдә катнашкан, мәскәүлеләр белән килешүләр, сөйләшүләр алып барган шәхес, Илдус Котдус улы инде берничә ай бу мәсьәләнең казанында кайный. Мин, дөресен генә әйткәндә, концепция проектын кулыма узган атнада гына алдым. Шунлыктан карашым әле яңа гына җитлегеп килә.

Беренчедән, бердәнбер дәреслек булырга мөмкинме? Юкмы? Шик бар! СССР чорында безнең бердәнбер дәреслек бар иде. Хәзер дә безгә бердәнбер дәреслек тәкъдим итәләр һәм, табигый, без аны кабул итәргә тиеш була-

быз, чөнки башка вариант юк. Әлеге дәреслекнең эчтәлегенә мөмкин кадәр тәкъдимнәр кертергә тиешбез — бу дәреслекне Россия Федерациясендә яшәүче барлык халыкларга яраклы итәргә кирәк. Әлеге мәсьәләнең гамәлгә ашуына бераз шикләнеп карасам да, концепция белән танышканнан соң, миндә яхшы фикерләр дә туды, чөнки уңай омтылыш монда күренеп тора. Менә сезгә бер фраза китерәм: «Задача учебно-методического комплекса: сформировать представление об основных этапах развития многонационального Российского государства». Авторлар Россия тарихын безнең илдә яшәүче башка милләтләр һәм территорияләр тарихы дип карый... Минемчә, бу омтылыш бик уңай күренеш!

Ләкин концепция әлегә дәреслек түгел. Уңай омтылышлар бар дип, һич тә тынычланырга ярамый! Чыннан да, кайбер әйберләр текстта бик кыска гына искә алынган, ә дәреслектә ул ничек яктыртылыр һәм аңа нинди бәя бирелер — монысы билгесез. Шул исәптән дәреслек язылган вакытта да без бу процесстан читтә калырга тиеш түгел һәм үз фикер-тәкъдимнәребезне әйтергә тиеш дип уйлыйм.

Миңа әлеге концепциядә нәрсә ошап бетмәде соң? Барлык ваклыкларга да тукталып, һәр детальне санап торасым килми, шәхесләрдән кемне искә алырга, кемне төшереп калдырырга да мөмкин икәнен яңадан утырып тикшерергә дә була. Бер мисал белән генә чикләнәм: татарлардан XX йөздә Салих Сәйдәшев һәм Муса Җәлилдән кала беркем дә искә алынмаган! Бу болай булырга тиеш түгел!

Рафаиль ХӘКИМОВ. Әле беренче вариантта алары да юк иде. Хәтта Чыңгыз Айтматовны да без тәкъдим иттек.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Ә XVII йөзгә әллә кемнәрне, әллә нинди монахларны кертеп бетергәннәр, хәтта арасында мин ишетмәгәннәре дә бар. Шәхесләрне һәм терминнарны искә алганда, без шуны аңларга тиеш: дәреслекнең күләме чикләнгән һәм бөтен нәрсәне дәреслеккә кертеп бетереп булмый. Без теге яки бу шәхесне кертергә кирәк, дип әйтербез. Ә бит әлеге шәхесләрне, аларның тарихи рольләрен ничек тә булса аңлату шарт. Менә монда нindидер нигезле һәм аңлаешлы чикләүләр булырга тиеш, чөнки рус тарихчылары концепция текстында, минемчә, икенче дәрәҗәдәге шәхесләрне дә санап чыккан. Бу шәхесләрне бөтен милләтләрнең мәктәп укучылары белергә тиешме? Без аларга мохтаҗмы соң?

XVI йөз — минем иң яраткан темаларымның берсе. Казанны яулап алу — ул Рус дәүләтенең сыйфатын үзгәрткән гаҗәеп тирәнтен борылыш. Онытмыйк: шуның нәтиҗәсе буларак, күпмилләтле, күпдинле Россия дәүләте барлыкка килә. Вакыйгасы искә алынуын алынган, ләкин бу күренешнең чын әһәмияте ассызыкланмаган. Без әлеге мәсьәләгә аеруча игътибар итәргә тиеш, чөнки Россия дәүләте шушы вакыттан гына башланып китә, аңа кадәр ул Киев дәүләте, соңрак Мәскәү дәүләте, аннан соң гына күпмилләтле, күпдинле Россия дәүләтенә әверелә. Кайбер төшенчәләргә дә тукталасым килә. Хронологиядә 1552 ел турында: «Взятие русскими войсками Казани» дип язылган. 1556 ел: «Присоединение к России Астраханского ханства». Биредә мин булган вакыйгаларны бераз йомшартып күрсәтергә омтылышны күрәм. Болар бит барысы да сугыш, кан коя, яулап алу. Кайвакытта тарихны артык йомшартырга кирәк тә түгелдер. Тарихны аңлатканда, бер яктан икенче якка чайкалу зыян гына китерә. Үткәннәрне үзгәртеп булмый, әлбәттә, аларны бары тик мөмкин кадәрле тыныч һәм объектив аңлатырга теләк булырга тиеш. Менә бу мәсьәләләр дә мине сагайтты.

XVIII йөздә дини сәясәтнең үзгәреше

һәм эволюциясе, минемчә, рус һәм татар тарихы өчен бик әһәмиятле. 1730-1740 еллардагы репрессияләр, Яңа керәшен конторасы, Лука Канашевич эшчәнлекләре... Аннан, ниһаять, Әби патша чорында бераз уңай якка үзгәрешләр... Концепциядә бу сюжетлар бик кыска бирелгән, ләкин бит болар милләтләр тарихында мөһим әйбер, аларга махсус тукталырга, махсус аңлатырга кирәктер. XIX йөздә җәдитчелек юк... Югыйсә, җәдитчелек — бөтен Россия империясендә яшәүче мөселман халыкларының тормышын үзгәртеп җибәргән күренеш!

Гомумән алганда, бу концепциядә уңай омтылыш сизелә, тик барыбер европоцентризмга гына түгел, русоцентризмга йөз тоту ачык ярылып ята. Ничек кенә тырышсак та, ничек кенә Рафаиль Сибгатович Мәскәүләргә барып йөрсә дә, без русоцентризмнан берничек тә котыла алмыйбыз. Ярый, хуш, бердәм дәреслек булсын да, ди, ләкин ватанпәрвәрлек хисе, гомумән, зур илгә мөнәсәбәт кече Ватаннан башлана. Шунлыктан тарих фәнен укытуда милли-төбәк компоненты булырга тиеш. Аңа ничек кире кайтырга? Монысы инде зур мәсьәлә. Гомумән, мәктәптә тарих дәресләренә сәгатьләр бик аз бирелә. Икенче Бөтендөнья сугышына — ике дәрес, Беренче Бөтендөнья сугышына — бер дәрес. Шушы кыска гына сәгатьләр эчендә әлеге темаларның бөтен нюансларын, кискен борылышларын, фаҗигаләрен балаларга ничек аңлатып бетерергә мөмкин? Шуңа күрә вариатив юнәлештә булса да, мәктәпләрдә төбәк, милләт тарихлары, һичшиксез, укытылырга тиеш. Әлбәттә, бердәм дәреслек тә булсын, әмма милли-төбәк компонентының кире кайтарылуы шарт.

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. Әйткәнемчә, милли-төбәк компонентын мәктәпләргә кертү мөмкинлеге бар, әмма аның өчен ата-аналар һәм җәмәгатьчелек белән эшләргә кирәк. Әгәр дә бүген 10-20 ата-ана директорга килеп: «Безнең балаларга татар тарихы, татар мәдәнияте кирәк!» — дип әйтә икән, директорның моңа каршы килергә хокукы булмый, чөнки канун буенча, өстәмә сәгатьләрне нинди фәннәргә бирү мәсьәләсе ата-аналар белән киңәшләшеп хәл ителергә тиеш. Кызганычка каршы, бүген ата-аналар моның белән кызыксынмый.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Аларга БДИ нәтиҗәсе кирәк....

Рафаиль ХӘКИМОВ. Ата-аналар үзләре дә тарихны белми бит...

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. Бу очракта республикабыз хакимияте дә ярдәм итәргә тиеш. «Диннәр тарихы» һәм «Этика» дәресләрен сайлаганда, ата-аналар үз фикерләрен әйтте, хакимият тарафыннан да аңлату эшләре алып барылды. Нәтиҗәдә, классларда мөселманнар белән христианнарны аермаска, дигән төпле фикергә килделәр.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Кызганычка каршы, безнең җәмгыятьтә тарих белән кызыксыну, тарих фәненең әһәмиятен аңлау юк. Күпчелек тарихның нәрсә өчен кирәклеген дә аңламый, гомумән, гуманитар фәннәрнең нигә кирәклеген белми...

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Дин белән бәйле тагын бер мәсьәләгә тукталасым килә. Чыннан да, концепция проектында чиркәүнең миссионерлык эше күренми. «Россия XVI гасырда» исемле бүлектә XVI йөзнең икенче яртысы турында сүз барган урында «Русская православная церковь» һәм «Мусульманское духовенство» дигән җөмләләр бар. Казанны яулап алгач, мөселман руханилар катлавы калмый... Монда «мусульманское духовенство» дип түгел «Миссионерская деятельность Русской православной церкви» дип язылырга тиеш, чөнки хәзерге керәшен татарларының гына түгел, ә мари, удмурт, чуваш, мукшы халыкларын да христиан диненә тарту шушы вакыттан башланып китә.

«Россия империясе XIX-XX гасырларда» дигән бүлектә «РПЦ и основные конфессии: иудаизм и ислам» дип язганнар. Ә бит чынлыкта дәүләтнең диннәргә карата мөнәсәбәтен чагылдырган һәм империядәге конфессияләр арасындагы система — «православие, инославие, иноверие» яктыртылырга тиеш. Башкача эшләгәндә, дәреслек рус тарихы гына булып калачак.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. ...һәм христиан дине тарихы!

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. Әмма дәреслекнең күләме, санитар нормалар дигән әйбер бар. Рафаиль Сибгатович, бу концепциягә без бүген керткән тәкъдимнәр кабул ителерме, алар дәреслектә чагылыш табарлармы?

Рафаиль ХӘКИМОВ. Миңа калса, бу — сәяси мәсьәлә. Тарихчылар аның белән килешер иде, алар белән уртак тел табуы авыр түгел! Сәяси күзлектән караганда мәсьәлә, четереклерәк... Безнең тәкъдимнәр кертелгән концепция проекты Россия Федерациясе Президенты Администрациясенә биреләчәк. Монда инде үз фикерләрен тарихчылар гына түгел, ә сәясәтчеләр дә белдерә. Шунлыктан ТР Дәүләт Советы, ТР Президент Аппараты, Татар милли-мәдәни автономиясе безне якларга һәм үз фикерләрен әйтергә тиеш дип уйлыйм. Әлегә ни өчендер алар читтә тора... Мин чыгышларымда да: «Без үз эшебезне эшләдек, хәзер сез фикер белдерергә тиеш», — дип әйттем. Әмма Татарстан Дәүләт Советындагы һәм РФ Дәүләт Думасындагы республикадан сайланган депутатларыбыз сүлпәннәр. Һәрберсе үз хәле белән мәшгуль... Безнең тәкъдимнәр кабул ителеп, уңай дәреслек язылу мәсьәләсе шик уята...

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. Әгәр дә безнең тәкъдимнәр белән әлеге дәреслек язылса, бу Россиядә тарих гыйлемен укыту, дәреслекләр язу системасында яңа бер этап булыр иде. Без Россия тарихын Евразия тарихы яссылыгында карасак, андагы үзенчәлекләрне, уникальлекне, шул исәптән охшаш булган якларны да күрә алыр идек. Әмма концепциядә Европа белән Азия аерым, ә Россиянең үзенчә уникаль, беркемгә дә охшамаган юл белән барганы күзәтелә.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Гомумән, идеаль дәреслек юк ул. Мин күптән түгел генә Германиядә булып кайттым һәм андагы тарих дәреслекләре белән кызыксындым. Алар ярты ел буе борынгы кешеләрне, аннары ике-өч ай грек тарихын укыйлар һәм XVIII йөзгә күчәләр. Менә сиңа бөтен тарих!

Рафаиль ХӘКИМОВ. Германиядә хәл җиңелрәк, анда һәрбер төбәкнең үз стандартлары, сайлау мөмкинлекләре бар.

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. Без һаман да баланың башына мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат сеңдерү турында уйлыйбыз. Ул Куликово сугышы кайчан булганлыгын, императорларны, хәрби лидерларны белсен, дибез... Әгәр дә инде укучы сугышның алшартлары һәм нәтиҗәләрен дә әйтеп бирә алса, «биш»ле куярга була. Ә Германиядә мондый максатлар куелмый. Бәлки бөтен фактларны, нечкәлекләрне тарихчы гына белергә тиештер? Германиядә методистлар, галимнәр: «Тарихны укыту балага нинди файда бирәчәк?» — дип карый.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Төп файда — баланы уйларга өйрәтү.

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. Әлбәттә. Хәтта шундый фикер дә бар: «Тарих укытуның мәгънәсе — балаларны газета-журнал һәм башка мәгълүмат чараларын укырга өйрәтү». Димәк, син теге яки бу информацияне укып, андагы фикерләрне аңлы рәвештә кабул итәргә, анализларга тиеш буласың. Европада мәгълүмат кабул итүчене генә түгел, ә фикер йөртүче, вакыйгаларга үз мөнәсәбәтен белдерүчене әзерлиләр. Әйтик, алар феодализмның нәрсә икәнлеген өйрәнә дә аны башка

илләр мисалында чагыштырып карый. Шулай итеп, тарих укытуда дөрес максат кую да бик мөһим, чөнки интернет мәгълүмат белән тулы, ә аны анализлый белергә кирәк. Теләсә нинди датаны, вакыйганы интернеттан да табарга мөмкин.

Рафаиль ХӘКИМОВ. Аннары дәреслекләрдә бик борынгы тарих белән мавыгу ни дәрәҗәдә файда китерә икән? Аның бүгенге көн белән бәйләнеше булмаса, укучыга белеп бетерү нигә кирәк? Ә Алтын Урда дәверләре, Казан яулап алыну чорлары белән вазгыять башкача. Болар турында бар кеше сөйли, әдәби әсәрләр язалар, опера-балетлар куялар. Миңа калса, һуннар, кимәкләр турында бер җөмлә белән генә әйтү җитә, ә тәфсилле сөйләү белгечләр өчен генә кирәк.

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. Нинди генә дәреслек булмасын, һәр укытучының башында үз концепциясе бар, һәм ул үз юлы белән дәрес бирә ала.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Нигездә, күп нәрсә шәхестән тора, ә дәреслек ул бары тик ориентир гына.

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. Әлбәттә, дәреслекләр бик әһәмиятле, әмма без укытучылар әзерләү системасын таркатмаска тиеш. Кызганычка каршы, инде ул таркалып бара... Күп кенә җитәкчеләрдә шундый иллюзия бар: менә дәреслек язылды, ул дөрес, камил китап була һәм укытучы бу китап белән балаларга «чын тарих»ны өйрәтә, ватанпәрвәрлек хисе тәрбияли, балалар мәктәптән камил шәхесләр булып чыгалар... Әмма чынбарлык бөтенләй башкача булырга мөмкин.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Мин еш кына үземнең мәктәптәге укытучыларымны искә төшерәм. Әгәр дә алар булмаса, мин, гомумән, тарихи эзләнүләргә кереп китә алыр идемме икән? Укытучы бит бары тик дәреслекне генә кабатламый һәм кабатларга тиеш тә түгел. Дәреслек балаларга мәгълүматны искә төшерер өчен генә кирәк, күп әйберне укытучы бирә.

Марат ГЫЙБАТДИНОВ. Аннары тагын бер кимчелек бар. Шул ук хөкүмәт кабул иткән документлар да бер-берсенә каршы килә. Мәсәлән, әле генә кабул ителгән Белем бирүнең Федераль Дәүләт стандартында балалар укытуда вариативлык булырга тиеш, дип язылган. Димәк, бердәнбер дәреслек ул стандартка каршы килә. Ничек инде бердәнбер дәреслек булганда, вариативлык була ала? Каршы килмәсен өчен, ул дәреслеккә төрле фикер-карашларны кертергә кирәк, ә болай эшләгәндә, берничә томлы дәреслек язылырга мөмкин. Бу проблеманы традицион карашлар кысаларында хәл итү мөмкин түгел. Шуңа күрә искергән методлар һәм алымнар кысаларына яңа эчтәлек салабыз, дип маташу уңышсыз. Яңа дәреслек эчтәлеге буенча гына түгел, методлары да, төзелеше буенча да яңа булырга тиеш.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Йомгаклап түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Беренчедән, концепция, чыннан да, империя һәм Совет чорындагы дәреслек төзү традициясен дәвам итә. Икенчедән, аның концепция проектын эшләү төркеменә РФ субъектлары Фәнни үзәкләреннән галимнәрне җәлеп итмәделәр. Өченчедән, шушы бердәнбер дәреслек киләчәктә тагын берничә вариант булып үзгәрер, камилләшер дип уйлыйм. Профильле уку йортлары өчен аерым, милли республикалар өчен җирле үзенчәлекләрне искә алган дәреслекләр дә булыр дип ышанасы килә.

9 октябрь, 2013 ел

***Илдус Заһидуллин** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.*

ШАГЫЙРӘ

САЛИСӘ ГӘРӘЕВА
(06.11.1938)

ШИГЪРИЯТ

Шигърият ул сары сандугачның
Жыры гына түгел тирәктә.
Шигърият ул... акыл чакмасының
Ярсып бәрелүе йөрәккә!

Ул — Жир тыны, ак каеннар моңы,
Карны ерткан уҗым кыягы!
Ул — акбүз ат, дала күкрәгендә
Йөрәк кебек тибә тоягы!

Ул — сүзсез жыр, күңел түрендәге
Бөреләнеп килгән хисләрем!
Ул — таң сере! Кояш! Җилкәсенә
Зәңгәр шәлен япкан кичләрем!

Шигърият ул — тургай кыңгыравы,
Кош канаты сызган ак юллар,
Һәм... без яшәп, сөеп, янып киткән
Саф мәхәббәт тулы ак еллар!

Ул — агымсу, чишмә чылтыравы,
Диңгез шавы, яңгыр биюе!
Мәхәббәт ул! Ефәк чәчләремә
Мин яраткан куллар тиюе!

Шигърият ул — Тормыш! Һәм аның да
Мәгънә тулы утлы мизгеле.
...Яшәешнең серен шигырь иткән
Минем кайнар йөрәк, билгеле! ■

* Шагыйрә Салисә Гәрәеваның кайбер сүз энҗеләре белән журналның башка битләрендә таныша аласыз.

ТАТАРЛАРНЫҢ ШӘРЕКЪТӘГЕ КҮЧЕМСЕЗ МИЛКЕНЕҢ ЯЗМЫШЫ НИХӘЛДӘ?

АЗАТ АХУНОВ,
филология фәннәре кандидаты,
Казан (Идел буе) федераль университетының
Халыкара мөнәсәбәтләр институты доценты

ТАТАРЛАРНЫҢ КҮЧЕМСЕЗ МИЛКЕ ХАКЫНДАГЫ МӘСЬӘЛӘНЕ БҮГЕН РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ ЧИТ ИЛЛӘРДӘ ЯТЛАР КУЛЫНА КҮЧКӘН МИЛКЕ БЕЛӘН БЕРГӘ КАРАРГА КИРӘК.

Соңгы вакытта дәүләт әлеге мәсьәлә белән чынлап торып шөгыльләнә башлады, хәтта махсус оешма — «Госзагрансобственность» исемле федераль унитар предприятие булдырды. Күптән түгел «Российская газета»да басылган мәгълүматларга караганда, Россиянең, шул исәптән, күрәсең, «татарларның да», чит илләрдәге күчемсез милке биш миллиард долларлык дип исәпләнә. Белгечләр Россиянең күчемсез милке Якын Көнчыгышта гына да 1917 елда ике миллион квадрат метр тәшкил итүен исәпләп чыгарган [1].

Тарихка күз төшерик. 1918 елда большевиклар Россия империясе әҗәтен түләүдән баш тарта һәм бер үк вакытта Россиянең чит илләрдә калган күчемсез милкеннән, алтыннан һәм кыйммәтле кәгазьләрдән ваз кичә. Фәкать 1923 елда гына, акылларына килеп, алар патша әҗәтенең бер өлешен түләргә ризалаша һәм югалган милекне кире кайтару турында сөйләшүләр башлап җибәрә. Шул чордагы тышкы сәүдә халык комиссары Леонид Красин Британиянең «Пинкертон» дигән фирмасына рус православие чиркәвенең элеккеге милкен бәяләгәне өчен акча түли. Бу вакыйганың ничек тәгәлләнүе хәзергәчә билгесез. Әмма 1993 елда шул ук фирманың экспертлары Көнбатыш, Якын һәм Ерак Көнчыгыш илләрендә Россиянең алтыны һәм башка төрле милкенең 188 миллиард доллар күләмендә «сеңеп» калуын хәбәр итте. Күрүебезчә, төрле саннар китерелә, әмма һәр очракта да алар бәләкәй түгел [2].

Биниһая зур шушы мөлкәттә татар капиталы күпме өлеш били? Моңа КГБ архивыннан китерелгән мәгълүматлар күпмедер дәрәҗәдә ачыклык кертә. Әлеге мәгълүматларны 1998 һәм 2001 елларда КДУ профессоры Индус Таһиров белән ТР буенча Федераль куркынычсызлык хезмәте идарәсе Иҗтимагый элемтәләр үзәгенең элеккеге җитәкчесе Ровел Кашапов бастырып чыгарды [3].

Р.Кашапов фикеренчә, татар күчемсез милкенең язмышы болай: совет хөкүмәте аны башта үзләштергән, ә соңыннан саткан.

Шуннан акча яшь дәүләт казнасын тулыландырган, ул акчаның бер өлеше Коминтернны финанс белән тәэмин итүгә тотылган. Р.Кашапов тарафыннан китерелгән мәгълүматка караганда, 1925 елда тышкы эшләр халык комиссары Григорий Чичерин Казан мөселманнарының изге урыннарда булган милке белән кызыксынган. Ул вакытта Согуд Гарәбстанында (бу чорда әлеге ил Һиҗаз, Нәжд корольлеге дип йөртелгән) СССР илчесе булып татар милләтеннән Кәрим Габдерәуф улы Хәкимов (1892-1938) эшли. Нәкъ менә шул кеше Тышкы эшләр халык комиссариатына биредәге татар милке хакында сорау юллый. Икенче төрле әйткәндә, бу хактагы мәгълүматлар ике чыганактан — Согуд Гарәбстаны һәм Мәскәү эчке эшләр хезмәткәрләре тарафыннан тупланган [4].

Шул рәвешле, Чичерин соравына җавап итеп, Мәккәдә «Низаметдин әфәнде», «Шакирҗан әфәнде» исемнәре белән йөртелә торган тәккәләр (суфилар һәм хаҗга баручылар өчен мосафирханәләр) һәм Шөбәйха урамында Галимҗан Галиевнең вакыф йорты (татар дин галиме Галимҗан Баруди йорты) булуы турында хәбәр ителә. Мәккәдә тагын бер йорт «Морат әфәнде» исемен йөртә һәм ул татар фабрикантлары Дибердиевләр хисабына төзелә.

Югарыда телгә алынган милек документлары Шәкүр әфәнде дигән кешедә саклана. Моңардан тыш, Мәдинә каласында «Казан мәчете»ннән, «Казан мәдрәсә»сеннән, бертуган Дибердиевләрнең берничә кибетеннән, Вахит әфәнденең вакыф йортыннан, шулай ук «Кадыйр әфәнде» тәккәсеннән торган милек турында хәбәр ителә. Соңрак Чичерин югары оешмаларга җибәргән хатында болай дип яза: «Хәкимов, һичьюгы якынча материаллар булмыйча торып, биредәге шушы мөлкәт хакында нинди дә булса тулы мәгълүмат алырга мөмкин түгеллеге турында хәбәр итә. Шуңа күрә иптәш Хәкимов үзенә бу мөлкәт хакында мөмкин кадәр тулырак материаллар җибәрүне сорый, андый мәгълүматларны безнең мөселман оешмаларыннан алуны таләп итә» [5].

Бюрократия машинасы хәрәкәткә килә. Мәскәү белән Казан арасында рәсми хатлар йөри башлый, алар хәл-вазгыятьне акрынлап ачыкларга мөмкинлек бирәләр. 1925 елның декабрендә Тышкы эшләр халык комиссариаты Казанга, Шәрекътәге күчемсез милек һәм аның ихтимал булган хуҗалары турында мөмкин кадәр тулы мәгълүмат җибәрүне үтенеп сорау җибәрә. Мәскәү Согуд Гарәбстанындагы бу йортларның кемнеке икәнлеген ачыклауны таләп итә. «Әгәр әлеге мөлкәт шәхси физик һәм юридик затларныкы булмаса, без аларны СССРга кайтарырга таләп итүнең законлы нигезенә ия булачакбыз». Әмма бөтен хикмәт шунда ки, татар күчемсез милкенең иң зур өлеше нәкъ менә шәхси затларныкы булганлыктан, большевикларга аларны кайтарып алырга берни дә мөмкинлек калмый. Фаразан, бу момент та исәпкә алынган була. Әгәр законлы йорт хуҗалары табылса, Мәскәү «аларның йортка ия булу хокукларын яңадан торгызу һәм киләчәктә аларның мәнфәгатен яклау турындагы мәсьәләне ачыкларга» әзер була.

Күрүебезчә, совет дәүләте законлы йорт хуҗаларының «хокукларын яңадан торгызу» планын кора, әмма моңа ышануы кыен. Мөгаен, милекнең элеккеге хуҗаларын файдаланып, соңыннан аларны, тере шаһитлар калмасын өчен, ераккарак озатырга уйлаганнардыр. Документларда җирле татарларның шушы тәкъдимне хуплаган очрагы теркәлгән мәгълүматлар юк.

Хәлбуки, 1926 елның маенда Казанга күчемсез милек белән эшләрнең ничек торуын җентекләп тасвирлаган яңа хат

килеп төшә. ОГПУның Татарстан бүлеге Гарәбстанда һәм Төркиядә кимендә тагын биш татар йортының ничек барлыкка килү тарихын ачыклаугаирешә. Моңардан тыш, Җиддәдән «Вакыфлар турындагы мәсьәлә тарихы» дигән бай эчтәлекле «белешмә» килә. Анда болай диелә: «Консуллык хезмәткәрләренә сугыш аркасында Мәккәдә бүленеп калган Россия гражданнарына күп тапкырлар хәл кадәре ярдәм күрсәтү — теге яки бу рәвештә вакыф милегеннән вакытлыча файдалану юлы белән булышлык итү һәм Җиддә каласында бу йортларны гаскәриләр тарафыннан пыран-заран китерүдән саклап калу турында үтенүләренә бәйле мәсьәләләр белән очрашырга туры килә». 1925 елның башында Россия консуллыгы Мәккәдә Россия колониясенең вакыф эшләре комитетын төзергә тырышып карый. Бу комитет вакыф милеге мәсьәләсен хәл кылуда ярдәм итәргә, бер үк вакытта аны контрольдә тотарга һәм исәп-хисап алып барырга тиеш була. Ләкин башта эш бик акрын бара. Нәкъ менә шул чорда биредә коточкыч сугыш башлана. Ул сугышны Гарәбстанны берләштерү максаты белән Нәжд әмире Ибне Согуд оештыра. Табигый ки, мондый шартларда эшне җайга салу һәм контрольдә тоту турында сүзнең булуы да мөмкин түгел. Барысы да тынычлангач, илчелек хезмәткәрләре янә милек мәсьәләсенә әйләнеп кайталар. Өстәвенә, әлеге чорда Бохара совет халык республикасыннан вакыфлар язмышы турында сорау килә. Анда шушы «вакыф милкен Бохара Республикасына тапшыру һәм юридик яктан аңа беркетү турында» мәсьәлә күтәрелә. Әмма большевиклар бу кыйммәтле милекне мөселман ватандашлары белән һич тә бүлешергә җыенмыйлар. Шул уңай белән мондый билгеләмә кабул итәләр: «Һиҗазда Россиядән чыккан, шулай ук Бохара һәм Хивадан килгән кешеләр тарафыннан булдырылган вакыф милке — асылда дини-хәйрия юнәлешендәге иҗтимагый мөлкәт ул, аңа фәкать без генә контрольлек итә алабыз». Бер Мәккә каласында гына да элеккеге Россия империясе кешеләре карамагында Советлар «балансына» һич тә күчереп булмый торган 7 хосусый һәм мирас итеп калдырылган вакыф саналган. Аның каравы шул ук Мәккәдә генә дә җәмәгатьчелек йортлары 100дән артып киткән, ә Җиддәдә дүртәү булган. Шул мәгълүм «белешмә»дә «вакыфларга гаять зур күләмдә капитал салынган булуына карамастан, Һиҗазда Россия вакыфларының үзәкләштерелгән идарәсе булмый, аларга контрольлек ителми». Моңардан тыш, иганәчеләр (һәм аларның варислары) вакыф милке белән үзләре исән вакытта гына идарә итә алганнар, әмма аны хосусый мөлкәткә әйләндерә алмаганнар. Шулай ук күпчелек биналарның хосусый милек итеп үзләре сатып алган җирдә түгел, ә арендага алынган урыннарда салынуы да моңа комачаулык иткән. Төркия законнары нигезендә (Гарәбстан исә XX гасыр башына кадәр Госманлылар империясенә керә), чит ил кешеләре җир сатып ала алмаган. Шуңа күрә алыш-биреш кәгазьләре ялган төрек һәм гарәпләр исеменә языла. Ә инде төрекләр Гарәбстаннан киткәч, яңа гарәп хакимнәре әлеге алыш-биреш кәгазьләрен законлы документ итеп санамыйлар. Шунлыктан төрекләрнең (шул исәптән Россия мөселманнарының да) бик күп күчемсез милек объектлары конфискацияләнә. Моңа аңлатма биргәндә, СССР илчелеге белгечләре, бу барлык кешелек законнарын һәм шәригать кануннарын бозу булып тора, дип бәяли.

Вакыф турындагы әлеге текст төзелгәндә, Россия мөселманнары милке турында мәсьәлә хәл ителмәгән була. Бер караганда, яңа король Ибне Согуд милекне турыдан-туры көч белән тартып алырга җыенмый, элеккеге идарәчеләрдән документлар гына таләп итә. Ләкин бу да изге ният

Татар шәкертләре Мәдинәдә
(«Аң» журналыннан алынган фото. 1914 ел. №3)

булып кына кала. Хикмәт шунда ки, документларның күпчелеге соңгы сугышлар һәм бәрелешләр вакытында юкка чыккан яки аларны элеккеге хуҗалары үзләре белән алып киткән. Хәер, ул документларның күчермәләре Госманлылар империясенең дәүләт архивларында сакланып калырга тиеш, ләкин анда аларны кем барып эзләр икән?

Текст авторлары, Россия мөселманнарының гомуми милке, акчага күчереп исәпләгәндә, берничә йөз мең фунт стерлингны тәшкил итә, дип санап чыгарганнар. Шул чор өчен искитмәле зур сумма бу! Совет хөкүмәте бу майлы калҗаны кулыннан ычкындырырга теләми һәм милеккә үз контролен булдыру өчен һәртөрле (иң әүвәле законлы) юллар эзли.

Без милеккә бәйле әлеге эпопеяның ничек төгәлләнүе турында берни дә белмибез. Гәрчә шушы мәсьәләгә кагылышлы документлар хәзергәчә ФСБ, Россиянең Тышкы эшләр министрлыгы архивларында сакланган булырга тиеш, ә алыш-биреш кәгазьләре, мөгаен, Истанбул архивларындадыр.

XIX гасыр ахыры — XX йөз башында шактый хәлле татарларның Якын Көнчыгышта үз йортлары булган. Бу йортлар акчаны ышанычлы рәвештә урнаштыру яки хәйрия максаты белән сатып алынган. Кагыйдә буларак, 5-6 бүлмәле, 2-3 катлы йортлар Россиядән хаҗга килгән мөселманнарга (кайчакта «казанлыларга», «мишәрләргә», «бохаралыларга» һ.б. дип атап куела) яки гарәп уку йортларында белем алучы шәкерт-студентларга вакытлыча файдалануга бирелгән. Торган өчен түләмәгәннәр, гәрчә кем дә булса түләргә теләсә һәм хәленнән килсә, ул акчадан баш тартмаганнар. Теге яки бу суфичылык тарикате-оешмасына кергән хәлле татарларның бер өлеше тәккә-йортларны Шәрекъкә үз белемнәрен күтәрергә, күренекле дин әһелләре, остаз-шәехләр белән аралашырга килгән мөэмин-мөселманнар өчен салдырта. Мәсәлән, татар сәүдәгәре Ибраһим Апаков (1821-1885) Мәккәдә үз акчасына пансион төзетә, монда торучыларны көнгә өч мәртәбә бушлай ашаталар. Югарыда сәүдәгәр Мөхәммәт-Йосыф Дибердиев хисабына салынган йорт телгә алынган иде. Бу шәхес бик зур фабрикант була, шулай ук талантлы шагыйрь һәм публицист буларак та таныла. Күрәсең, Дибердиев кайсыдыр суфичылык тарикатендә торган һәм хәйрия максаты белән күчемсез милек булдырган. Ул чама белән 1899 елда хаҗга бара. Мәккәдә Дибердиев күптән түгел генә өйләнгән туганы, татар тарихчысы Мо-

рат Рәмзи (1855-1934) йортында туктала. Өйдәге тыгызлык һәм бөркүлек, сабый баланың бертуктаусыз тавыш куптарып йөрүе затлы кунак күңеленә хуш килеп бетмәгән, күрәсең. Шунда Дибердиев туганына яңа йорт сатып алып бирә. Соңыннан аны «Морат әфәнде» йорты дип йөртәләр. Сүз уңаеннан М.Рәмзинең хатыны Әсма ханымның татар сәүдәгәре Габдрахман Җәдитнең бертуган сеңлесе булуын да әйтергә кирәк. Бу кеше Шәрекъ һәм Европа илләре арасында сәүдә белән шөгыльләнә, еш кына Мәккәдә була. Монда ул үз йортын булдыра.

Татар дин әһеле Габдерәшит Ибраһимов (1857-1944) үзенең тәрҗемәи хәлендә XX гасыр башында Мәдинәдә Казан мөселманнары тоткан кимендә дүрт йорт булуы турында яза. Ул үзе, мәсәлән, шәех Габдесаттар идарә иткән йортта туктала [6]. Ләкин ул йортларның тәгаен кемнәрнеке булганлыгы билгесез. Хәер, кайчак архив материалларында «таянырлык» нәрсәләр дә очрый. Казан архивларының берсендә без 1883 елда туган Мөхәммәтшакир Закир улы Бигаев исеменә юлыктык. Бу кеше сәгать остаханәсе тоткан. 1933 елда аны «Бөтенсоюз социал-фашистлар партиясе» эше буенча кулга алалар. Тикшерүчеләр аның зур йорт хуҗасы икәнлеген ачыклый, ул Казанда, Истанбулда һәм Мәдинәдә йортлар тоткан, соңгысында революциягә кадәр берничә ел яшәп алган [7].

Аерым чыганаклар безгә Истанбулда элеккеге Казан мөселманнары карамагында өчкатлы йорт булганлыгын күрсәтә.

Югарыда исеме аталган Габдерәшит Ибраһимов фикеренчә, бу йорт Исхак хаҗи Апанаев хисабына алынган. Әлеге йорт, төгәлрәге — тәккә, «Нур Госмания» мәдрәсәсе янында урнашкан, Мәккәгә барышлый татарның бик күп зыялы затлары шунда тукталган. Шиһабетдин Мәрҗани, Габдерәшит Ибраһимов, суфичылар шәехе Зәйнулла Рәсүлев исемнәре әнә шундыйлардан.

Күчемсез милек турында сөйләгәндә, Якын Көнчыгышта Россия исеменнән эш йөрткән дипломат татарлар турында бәян кылу зарур. 1892 елда Согуд Җиддәсендә Россия илчелеге ачыла. Согудлылар дәүләтендә беренче илче итеп татар кешесе — Шаһимәрдән Мирәс угылы Ибраһимов (1841-1892) куела. Ул, хаҗ кылганда, билгесез сәбәпләр аркасында һәлак була. «Кяферләргә» хезмәт иткәне өчен, дини фанатиклар үтергән, дигән фараз да юк түгел. Кайбер мәгълүматларга караганда, Россия Тышкы эшләр министрлыгы Ибраһимовка «шәехләр белән турыдан-туры дустанә мөнәсәбәткә керергә» һәм Россиянең Гарәбстанда «үз кодрәтенә тиң югары дәрәҗәдә булуына» ирешергә куша. Гәрчә үзе «җирле халыкның хөрмәтен вә мәхәббәтен яуларга» тиеш була. Кем әйтмешли, утсыз төтен чыкмый — илчелек тә разведка эшләре белән шөгыльләнә. Аерым алганда, илчелек бу елларда Мәдинәдә яшәгән Шамил имам улы Мөхәммәтгалинең (Мөхәммәткамил исеме белән дә билгеле) һәр адымын күзәтеп тора. Мөгаен, шулар бөтенесе дә илче язмышында чагылыш таба [8].

1895 елда Җиддәдәге Россия илчелегендә янә татар кешесе — Шакирҗан Ишәев эшли. Ул 1896 елда «Среднеазиатский вестник» журналында бастырган «Мәккә — изге кала» дип аталган зур күләмле мәкаләсендә бу шәһәрдән һәм Согуд Гарәбстаныннан алган тәэсирләрен бәян итә. Илче мөселманнар тәккәсенә баруын болай тасвирлый: «Барча милләттән хаҗга килгән ярлы кешеләр өчен «тәкия» дип аталган түләүсез йортлар бар. Алар төрле чорларда төзелгән һәм бай мөселманнар, ислам динендәге халыклар тарафыннан хаҗга баручылар файдасына иганә итеп бирелгән. Ошбу «тәкия»ләрне махсус кешеләр тота. Шәһәрдәге барча йортлар ничек булса, боларның да тышкы вә эчке кыяфәтләре шыксыз…» [9].

1945 елда Мәдинә шәһәренең гу-

бернаторы татар кешесе Исмәгыйль әфәнде була. Аның әтисе хәзрәти Мостафа хәзерге Әлки районының Чаллы авылында мулла хезмәтен башкара һәм Октябрь инкыйлабына кадәр үк Төркиягә күчеп китә, соңрак Мәдинәгә килеп урнаша. Мәгълүм булганча, аның туганнарыннан тагын берсе Казандагы Кызыл мәчеттә муллалык кыла. Бу губернатор тарихта нинди эз калдырган? Әлеге сорау һаман әле үз җавабын көтә [10].

1924 елда Советлар Союзы белән Һиҗаз арасында рәсми дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырыла. Ә Җиддәдә Совет иле дипломатия агентлыгына һәм генераль илчелегенә 32 яшьлек Кәрим Хәкимов җитәкче итеп куела. Бөтен дөньяның СССРны танымаган һәм аның белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырмаган дәвердә тышкы сәясәт өлкәсендә бу үзенә күрә бер юл яруга тиң адым була, илчелек Шәрекътәге гарәп гавамында СССРның бердәнбер дипломатик вәкиллеге була. Башка илләрнең дипломатлары арасында иң беренче булып Хәкимов үз дәүләте исеменнән әлеге яңа дәүләтне таный. Согудлылар белән Советлар арасында сәяси шартнамә төзү аның төп максатыннан санала.

«Мәккәдәге безнең вәкил, — дип яза Григорий Чичерин Хәкимов хакында, — күзәтүче һәм хәбәр итеп торучы булачак, шул ук вакытта мөселманнар дөньясының бөтен ягыннан бирегә агылган вәкилләренә йогынты ясап торачак». Әлеге максат хакына Мәскәүнең идарәче даирәләре Кәрим Хәкимовка мөселманнар тормышы белән яшәргә — мәчеткә йөрергә, хаҗга барырга рөхсәт итәләр. Шуның нәтиҗәсендә, илче согудлылар хакимияте даирәсенә якынаюга ирешә. Бу вакытта әле ул илдә нефть чыгарылмый, бензин белән керосин Англиядән кертелә. Хәкимов исә нефть продуктларын СССРдан арзанрак бәягә китертүгә, шул рәвешчә гарәп илләре базарында Бөекбританиянең монополиясен җимерүгә һәм бер үк вакытта сәяси йогынтысын какшатуга ирешә.

Безгә Төркия, Сүрия, Согуд Гарәбстанында һәм башка илләрдә реституция, ягъни кире кайтарып бирү законнары бармы-юкмы икәнлеген ачыкларга кирәк. Ә андый законнар булса, алар татар сәүдәгәрләренең бүгенге варисларына үз мирасларының бер өлешенә дәгъва кылырга ярдәм итәр һәм бу гамәлгә иҗтимагый оешмалар, юристлар, дипломатлар кушыла алыр иде. Ләкин күчемсез милек хакындагы мәсьәләне ничек тә әле ачыкларга мөмкин булса, мөселман банкларына татарларның акча кертемнәре мәсьәләсен, гомумән, беркайчан да берәүнең дә күтәреп чыкканы булмады.

Шушы барлык сорауларга җавап табу өчен, Россиядәге һәм чит илләрдәге архивларда җентекле эзләнү эше алып барырга кирәк. Әйе, ул ныклап тикшерүне сорый. Әгәр берни дә килеп чыкмый икән, бу да куркыныч түгел. Чөнки без татар тарихына кагылышлы күп нәрсәне ачыклаячакбыз, күп яңалык беләчәкбез.

Әдәбият

1. Русские козыри в чужом кармане. Сколько у России собственности за рубежом? // Российская газета, 2001. — 13 апреля.
2. Сироткин В.Г. Золото и недвижимость России за рубежом. — М., 2000. — С.209.
3. Тагиров И. Восток — дело тонкое // Гасырлар авазы — Эхо веков. — 1998. — №1/2. — С.149-164; Кашапов Р. Вернут ли имущество казанских мусульман? // Конец недели (субботнее приложение к газете «Вечерняя Казань»). — 2001. — 17 февраля.
4. «... Выражаем Вашему высокопревосходительству пожелания непрерывного благополучия» // Гасырлар авазы — Эхо веков. — 1995. — май. — С.154-159; «Счастливая Аравия» глазами советского полпреда. — Шунда ук. — 1996. — №1/2. — С.131-139.
5. Кашапов Р. Вернут ли имущество казанских мусульман? // Конец недели (субботнее приложение к газете «Вечерняя Казань»). — 2001. — 17 февраля.
6. Ибраһимов Г. Тәрҗемәи хәлем. — Казан, 2001. — Б.84.
7. ТР ҮД ТС ДА. Фонд 8233. 2 нче тасвирлама. Архив эше №2-14611. 6, 169, 192 нче битләр.
8. Такой далекий Ближний Восток // Гасырлар авазы — Эхо веков. — 1996. — №1/2. — С.116-130; Гусейнов Р. Миражи в пустыне // Труд. — 2002. — 23 мая.
9. Мекка — священный город мусульман. (Рассказ паломника) // Гасырлар авазы — Эхо веков. — 1996. — №1/2. — С.123.
10. Кашапов Р. Вернут ли имущество казанских мусульман? // Конец недели (субботнее приложение к газете «Вечерняя Казань»). — 2001. — 17 февраля. ■

КЫРЫМ ҺӘМ ИДЕЛ-УРАЛ ТАТАРЛАРЫ АРАСЫНДАГЫ БАГЛАНЫШЛАР

ФИЛҮСӘ АРСЛАН,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Мин дә — сибелгән татарның
Бер газиз баласы ла!
Иделем аша юл сузам —
Чакрымнар арасына!..
Флёра Гыйззәтуллина

...КЫРЫМ ТЕМАСЫ — МИНЕМ ӨЧЕН ЯҢА ТҮГЕЛ, ЧӨНКИ ШАКТЫЙ ЕЛЛАР ИНДЕ КЫРЫМГА БАРЫП ЙӨРИМ, АНДАГЫ ТАТАРЛАР БЕЛӘН АРАЛАШАМ. МОҢА РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ МӘДӘНИЯТЕН, СӘНГАТЕН ҮСТЕРҮГӘ 50 ЕЛДАН АРТЫК ГОМЕРЕН БИРГӘННӘН СОҢ, 1998 ЕЛДА ТАТАРСТАННЫҢ ҺӘМ РОССИЯНЕҢ АТКАЗАНГАН СӘНГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ, ПРОФЕССОР, ОСТАЗЫМ ҖӘВИД АБДУРАИМ УЛЫ КОТДУСОВНЫҢ АК МӘЧЕТ (СИМФЕРОПОЛЬ) ШӘҺӘРЕНӘ КҮЧЕП КИТҮЕ СӘБӘП БУЛДЫ.

Кырым татарлары — дөньяда геноцидка иң көчле дучар булган милләтләрнең берсе. 1783 елда Россия империясе кул астында калгач, Кырым ханлыгы бетерелә һәм бар яктан да югалту гына кичерә. Патша хөкүмәте тарафыннан кырым татарларын ярымутраудан кысрыклап чыгару сәясәте башлана. Шуның нәтиҗәсендә алар Төркиягә, Балканга һәм башка чит җирләргә мөһаҗирлеккә китә. Бер үк вакытта Кырым ярымутравын колонизацияләү үткәрелә. Кырымга Россиянең үзәк губерналарыннан руслар агыла. Шулар белән бергә әрмән, болгар, төрек, немецлар да килеп төпләнә, ә татарлар саны кимегәннән кими. Әлеге процессның кульминацион ноктасы Бөек Ватан сугышы елларында — кырым татарларының ирләре Ватан азатлыгы өчен көрәшкәндә, 1944 елгы депортация (геноцид) була, хатын-кызлар, картлар һәм бала-чагалар туган җирләре Кырымнан куыла. Шуның нәтиҗәсендә кырым татарларының 46,2% һәлак була, депортациянең беренче елларында гына да вафат булучыларның 70%ын балалар тәшкил итә. Бу еллардагы сәясәтнең аерым элементлары бүген дә тормышка ашырылып тора.

Зынҗырлы мәдрәсәсенең (1500 ел) ишеге реставрациягә кадәр. 2006 ел

Зынҗырлы мәдрәсәсенең реставрациядән соң эчке күренеше

«Акчура» җәмгыяте Ялтадагы башка милләт вәкилләре белән дә уртак тел табып, дус-тату яши. 18 майда — кырым татарлары депортацияләнгән көндә — Кырымдагы барлык татарларның бер милләт булып дус-тату яшәүләре аеруча ачык күренә. Аларның фаҗигасе — бөтен милләт өчен зур фаҗига. Бу кайгылы кара датага 2014 елның 18 маенда 70 ел тула.

Украинада 73 мең казан, урал, себер татары яши. Симферополь (Ак Мәчет) шәһәрендә Идел-Урал ассоциациясе филиалы эшләп килә. Егерменче елларда инде Ак Мәчеттә Казан бистәсе булган. Казан татарлары арасыннан Кырым мәдәниятенә үзләренең өлешен керткән шәхесләр бик күп. Партизаннар хәрәкәтләрендә катнашучылар да шактый булган. Ә инде 1944 елда кырым татарларын илләреннән куганда, 6 меңнән артык казан татарын сөргенгә җибәрүләре турында мәгълүмат бар. Бу турыда Рәфыйк Мозаффаров үзенең энциклопедиясендә яза һәм аларның бер өлеше хәзер Кырымга кайтып, күбесе кырым татарлары белән кушылып, гаилә корып яши. Аларны кырым-казан татарлары дип йөртәләр.

Кырым һәм казан татарлары арасында үзара элемтәләр элек-электән даими булган. Ләкин аны яшергәннәр,

Хан мәчете. Бакчасарай

халыкка белдермичә, бер-берсенә каршы куйганнар. Депортация вакытында кырым татарлары өстеннән куелган комендантларның күпчелеге казан татарлары булган. Бу — ике халыкны бер-берсенә каршы кую өчен махсус эшләнелгән сәясәт. Идел татарларының статуссыз калуы, ташламалары булмавы да моңа дәлил.

Хәзер Кырымда үз илләренә кайткан кырым татарларын урнаштыру, аларны җир һәм торак белән тәэмин итү, туган телләренә дәүләт теле статусы бирү, югары дәүләт органнарына үз вәкилләрен сайлау, милли кадрлар әзерләү, мәдәниятне торгызу һәм башка бик күп мәсьәләләрне тормышка ашыру көн үзәгендә тора. Кырымлылар белән аралашып, күп нәрсәне үз күзләрең белән күргәч, аларның чын мәгънәсендә ватанпәрвәр, культуралы, безнең белән чагыштырганда, күпкә оешкан, дус, бердәм халык икәненә инанасың. Әйтергә кирәк, кырым татарлары югары белемлелек буенча Кырымда яһүдләрдән генә калыша. Менә шушы кешеләр бик кечкенә хезмәт хакына эшкә ялланып һәм очраклы хезмәтләр хакына җан асрарга мәҗбүр...

КЫРЫМ МӘДРӘСӘЛӘРЕ ҺӘМ МӘЧЕТЛӘРЕ

Кырым мәдрәсәләрен берничә типка бүләргә була. Иң танылганнары — Бакчасарай мәдрәсәләреннән Хан мәдрәсәсе, Орта, Зынҗырлы, Карасу базар, Керчь, Сары-Әмин шәһәрләре һәм авыл мәдрәсәләре. 1783 елда Хан биләмәсендә 35 мәдрәсә, 1867 елда — 23 (Төркиягә 5 миллион халык эмиграцияләнгәч), ә инде 1893 елда 84 мәдрәсә эшләгән. Шуларның иң танылганы — 2006 елда Төрек фирмасы USRA — Төрек Республикасының халыкара хезмәттәшлекне үстерү идарәсе тарафыннан реставрацияләнгән Зынҗырлы мәдрәсәсе. Ул 1500 елда төзелә. Ни өчен «зынҗырлы»? Аны икенче төрле «Чылбырлы мәдрәсә» дип тә йөртәләр. Бакчасарайның Хан сараеннан ерак түгел, Салачик дип аталган җирдә Зынҗырлы мәдрәсәсен төзеткән хан Миңлегәрәй Хаҗигәрәй улы: «Фән һәм мәгърифәтчелек алдында бөтен кеше баш ияргә тиеш», — дип әйткән. Шуңа да мәдрәсәгә кергәндә, ике якка ачыла торган ишек өстенә беркетелгән чылбыр-зынҗыр аша беркем дә баш ими керә алмаган, фәнгә хөрмәт йөзеннән «Белем Әхрамы»на баш иеп керергә тиеш булганнар.

Урта гасырларда Европада Зынҗырлы мәдрәсәсен кырым татарларының милли университеты итеп кабул иткәннәр. Бу уку йорты Кырым ханлыгының Үзбәк мәдрәсәсе традицияләрен дәвам иткән. Үзбәк хан мәдрәсә-мәчете, Бакчасарайның югары уку йорты барлыкка килгәнче, ике гасыр буе мәгърифәтле кырым элитасын әзерләгән. Зынҗырлы мәдрәсәсендә дә илаһият фәннәре белән бергә астрономия, физика, риторика, математика, фәлсәфә, тарих кебек дөньяви гыйлемнәр укытылган. Заманында әлеге мәдрәсә Европада колледжлар һәм университетлар системасын барлыкка китерүгә һәм үстерүгә этәргеч ясаган.

Кырым татарларының күренекле җәмәгать эшлеклеләре, галимнәре мәдрәсәне үстерү һәм камилләштерү өчен күп көч куялар. Алар арасында күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче, педагог, нашир Гаспралы Исмәгыйль Мостафа улының (1851-1914) роле бәяләп бетергесез. Ул 1868-1871 елларда Зынҗырлы мәдрәсәсендә шәкертләргә белем бирә, 1878-1883 елларда Бакчасарай шәһәре башлыгы булганда да, мәдрәсәне ярдәменнән ташламый. Ә инде 1883 елдан Исмәгыйль Гаспралы наширлегендә һәм мөхәррирлегендә Бакчасарайда дөнья күргән «Тәрҗеман-Переводчик» газетасы Идел-Урал буйларында да тарала башлый. Ул әлеге газета аша гомумтөрки тел булдырырга һәм бар-

Зөһрә Акчурина. Сембер, 1881 ел

Исмәгыйль бәк Гаспралы

ча төрки дөньяны берләштерергә омтыла. Газетаны чыгару эшендә Сембер губернасы Зөябаш авылында туган, И.Гаспралының хатыны, беренче татар хатын-кыз журналист Акчурина Зөһрә Әсфәндияр кызы (1862-1903) да зур роль уйнаган. «Тәрҗеман» газетасын нәшер итүгә Сембер сәүдәгәрләре һәм эшкуарлары Акчуриннар акчалата ярдәм дә иткән. Күрүебезчә, бөтен төрки дөньяга мәшһүр «Тәрҗеман-Переводчик»ның дөньяга танылуында безнең Идел буе татарларының роле бәһасез. Шул ук 1883 елдан мәгърифәтче И.Гаспралы тарафыннан яңа ысул белән укытыла торган җәдиди мәдрәсәләргә нигез салына һәм алар өчен дәреслекләр нәшер ителә. Зынҗырлы мәдрәсәсендә дә укыту җәдитчелек ысулы белән алып барыла башлый. Дөньякүләм мәшһүр әлеге мәдрәсәдә Идел-Урал буе татарларының да гыйлем алуы һәм укытуы мәгълүм.

Октябрь инкыйлабыннан соң большевиклар кырым татарларының «милли университет»ын ябалар. Башта мәдрәсәне шифаханә мәктәбе итеп тоталар, соңрак коммунистлар фиркасе фәрманы белән мәдрәсә бинасы складка әверелдерелә. Ә аның тирәсендәге аерым-ярдәмче бүлмәләрне психик авырулар өчен интернат итеп файдаланалар. Мәдрәсәдә сакланган уникаль китаплар урлану нәтиҗәсендә, гасырлар буена җыелган мәдәни, әдәби мирас юкка чыгарыла. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң большевиклар «Кырым — кырым татарларыннан башка» сәясәтен үткәрә — күп кенә мөселман гыйбадәтханәләрен, матди һәм рухи мәдәният һәйкәлләрен юкка чыгара. Хәтта Зынҗырлы мәдрәсәсе биләмәсендә җирләнгән кырым татарларының юлбашчылары И.Гаспралы һәм А.Озенбашлының рухын рәнҗетүгә дә барып җитәләр...

Алупкадагы мәчетнең язмышы да гыйбрәтле. Аны җирле мөселманнар XVIII гасырда ук төзегән. Мәчеткә тирә-як авыллардан гына түгел, бөтен Кырымнан, хәтта Санкт-Петербургтан ял итәргә килгән кунаклар да йөри торган була. Вакытлар үткәч, бу урынга князь Воронцов кызыга — мәчет урынында зур Сарай барлыкка килә. Ә гыйбадәт йортын яңаны төзиләр. Се-

Ялтадагы мөселман зиратындагы каберташлар

вастополь (Акъяр) юлында урнашкан мәчет Ватан сугышы елларында немецлар тарафыннан җимерелә.

Тагын бер мәчет — Ялтада, А.П.Чехов йортына каршы бинада була. Аның тышкы ягында гарәп хәрефләре белән «1884 ел» дип язылу шул елда төзелгәнлегенә ишарә ясый. Хәзер биредә музыка мәктәбе эшли.

Ялта каласының бүген мөселманнар гыйбадәт кыла торган мәчете Төркиядән килгән мөгаллим Хаҗи Муса җитәкчелегендә төзекләндерелә. Мәчет каршында инде ун елдан артык мәдрәсә эшләп килә, анда гарәп теле һәм ислам нигезләре өйрәтелә. Шәкертләргә Хаҗи Мусадан соң Төркиядән килгән мөгаллимнәр — Хөсәен әфәнде Каракош, Мехмед хуҗа Дагъли белем бирә. Мәчеткә кырым татарлары белән Идел-Урал татарлары да бик актив йөри. 2011 елда «Акчура» оешмасыннан 7 якташыбыз мәдрәсә тәмамлау турында таныклык алды. Мәчеттә ифтар кичәләре дә уздырыла. Олы яшьтә булуына карамастан, мәдрәсәдә белем алган якташыбыз Җәмилә апа Хисамова да дини бәйрәмнәргә, йолаларга багышланган чараларга Коръән укырга чакырыла. Бүген мәдрәсәдә балалар өчен дә курслар эшли.

Ялта шәһәрендә гыйбрәт алырлык урыннар байтак. Без бөтен шәһәр манзарасы күренеп торган мөселман зиратына да бардык. Биредә, нигездә, кырым татарлары, ә соңгы елларда исә Идел-Урал татарлары да җирләнә. Кырым һәм Идел-Урал татарлары берләшеп, бу борынгы зиратның урынын, шәһәр җитәкчелегеннән рөхсәт алуга ирешеп, үзләренә калдырганнар.

Таштагы язмалар кырым һәм казан татарлары телендә гарәп хәрефләре белән язылган, шунда ук Коръәннән аятьләр уелган, ай куелганнары да байтак. Кайбер кабер ташларының арткы ягына мөселман бизәкләре дә уелган.

Каберлекнең эченә кергәч тә, игътибарны уң якка тезелгән кабер ташлары җәлеп итә. Сталин кырым татарларын илләреннән кугач, каберлекне трактор-бульдозерлар белән сөрдереп, ташларын Алупка каласына мәдәни бина төзү өчен ташыганнар. Бу бинаның бары тик кабер ташларыннан гына төзелгәнлеге билгеле. Бина төзелеп беткәч, әлеге эшкә кулы тигән бәндәләрнең төрле сәбәпләр белән үлүе, яисә чирләве турында мәгълүматлар бар.

...Севастопольдәге Акъяр җамигъ мәчетенә нигез салган Исмәгыйль хәзрәт Мөхәммәдрәхим улы Сергач ягының иң күренекле татары була. Ул 1841 елда Сембер губернасы Курмыш

ترجمان

«Тәрҗеман-Переводчик» газетасы

өязе Яңа Мөчәләй авылында мулла гаиләсендә туа. Үз төбәгендәге мәктәп һәм мәдрәсәләрдә белем алганнан соң, авылда әтисе урынына указлы мулла булып кала. Яңа Мөчәләйдә дәүләт казнасы хисабына финанслана торган рус-татар мәктәбе ача. 1881 елда Исмәгыйль хәзрәтне Новочеркасскка имам итеп чакыралар. Өч ел эчендә ул монда мәчет һәм мәктәп бинасы төзетә, үзе ир балаларны, хатыны кызларны укыта. 1885 елда Севастопольгә күченә һәм биредә имам буларак, мөселманнарны оештыручы, бер мәхәлләгә берләштерүче, рухи юлбашчыга әйләнә. Әдәбият галиме Мәсгуд ага Гайнетдин язуынча, Исмәгыйль хәзрәт татарның җәдит мәктәпләренә кадәр үк мәктәп системасын яңарта башлаган алдынгы мәгърифәтчеләреннән берсе булган. Акъяр шәһәрендә мәчеткә нигез салучы һәм аны төзү эшләрен башлап йөрүче дә Исмәгыйль хәзрәт була. Мәчет төзү 1894 елда Кырымда Левадиядә патша Александр III вафат булуы һәм аны Петербургка озатыр өчен Севастопольгә алып килү вакыйгаларына турыдан-туры бәйләнгән. Нәкъ менә Исмәгыйль хәзрәт җитәкчелегендәге мөселманнар делегациясе үлгән патша рухына дога кылыр өчен һәм аңа ядкәр итеп, Севастопольдә мәчет салу тәкъдиме белән хакимияткә мөрәҗәгать итә. Хөкүмәт үз карамагындагы Кырым ислам институтлары вакыфыннан 14 мең акча бирү турында карар чыгара. Мәчет төзү өчен бу акча гына җитмәгәнлектән, Исмәгыйль хәзрәт, ике мәртәбә Идел буйларына китеп, акча җыеп кайта. Улы Йосыфны да, Төркия мәдрәсәләрендә укытып, 1902 елда үз янына мулла итеп урнаштыра һәм мәчет төзү мәсьәләсен бергәләп кайгырта башлыйлар. 1908 елда мәчет өчен җир бирәләр, төзү эшләре башлана. Әтисе 1911 елда хаҗ сәфәрендә вафат булгач, Йосыф хәзрәт аның эшен дәвам итә…

Йосыф Исмәгыйль Хаҗи улы Рәхимов 1870 елда шулай ук Сембер губернасының Яңа Мөчәләй авылында туа. Йосыф авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, Буа мәдрәсәсендә укый, аннан гыйлем алуын Истанбулда дәвам итә. Ул бәләкәйдән бик зиһенле булуы белән аерылып торган, төрле телләрне һәм фәннәрне өйрәнүгә сәләте белән сабакташларын таң калдырган. Йосыф Истанбулдагы уку йортын тәмамлаганда, 6-7 телдә иркен сөйләшкән, медицинаны һәм башка фәннәрне яхшы белгән. Истанбулга эш белән килгән танылган татар мәгърифәтчесе, «Тәрҗеман-



Переводчик» газетасы мөхәррире Исмәгыйль Гаспралы аны Севастопольгә әтисе янына хезмәт итәргә кайтырга күндергән. Йосыф, Идел буена, туган якларына кайтып, Фатыйма дигән гүзәл кызны кәләшлеккә алып килгән дә Севастополь өязе казые эшенә җиң сызганып тотынган. Ул 1909 елдан мәчет каршындагы мәктәптә мөгаллим булып эшли, соңрак Севастополь татар халык мәктәбе директоры була. Хәзрәт мәктәбендә дини дәресләр белән бергә математика, физика, химия фәннәре дә укытылган, дәресләр татар, рус, фарсы, француз телләрендә алып барылган. Йосыф Исмәгыйль улы үзе балаларга тарих һәм география фәннәрен укыткан. Мәктәптә кырым татарлары белән бергә казан татарлары да белем алган.

1914 елның 20 апрелендә мәчетне рәсми рәвештә тантаналы ачу мәҗлесенә шәһәр түрәләре, руханилар килгән. Тантанада хәтта император Николай IIнең дә катнашканлыгы мәгълүм. Яңа мәчеткә мулла итеп тәгаенләнгән Йосыф хәзрәткә ул Романовлар династиясе тәхеткә утыруның 300 еллыгына чыгарылган альбом бүләк иткән, балаларының башларыннан сыйпаган (кызганыч, бу альбом дәһрилек чорында юкка чыга). Шулай итеп Кырым халыклары арасында «Рәхим бәй» дип йөртелгән Йосыф хәзрәт мөселманнарның мәгърифәтчесенә әйләнгән.

Мәчет ике балкон белән күпкырлы челтәрле манарадан гыйбарәт. Төп керү ишеге аркасына «Александр III истәлегенә» дип язылган. Мәчет проекты шәһәр архитекторы А.М.Вейзен һәм Г.Н.Долин тарафыннан, Каһирәдәге әл-Әзһәр мәчетенә һәм университетына охшаш типта Мисыр һәм Төньяк Африка архитектура үзенчәлекләрен саклап, Мисыр-мәмлүк стилендә төзелгән.

Мәчет Кара диңгез флоты хәрбиләре һәм җирле мөселманнар өчен хезмәт иткән. Тагын шунысы да мөһим: Кара диңгез флотында 30 елдан артык ахун булып торган Мөхәммәдзаһир Җамалетдинов та безнең төбәк татары — Казан губернасы Спасс өязе Яңа Чаллы авылыннан (хәзерге Әлки районына керә).

Россия мөселманнарының хаҗ сәфәре юлы Севастополь аша үтү сәбәпле, мәчеткә кереп намаз уку күркәм гадәт булган. Шулай ук Бохара әмиренең дә 1912-1915 елларда хаҗ юлында Йосыф имамда кунак булып, аңа атлас чапан бүләк итүе турында мәгълүматлар бар.

1930 еллардан мәчетләрне юкка чыгару, аларны ябу аерым план белән алып барыла, Йосыф хәзрәт һәм аның гаиләсе өстеннән дә күзәтү, эзәрлекләүләр көчәя. 1937 елның 2 октябрендә Йосыф Рәхимов кулга алына һәм Севастополь төрмәсенә ябыла, ә 1938 елның 10 февралендә аны атарга дигән хөкем карары чыгарыла. 1956 елда Фатыйма Рәхимова СССР Министрлар Советы каршындагы Дәүләт куркынычсызлыгы комитетына иренең эшен яңадан карау хакында мөрәҗәгать иткәч, Йосыф хәзрәткә бирелгән үлем җәзасының 10 ел төрмә белән алыштырылганлыгы, аның



1943 елның 19 февралендә төрмәдә йөрәк өянәгеннән вафат булганлыгы ачыклана. Ул 1957 елның 5 февралендә генә реабилитацияләнә. Йосыф хәзрәт — үз нәселләрендәге уникенче буын дин әһеле, кызганычка каршы, соңгысы була...

1938 елның 24 июлендә Севастополь шәһәре Советы Президиумының карары нигезендә, мәчет гыйбадәтханә буларак халыкка хезмәт итүдән туктый, әмма аның ике балконы белән күпкырлы челтәрле манарасы саклана. Бөек Ватан сугышы вакытында Севастополь шәһәре җир белән тигезләнгән дияргә була. Бары тик өч бинасы — мәчет, шәһәрнең «капкасы» булган колонналар һәм Кара диңгез флотының төп бинасы гына исән кала. Фәкать 1948 елда гына Сталин фәрманы белән шәһәрнең уртасындагы мәчет манарасы ике ай буе көрәк-ломнар ярдәмендә җимертелә. Мәчет бинасы Кара диңгез флоты архивы карамагында кала... 1989 елда үзгәртеп кору чорлары башлангач, кырым татарлары туган җирләренә кире кайта башлый. 1991 елдан әкренләп милли үзидарә системасы торгызыла. 1992 елда Севастополь мөселманнары архивның икенче катында җомга намазын укый башлый, ә 1994 елда мәчет тулысынча татарларга бирелә. 1995 елда мәчетне төзекләндерү эшләре башкарыла. 2000 елда Истанбул иганәчеләре ярдәме белән яңа манара да төзелә.

Әдәбият

1. Гайнетдин М. Гасырлар мирасы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. — Б.120-124.
2. Кудусов Эрнст. Москва и Крым: Очерк истории взаимоотношений двух наций — великороссов и крымских татар. — Москва, 2002. — 88 с.
3. Джавид Кудусов: материалы, статьи, воспоминания / сост. Ф.Арсланова, И.Ковалева. — Казань, 2009.
4. Али Э. Путешествия по неизвестным страницам истории Севастополя. — Симферополь, 2010. — 112 с.
5. Фесенко А. Севастопольская мечеть: http://new-sebastopol.com/news/sevastopol/Sevastopol_skaya_mechet_
6. Ганкевич В. Ю. Крымскотатарские медресе: http://crimeantatars.com
7. Новая жизнь Зынджырлы- медресе: http://gazeta.zn.ua/CULTURE/novaya_zhizn_zyndzhyrly-medrese.html
8. Юныс М. Альбатрос язмышы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. — 383 б.

Ахыры киләсе санда

«БӘКЕР» ШИФАХАНӘСЕНӘ 80 ЕЛ

ТЫЛСЫМЛЫ ТӨБӘК МУЗЕЕ

Бәкер китте саз буена,
шунда алачык корды...
Ханның яралы атларын
ләм сылап савыктырды...
«Бәкер сазы» (Р.Харис).*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ БИРГӘН МӘГЪЛҮМАТЛАРГА КАРАГАНДА, БҮГЕН РЕСПУБЛИКАБЫЗДА 1065 ШӘХСИ ҺӘМ КОРПОРАТИВ МУЗЕЙ (ДӘҮЛӘТ КАРАМАГЫНДАГЫЛАРЫ — 128) БАР. НИГЕЗДӘ, БУ МУЗЕЙЛАР БЕР ОЕШМАГА КАРЫЙ ҺӘМ ШУЛ ОЕШМАНЫҢ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ, САКЛАУ, ПРОПАГАНДАЛАУ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘ.

*Риваять-поэма белән «Чын мирас» журналының 2013 елгы 1 нче санында (82-85 битләр) таныша аласыз.

Шундый күркәм мәдәният учакларының берсе — «Бәкер» шифаханәсе музее. 2008 елда «Бәкер» шифаханәсенең 75 еллыгы уңаеннан ачылган әлеге музей үзе дә тарихи бинага — курортның 1950 елларда төзелгән беренче конторасына урнашкан. Без бу музейның мөдире **Гөлсия ханым Саримова** белән әлеге музей, музейда шифаханә тарихын өйрәнү тәҗрибәсе, гомумән, «Бәкер»нең бай үткәне турында сөйләшергә булдык.

– Хөрмәтле Гөлсия ханым, дәвалау учреждениеләренең үз музейлары булу бик сирәк күренеш. Шифаханәдә шундый бай, эчтәлекле музей оештырып җибәрү идеясе кайчан туды? Музей оештыруда кемнәр зур роль уйнады?

— Музей ачу уе Фаяз Ибраһим улы тарафыннан 2000 елларда ук күтәрелгән иде. Тик әле ул вакытларда бүгенге музей бинасы торак йорт ролен үти иде, шуңа бу мәсьәлә, яңа торак йортны җиткереп, хезмәткәрләрне шунда күчергәч, яңадан кузгатылды. Музей өчен 3-4 фоторәсем, приказлар китабы һәм кемнәрдер тарафыннан язып калдырылган ике-өч язма гына бар иде. Җитмәсә ветераннарыбызның да күбесе мәрхүмнәр. Ничек курыкмыйча ышанып эш башлаганбыздыр… Бүген үзем дә гаҗәпләнәм. Җитәкчебез Фаяз Ибраһим улының ышанычы һәм бигрәк тә һәр тәкъдимне күтәреп ала белүе, рухи һәм матди яктан һәрчак ярдәм кулын сузуы кыска гына вакыт эчендә зур эшләр башкарып чыгарга мөмкинлек бирде. Чын-чынлап изге эшкә алынганбыз ахрысы, эш искитмәле күтәренке рухта һәм бик нәтиҗәле дәвам итте. 2008 елның февраль азагында беренче тапкыр музей булачак йортның ишеген ачып кергәнемә әле һаман да ышанып бетә алмыйм… Ә инде 2008 елның 5 сентябренә музей үзенең беренче кунакларын кабул итте. Бу эштә төп ярдәмчеләрем булган авылдашларыбызга, бик күп еллар дәвамында Бәкер җиреннән сихәт алучы кунакларыбызга, шифаханәнең ветераннарына, музейны бизәүдә һәм экспонатларны урнаштыруда искиткеч зур ярдәм иткән Чирмешән егетләре — бертуганнар — рәссам Фәйзелхакка, агач эшләре остасы Җәлилгә, макетлар ясаучы оста Муса Вилдановларга олы рәхмәтемне һәм хөрмәтемне белдерәм. Мине әлеге изге эшне башкарып чыгарга ышанып чакырган һәм онытылмас ачышларга, яңалыкларга бай булган музейны оештыру, анда эшләү елларын бүләк иткән Фаяз Ибраһим улы Ибраһимовка аеруча рәхмәтлемен.

– Республикабызның күп кенә музейлары төбәкнең борынгы тарихыннан яки шул районның хәзерге җитәкчесенә дан җырлаудан башланып китә. Ә Сезнең музейга керүгә, ат арбасы һәм атны җигү әсбаплары үзенә җәлеп итә. Моның сере нидә?

— Нәкъ менә ат арбасы — безнең үткәнебез, «Бәкер» шифаханәсенең беренче трамплины. Беренчедән, 1933 елдан алып 1963 елга кадәр Бәкер сазын ат һәм арба белән күтәргәннәр, икенчедән, 1956 елга кадәр «Бәкер» хезмәткәрләре үзенең кунакларын, дәваланырга килүчеләрне Шынтала һәм Бөгелмә станцияләреннән ат һәм арба белән алып килгән. Өченчедән, шифаханә оешкан көннән үз ярдәмче хуҗалыгы булган. Нәтиҗәдә, 1984 елга кадәр дәваланучыларны тукландыруга кирәкле барлык төр азык-төлек белән дә «Бәкер» үз-үзен тәэмин иткән. Биредә шул чордагы татар авыллары өчен гадәти булмаган яшелчә, җиләк-җимеш бакчалары гаҗәеп күренеш саналган һәм бу эшкә 1935 елларда монда килгән «сәяси яктан ышанычсыз кешеләр» ярдәм иткән. Баштарак җиләк-җимешне бакчаларда үстерсәләр, соңрак зур күләмле парник-теплицалар да төзеп куйганнар. Ярдәмче хуҗалык эшендә дә иң төп көч, транспорт — ул ат һәм арба. Дүртенчедән, 1960 ел-

Шифаханәнең Максим Игнатьев төзеткән бинасы

Бөек Ватан сугышы елларында яралыларны дәвалау

ларга кадәр «Бәкер»нең төп ягулыгы утын булган, ә утынны урманнан шифаханәгә китерү эшен, әлбәттә, ат һәм арба башкарган. Менә шуның өчен без ат һәм арбаны беренче трамплиныбыз дип саныйбыз. Гомумән, безнең төбәкнең дөньяга даны таралу да аттан башланган (Болгар ханының авыру атлары Озын күл буенда савыгуын искә төшерик. — *Ред.*), ат һәм арба белән Европа дәрәҗәсендәге шифаханәгә килеп җиттек. Бүген дә безнең биредә хезмәт күрсәтүче атыбыз бар. Шушы ук экспозициядә бәкерлеләрнең ләм чыгару эшендә беренче кулланган әйберләре — тастымаллар, эскәтер, фонарь, агач көрәк һәм чиләк кебек предметлар да урын алган. Гади генә фонарь дә күп тарихи вакыйгаларның шаһиты. Беренче елларда биредә 60 кеше берьюлы дәваланган, ә хезмәт күрсәтүчеләрнең саны бер дистә чамасы гына булган. Дәваланучылар күп булу сәбәпле, ләмне, казып

алып, аларга җиткерер өчен, эшне иртәнге сәгать икедә башларга туры килгән. Ләмне бары тик агач көрәкләр ярдәмендә казыганнар һәм бер урыннан икенчесенә дә агач чиләкләр белән күчереп йөрткәннәр. Бер ат арбасына 20 чиләк ләм сыйган — моны биредә эшләгән өлкән буын вәкилләре әле дә хәтерли. Бәкер ләмен авыруларга тәкъдим итү алдыннан турыдан-туры утка куеп җылыту ярамый, чөнки табигый матдәнең сыйфаты бозыла, дәвалау куәте кими. Шифаханә янында шушы ләмне җылыту системасы булган: табигый ташлардан зур чан ясаганнар, аның эченә 20 чиләк ләмне тезеп куйганнар. Чанга ике яклап кайнап утырган зур казаннардан пар кергән, ике метрлы агачларны яндырып җылытыла торган шул казаннарда көне-төне су кайнаган. Чан авыр имән капкачлар белән капланган. Пар тагын да авырайткан имән капкачларны берничә мәртәбә ачып ябу зур физик көч таләп иткән. (Сугыштан соң гына күмер белән җылытыла торган пар казанлы котельная төзелә һәм ләм торбаларда җылытыла башлый.) Ләмне сазлыктан чыгару, пар белән җылыту кебек авыр эшләрне хатын-кызлар башкарган. Эш катлаулы булса да, «Бәкер» шифаханәсендә бер генә кешене дә дәваламыйча калдырмаганнар.

– Бу тирәдә күлләрнең, аеруча андагы ләмнең тәнгә сихәте безнең борынгы төрки бабаларыбызга берничә гасыр элек үк мәгълүм булган. Әмма моннан 80 ел элек шифаханә оешып китү һәм «Бәкер»нең үсеше кемнәр белән тыгыз бәйләнгән?

— Мин, музей хезмәткәре буларак, тирә-як авыллар тарихын һәм шифаханәдә хезмәт иткән, биредә лаеклы эз калдырган һәр кешенең тормыш юлын өйрәнеп чыгарга тырыштым. Гомумән, дәвалау эшендә әлеге төбәктә яшәүче һәрбер кешенең дә өлеше зур булган. Бәкер һәм аның тирә-як авылларындагы кешеләр — алар искиткеч шәфкатьле бәндәләр. Бу җирләргә сихәт эзләп, елап-сыктап, ярымгарип килгән сәламәтләнүчеләрне үз итеп, якын күреп кабул итү, йортыңа кертү, сазлыкка алып килеп, күрсәтмәләр биреп дәвалау җирле халыкның аңына кергән.

80 ел эчендә шифаханәдә 24 өлкән табиб хезмәт куйган (1945 елга кадәр алар директорлар, ә аннан соң баш табиблар дип аталганнар). Шуларның өчесе хәрби табиб булган. Ә музей эчендәге аллеяга баш табибларның унысының гына рәсеме куелды. Чөнки нәкъ менә алар 3 елдан күбрәк хезмәт иткән һәм һәрберсе дә эш-гамәлләре белән «Бәкер» тарихында тирән эз калдырган. Иң беренчесе — «Бәкер»не шифаханә буларак дөньяга таныткан кеше — Максим Игнатьевич Игнатьев.

Төбәктә трахома, тиф, холера авырулары котырган бер дәвер — 1928 елда Максим Игнатьевич Иске Куак хастаханәсенә эшкә кайта. Беренче көннәрдән үк ул Бәкер ләме, суларының шифасы турында ишетә. Анда үзе барып, җирле халыктан ләм белән дәвалану ысулларын өйрәнеп, туплаган мәгълүматлар турында Татарстан Сәламәтлек саклау халык комиссариатына мөрәҗәгать итә. Әмма тиешле җавап килми. Шуннан табиб «Бәкер»нең беренче хезмәткәрләре — Хаҗип һәм Фатих Фәсхетдиновларны эшкә ала, аларга Иске Куак хастаханәсенә Бәкер ләмен һәм суын ташу вазифасын йөкли, үзе авыруларны дәвалый башлый. Максим Игнатьевич 1930 елда Бәкернең ләмен һәм суын Сочи каласындагы махсус лабораториягә алып бара. Аннан кайткач, яхшы дип бәяләнгән анализ һәм үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән Казанга юнәлә. Шул ук елның 19 июнендә ТАССР Халык комиссарлар советының утырышында курорт төзү хакында указ чыгарыла һәм Максим Игнатьевич аның беренче директоры итеп раслана. Шул карардан соң

«Бәкер» курортының төзелеш планы эшләнә. Беренче су һәм ләм белән дәвалау корпусы кулак дип саналган дүрт кешенең йортларыннан җыела. Хәзер сез бу йортларның фрагментларын ачык музейда күрә аласыз. 1933 елның 25 августында шифаханә үзенең беренче авыруларын кабул иткән, ә 1934 елда курорт хезмәткәрләре дәваланырга килүчеләрне үзенең ярдәмче хуҗалыгын аякка бастырып каршылый. Истәлекләргә караганда, бирегә килгән һәр кешене беренче өч көн бик шәпләп, себеркеләп мунча керткәннәр, шуннан соң табиб кабул иткән, анализлар тапшырткан. Бары тик дүртенче көнне генә «Бәкер» кунаклары аның дәва чыганаклары белән очрашкан. Дәвалану вакыты 25 көн булган. Шифаханәдә 3 табиб, 4 шәфкать туташы эшләгән. Бөгелмә, Казан, Чистай, Самара, Алабуга шәһәрләреннән җәйге ял вакытларында бирегә акча эшләргә килгән белгечләр бик еш алмашынып торган. Аларны җирле халык фатирга керткән. Шунысын да әйтергә кирәк: җирле халык беренче елларда курортта бик эшләмәгән. Бу мөселманнарга чит кешенең шәрә тәненә карарга тыелу белән аңлатыла. Шунлыктан хезмәткәр ләр Иске Куак, Федотовка, Кузьминовка авылларыннан килгән. Бары тик сугыш елларында гына Бәкер авылының 14-15 яшьлек татар кызлары биредә эшләргә мәҗбүр ителгән.

1941 елның 22 июнендә сугыш башлану сәбәпле, 28 июньдә «Бәкер» шифаханәсе ябыла, дәвалау бүлеге эшчеләре дә хезмәттән азат ителә, әмма ярдәмче хуҗалыкта эш туктамый. Сакланып калган приказ кенәгәләрендәге документларга караганда, бу елның җәендә эшчеләргә маллар өчен печән, кыш ягарга утын әзерләү максат итеп куела. Август аенда почта, клуб, китапханә хезмәткәрләрен, кастеляншаларны эштән кыскарталар. Шул ук документларда 8 хезмәткәрнең Ватан азатлыгы өчен сугышка китүе билгеле. Ярдәмче хуҗалыктагы дуңгызларны, мөгезле эре терлекне сарыкларга алмаштырып, «Шушма» күмәк хуҗалыгына тапшыралар. Җитмәсә иң яхшы дүрт атны фронтка алалар. Авырлыкларга да карамастан, шифаханәнең ярдәмче хуҗалыгы 1942 елның маена 73 баш сарык, 4 баш ат, дистәдән артык тавык, чәчүлек бәрәңге саклап кала, хәтта сугышка кадәр әзерләнгән чәчәк орлыкларын да утырталар.

Шул ук елның май аенда шифаханә нигезендә 49-14 нче номерлы эвакогоспиталь оеша. Җәй айларында самолётларда иң авыр хәлдәге яралыларны — нигездә, умыртка баганасы, янбаш һәм сөяк-буын яралары белән «Бәкер»гә алып килә башлыйлар. 1942 елның 1 июненнән октябренә кадәр дәвалану вакыты 24 көн, ә авыр җәрәхәтлеләргә 48 көнгә кадәр булганлыгы билге. Шуның өстенә кышын фронт өчен бәрәңге киптереп озатканнар, шикәр ясаганнар. Бу елларда биредә фронт сызыгыннан тылга озатылган кешеләр дә хезмәт куйган. Алар арасында безнең төбәк өчен ят фамилиялеләр — Н.П.Шрейберей, З.Швейкина, М.Дейкова, О.С.Лаврова, Аборбонел, Нахимчук — эшләве, хәтта танылган татар язучысы Гадел Кутуйның хатыны А.С.Кутуеваның аз гына булса да өлкән табибә вазифасын башкаруы билгеле. Ә гади хезмәткәрләрне, нигездә, 50 яшьтән узган хатыннар һәм 14-15 яшьлек кызлар тәшкил иткән, чөнки урта буын авыл хуҗалыгы, нефть тармагыннан китә алмаган, ә ирләр сугышта булган. Мин еш кына бу дәвердә эшләгән кешеләрдән: «Иң авыры нәрсә булды?» — дип сорыйм. Алар: «Иң авыры «Бәкер» җиренә, аның дәвасына ышандыру иде», — диләр. Чөнки «Бәкер» ләме белән дәвалану өчен, үзеңне психологик яктан да, рухи яктан да бик нык әзерләргә кирәк. Бөек Ватан

сугышы елларында шифаханә ике мең ярымнан артык яралы солдатка җан өрә. «Бәкер»нең суы, ләме һәм хезмәткәрләренең җылы мөгамәләсе аларга зур сихәт биргән, егетләрне бик тиз аякка бастырып, фронтка озаткан. Врач-хирург Земляницын һәм аның белән эшләүче шәфкать туташлары В.Юртаева белән Ф.Нерухның гына да сезон саен 60тан артык авыр тән җәрәхәте алган хәрбиләргә ярдәм күрсәтүләре ачыкланды.

«Бәкер»нең сугыш елларындагы тагын бер казанышы — биредә 1943 елга кадәр сөяк-буын авыруларын гына дәвалаган булсалар, 1944 елда, «Бәкер» курортында эшләгән атаклы шәхесләрнең хезмәт нәтиҗәсендә, гинекологик һәм бала таба алмау чирләреннән савыктыру программалары да өстәлә. Алар бүген дә иң уңышлылардан санала. Тагын шунысын да билгеләп китәргә кирәк: госпиталь көндез яралыларны дәваласа, төнге сәгать икедән иртәнге сигезгә кадәр һәм кичен сихәт эзләп килгән җирле халыкка (күбрәк хатын-кызлар булган) ярдәм күрсәткән. Музейны оештырып эшли башлаган елда, әнисе «Бәкер»дә дәвалану нәтиҗәсендә туган беренче баланы эзләп табарга дип бурыч куйган идек. 1940 елларда дөньяга килгән баланы таба алмасак та, 1950 елда туучының кем икәнен белү насыйп булды.

Сугыш тәмамланганнан соң, биредә эшләүчеләр арасында фронтовикларның саны арта, гимнастёркалы ир-егетләр күренә башлый. Райком ярдәмендә шундый егетләрдән төзелеш бригадасы оешып, киң колач белән ремонт-төзелеш эшләре җайга салына. Тиздән физик дәвалау өчен дүрт бүлмәле бина, җиләк-җимешне сакларга подвал булдырыла, кышкы корпус төзелә башлый. Сугышка киткән атларның кире кайтуы приказ кенәгәләрендә аларның кушаматлары теркәлүдән мәгълүм. Шифаханә тормышы акрынлап җайлаша. 1945 елның сезоны азагында биредә хезмәт итүчеләргә хәтта йөзәр сум премия дә бирәләр. Сугыштан соң малларның саны арттырыла, яшелчә мәйданнары киңәя. Дәваланучылар туйганчы ит һәм бәрәңге ашый башлый. Алай гына да түгел, биредә эшләүчеләрнең дә тамак ягы кайгыртыла. Бу елларда да шифаханәгә эшкә иң көчле травматологлар, ортопедлар, гинекологлар килә. Алар арасында профессор Шәрәф, профессор Камай Терегулов, гинеколог Мөршидә Монасыйпова, Лидия Константиновна Дуг кебек республикабызда танылган табиблар бар. Максим Игнатьевичның фронттан кайтып эшкә керешүе шифаханәгә яңа сулыш өрә.

Җитәрлек дәрәҗәдә азык белән тәэмин ителү сәбәпле, тирә-яктагы татар авыллары халкы да биредә эшләргә омтылган. 1948 елда шифаханә эвакогоспиталь статусыннан үзенең элеккеге дәрәҗәсенә — «санаторно-курортное грязь-бальнеологическое лечебное учреждение» исеменә кайта. Сугыштан соңгы тернәкләнеп китү эшләрен оештыру башында врач-хирург, фронтовик Фәридә Фәйзелгаян кызы Кильматова тора. Ул 1945 елда табибә буларак «Бәкер»гә җибәрелә һәм икенче сезонда баш табиб итеп тә тәгаенләнә. Соңгы елларда, шифаханәнең тарихын өйрәнгәндә без бу шәхеснең исән-сау булуын, аның Казанда яшәвен белдек. Ике дә уйлап тормыйча, 90 яшьлек Фәридә ханым янына Казан каласына юл тоттык. Ул музей фондына шул чорларга нисбәтле фоторәсемнәр, документлар, язмалар тапшырды, үзенең хатирәләре белән дә уртаклашты. Сугыштан соңгы елларда Фәридә апа үзе дә «Бәкер»дә дәвалана һәм 1950 елда кызын — Галияне алып кайта. Фәридә апаны без 2009 елда «Бәкер суы» бәйрәменә чакырдык, ул бездә 10 көн ял итеп, дәваланып китте, кызганыч, шул елның декабрендә вафат булды. Бу шәхес белән күрешеп, аралашып

калу тарихтагы күп кенә ак тапларны бетерергә ярдәм итте.

XX гасырның икенче яртысында шифаханәне гөрләп үсә, дип әйтергә була. Татарстан Республикасында эре сәнәгать оешмалары барлыкка килә, алар каршында профсоюзлар оеша, ә алар үз хезмәткәрләрен ял итәргә шифаханәләргә җибәрә башлый. 1951 елда биредә койка-урыннарның саны 100гә, 1959 елда 150гә кадәр җитә, 50-60 нчы еллар чигендә шул ук сандагы урыннарга исәпләнгән ашханә һәм клуб, 14әр урынга исәпләгән 3 җәйге йорт төзелә, «Сихәт» чишмәсенең суы өчен беренче такта павильон ачыла, клуб каршына фонтан да ясала, ап-ак мәгърур сыннар барлыкка килә. 1966 елда хуҗалык корылмалары, су һәм ләм белән дәвалау бинасы төзелә, дәваланучыларны кабул итү мөмкинлеге 230га кадәр арттырыла, биредә ел әйләнәсендә дәвалау оештырыла. Ә 1969-1979 елларда яңа йокы корпуслары, эшчеләр өчен торак йортлар, 300 урынга исәпләнгән, бию залы булган клуб, 50 урынлы балалар бакчасы төзелә, су асты массажы, су астында умыртка баганасын тарттыру кебек яңа дәва төрләре гамәлгә керә. 80 нче еллар азагында да үсеш дәвам итә: 3 нче корпус төзелә, «Бәкер»нең данлыклы «Утлы суы» дәвалау программасына кертелә. 1991 елда ике скважинадан составында натрий, магний, кальций, сульфат ионнары булган «мацеста» тибындагы су чыгарыла һәм дәвалау процессында файдаланыла башлый. Бу эшләрне оештырган табибларның (баш табиблар — Фәридә Янгуразова, Фәүзия Камалетдинова, Фәрит Әюпов, Тамара Федотова, Фазыл Әхмәров, Виктор Одушкин, Николай Андрияшин, Фердинанд Әхмәтҗанов, Рәшит Абашев, Наил Хәйретдинов) һәм хезмәткәрләрнең тормыш юллары, кыскача биографияләре, эшчәнлекләре музей стендларында һәм экспозицияләрдә фотодокументлар, шәхси предметлар, истәлек-хатирәләр ярдәмендә җентекле яктыртылган.

– Киләсе елга «Бәкер» шифаханәсенә баш табиб Фаяз Ибраһим улы Ибраһимовның килүенә 20 ел була. Бу бер кеше гомере өчен аз вакыт түгел. Шифаханә 90 нчы елларда базар икътисадына ничек яраклашты? Гомумән, соңгы 20 елда тарих сәхифәләренә кереп калырлык нинди зур вакыйгалар булды һәм бу чордагы казанышларны музейда ничек күрсәтәсез?

— Безнең «Бәкер» шифаханәсе 1967 елдан профсоюзларга кертелә. Шифаханәгә барлык юлламаларны да профсоюзлар тарата. Ә 90 нчы еллар башында, Советлар Союзындагы барлык шифаханәләр кебек үк, безнеке дә бик авыр хәлдә калды, чөнки профсоюзларның эшчәнлекләре сүлпәнәйде. Менә шул вакытта «Бәкер»гә дә юлламаларны таратучылар булмады. Шулай итеп, 1994 елда Фаяз Ибраһим улы Ибраһимов, җайга салынган эшләрен ташлап, әлеге җимерелеп барган оешманы үз канаты астына алды һәм бик кыска арада аякка да бастырды. 1990 елларда безнең «Бәкер»не эре сәнәгать оешмаларына бирү турында сүз кузгатылды. Шифаханәне эре ширкәтләр дә, шәхси эшкуарлар да сатып алырга теләде, аеруча моның белән нефтьчеләр кызыксынды. Фаяз Ибраһим улы исә, профсоюзларны җәлеп итеп, шифаханәне саклап калды. Чөнки шифаханә профсоюзларныкы булганда гына, анда һәркем дәваланырга мөмкин. Ул юлламаларны үзебездә ясатып, бөтен Союз буенча җитештерүне дәвам иткән хуҗалыкларны эзләп тапты, алар җитештергән товарны шифаханә юлламаларына алмаштырып бирү нәтиҗәсендә, дәваланырга килүчеләрнең саны арттырылды. Соңгы 20 елдагы казанышларны күрсәтер өчен, без кунакларга шифаханә буенча экскурсияләр үткәрәбез. Ә үсеш-үзгәрешләр күзгә бәрелеп тора: кыска гына вакыт эчендә дәвалау, яшәү,

Музей бинасы

админстратив-хуҗалык корпуслары, сәламәтләндерү үзәге аякка бастырылды, җылы переходлар, кечкенә зоопарк, дендробакча, заманча кунак йортлары һәм спорт мәйданчыклары, Каенсар күле, сероводородлы су бассейны, SPA салон төзелде, тау шуу комплексы, хоккей мәйданчыгы, машиналар кую өчен урыннар, терренкурлар (җәяүлеләр өчен махсус сукмак) булдырылды һәм барлык яшәү корпусларында, заманча реконструкция үткәрелеп, капиталь ремонт ясалды. Бик күп яңа дәвалау программалары кертелде. «Бәкер»нең ләме, борынгы бабаларыбыз дәваланганча, авыруларга су белән кушылып бирелә башлады, минераль сулы чишмә — «Бәкер суы» һәм зәңгәр балчык дәвалау программасына кертелде. «1», «2», «3 спальный корпус» дигән язулар урынына «Аккош», «Тургай», «Сандугач» исемнәре, ә яңасының «Карлыгач» атамасы белән барлыкка килүе баш табибыбызның ни дәрәҗәдә милли җанлы шәхес икәнлеген күрсәтә. Безнең үз музеебыз оештырылды, тарихны җентекләп өйрәнү эше башланып китте. Шифаханәнең 1930 елларда төзелгән агач биналары, концервацияләнеп, аерым түбә астына алынды, шуның нәтиҗәсендә үткән белән хәзергене

«Бәкер» шифаханәсенә нигез салучы Максим Игнатьевка куелган һәйкәл

чагыштырып карар өчен менә дигән мөмкинлек тудырылды. Иске агач биналарны музей объекты буларак саклау — Татарстанда гына түгел, ә Россия Федерациясендә бик сирәк күренеш. Гадәттә бина искерә икән, аны сүтеп ташлау ягын гына карыйлар... «Бәкер» шифаханәсенә нигез салучы Игнатьев Максим Игнатьевичка, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга, бу елларда «Бәкер»нең эвакогоспиталь булуын искәрткән истәлек ташлары һәм такталары куе-

лу үткәннәргә, биредә эшләп киткән өлкән буын вәкилләренә чиксез хөрмәт булуы турында сөйли. Әгәр дә әлеге шифаханә берәр кешенең яки сәнәгать оешмасының шәхси милкенә әйләнгән булса, биредә музейлар оештыру, тарихны өйрәнү, мәдәниятне үстерү, монда эшләп киткән шәхесләрнең исемнәрен мәңгеләштерү турында хәтта сүз дә кузгату мөмкин булмас иде. Соңгы егерме елда «Бәкер» Татарстан Республикасында гына түгел, ә Россия Федерациясе, хәтта дөньякүләм уникаль шифаханә булып танылды. Фаяз Ибраһим улы — «Бәкер» шифаханәсенә беренче нигез салган Максим Игнатьевның дәвамчысы, аның уй-хыялларын заманча югарылыкта тормышка ашыручы мөхтәрәм шәхесләребезнең берсе. Танылган драматургыбыз Туфан ага Миңнуллин аның турында: «Фаяз Ибраһим улы — кешеләргә бик игътибарлы, мәгънәле җитәкче. Шуның нәтиҗәсе буларак, шифаханә бүген иң популяр ял итү һәм дәвалану үзәге. Киләчәк менә шундый җитәкчеләр кулында булса гына, уңышларга ирешәчәкбез!» — дип язган иде. Җитәкчебез һәм хезмәткәрләрнең тырыш хезмәте нәтиҗәсендә, «Бәкер» шифаханәсе 80 яшен 30лап алтын медаль һәм ярты дистә көмеш медаль кавалеры буларак каршылый.

– Еш кына «Бәкер» турында сөйләгәндә, аны «Җиде могҗиза иле», диләр. Монда нинди могҗизалар турында сүз бара? Бәкер җиренең сере нидә?

— Мәгълүм ки, безнең музей — дәвалау учреждениесе музее. Шунлыктан, биредәге һәрбер бина сырхауларга савыгырга ярдәм иткән кебек, безнең музей да кешеләрне дәвалау процессыннан читтә кала алмый. Бирегә килгән бер кешенең дә музейны читләтеп үткәне юк. Безнең әби-бабаларыбыз элек-электән, авырып китсәләр, төрле таблеткалар белән түгел, ә табигатьтә үскән үләннәр ярдәмендә дәваланырга омтылганнар, табигатьтән җан тынычлыгы тапканнар. Ә адәм баласының җаны сау-сәламәт булганда, тәне дә сәламәт. Табигать гомер буе кеше организмын чистартып, аңа яңа көч, омтылыш биреп торган. Хәзерге заман кешесе табигать ярдәмендә үз организмын чистарта аламы? Биредә табигый чыганакларны кулланып сихәт алу өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. «Бәкер» җирендә без кешеләрне табигатькә якынаерга һәм аңа икенче күз белән карарга өйрәтәбез.

Дөньякүләм мәгълүм ФЕМТЕК (Всемирная федерация водолечения и климатолечения) оешмасы бар. Алар Җир шары буенча дәваланырга ярдәм итә торган тере һәм үле табигый факторларны эзлиләр һәм өйрәнәләр. Соңгы 5-6 елда аларны бары тик тере факторлар гына кызыксындыра. Бу оешма 2-3 елга бер тапкыр үз сессиясен уздыра, бирегә дөньяның иң данлыклы курорт җитәкчеләре һәм шул тармак буенча белгечләр җыела. 2009 елда безнең өлкән табибыбыз Фаяз Ибраһим улы да Япониягә чакырылды һәм анда «Бәкер»гә дөнья күләмендә беренче сертификат тапшырылды. Сертификатта «Бәкер» — дөньяның иң бай шифаханәсе» дип язылган. Әлбәттә, биредә табигый байлыклар күз алдында тотыла. 2010 елда Парижда һәм Туниста янәдән шундый ук сертификатка лаек булдык. 2011 елда Словениядә дә әлеге таныклык бирелде. Дөньяда мондый мәртәбәле сертификатны берничә мәртәбә алган шифаханә әлегә юк. Без бу оешманың протоколлары белән дә таныштык. Анда: «Бүген «Бәкер»нең дәвалау программасы буенча кулланыла торган сапропель ләменә һәм утлы суына дөньяда тиңнәр юк», — дип язылган. Борынгы риваятьләр буенча, ханның үләргә дип хөкем ителгән атлары Озын күлдә савыгуының һәм «Мәхәббәт тавы»ннан челтерәп аккан чишмә суы эчеп, кыпчак егетенең тиз арада сәламәтләнүенең сәбәбе дә менә

шунда инде. «Бәкер» шифаханәсенә бирелгән мактау кәгазьләре, сертификатлар, төрле бүләкләр аерым экспозициядә урнаштырылды.

Музейга килгән кешеләргә дә «Бәкер»нең иң зур сере биредәге җиде төрле табигый байлыкта, дип аңлатам. Алар — ләм, утлы су, Сихәт чишмәсе, «Нафтуся» тибындагы Бәкер суы, зәңгәр балчык, һавасы һәм Бәкер суы (шешәләргә тутырыла торганы). Әйтергә кирәк, бу чыганакларның барысы да тере, шул сәбәпле алар тиз арада кеше организмына нәтиҗәле сихәт бирә. Табигый чыганаклар, кешене дәвалаганнан соң, төрле чистарту корылмаларына җибәрелмичә, турыдан-туры җиргә тапшырыла һәм, Җир-ана тарафыннан чистартылып, 5-6 айдан яңа сихәт көченә ия була. Ә иң әһәмиятлесе — Бәкер ягы кешеләренең күләч йөзе, самимилеге, алтын куллары һәм биредәге табигать белән кеше арасында гына булырга тиешле гармония. Бәкердә кешене табигать дәвалый. Безнең хезмәткәрләрне бу эштә 80 ел буе табигатьнең иң оста булышчылары, дип әйтергә тулы нигез бар.

– Гөлсия ханым! Редакция исеменнән Сезне һәм хезмәттәшләрегезне бәйрәмнәрегез белән котлыйбыз. Татар халкының борынгыдан килгән табигый дәвалау традицияләрен саклап калып, аны заманча ысуллар белән халкыбызга җиткергәнегез һәм дөнья күләмендә танытканыгыз өчен мең рәхмәт!

— Без әлеге төбәкнең сер пәрдәсен, тарихын ача гына башладык. Алда тагын да зуррак ачышлар һәм шатлыклар көтә безне! Ә Бәкер җире инде сигез гасыр дәвамында кешелеккә сихәт өләшә. Бу эштә ул бик күп яклары белән кабатланмас һәм бердәнбер. Шуңа да аннан дөрес файдалану, бар сихәтенә ия булу серләрен килгән кунакларыбызга җиткерүдә музеебыз зур роль уйный. Ул киләчәктә дә шулай булып калыр, иншаллаһ!

*Әңгәмәдәш — **Ленар Гобәйдуллин.***
Лениногорск районы,
«Бәкер» шифаханәсе,
6 сентябрь, 2013 ел

Әдәбият

Яратсам да туган-үскән илне,
Мин тауларга карап юл алдым;
Татарстан кызы булсам да мин —
Шагыйрәсе дәртле Уралның!

Салисә Гәрәева

КОТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

ЙОСЫФ БАЛАСАГУНИ
(ЙОСЫФ ХАСС ХАҖИБ)

ҖИДЕ КАТ КҮК ҺӘМ УНИКЕ БӨРЕҖ

Ходай аты белән мин башлыйм сүзне,
Түрәткән, үстергән Иям ул үзе.

Үзе теләгәнчә корды галәмен,
Яндырды дөньяның кояш-ай шәмен.

Фәләкне күр — һәрчак әйләнеп тора,
Шунда кемдер язмыш сәгатен бора.

Зәңгәр күк яралтты, йолдыз бизәкле,
Кара төннәр, якты көннәр түрәтте.

Гади бизәк түгел күктәге йолдыз:
Кайсы сәяхәтче, кайсы кулавыз[1].

Халаекка махсус яндырылган ул:
Адашканнар шуңа карап таба юл.

Каюлары якын, каюсы ерак,
Каюлары тонык, кайсы яктырак,

Болардан иң өстен Искәндәр[2] йөзә
Ике ел да сигез ай бер бөреждә.

Аннары икенче, Уңай[3] була ул,
Бер өйдә[4] унике айлап кала ул.

Өченчесе — Күрүд[5], ялтырый горур,
Нинди яшеллеккә бакса, шул корыр.

Дүртенчесе — кояш, яктырта җирне.
Һәркемгә елмая, ерактыр үзе.

Бишенчесе — Сәвит[6], йөзе сөйкемле.
Шуңа баксаң әгәр, юаныр күңлең.

Аннары Арзу[7] — ул чыннан да арзу:
Кемгә якынлашса, шуңа булыр дус.

Болардан иң аста йөргән ай булыр,
Кояш белән туры карашса — тулыр.

Бар аннары тагы унике **өяк**[8]:
Каюсы пар өйле, кайсы бер өйдә,

Кузый — язгы йолдыз, аннан **Гуд** килә,
Ирәндез һәм **Кучык** йөри бергәләп.

Арысланга Богдай башы иярер,
Өлге, Чаян, Җәя — барсы дус-иштер.

---

* Дәвамы, башы 10 нчы санда.

[1] **Кулавыз** — кәрваннарга юл күрсәтеп баручы.

[2] **Искәндәр** йолдызы — Сатурн. Рәхмәти Аратта — **Зөхаль.**

[3] **Уңай** — Юпитер. Рәхмәти Аратта — **Мөштәри.**

[4] **Өй** — ике бөреж (Зодиак йолдызы) арасы; горизонтның уникедән бере.

[5] **Күрүд** — Марс. Рәхмәти Аратта — **Мәрих.**

[6] **Сәвит** — Зөһрә, Венера. Рәхмәти Аратта — **Зөһрә.**

[7] **Арзу** — Меркурий. Рәхмәти Аратта — **Готарид (Утарид).** Арзу үзе «кадерле теләгең» дигән сүз.

[8] **Өяк** — Зодиак йолдызлыкларының берсе. Хәзерге татарча **өйәк**, мишәрчә **Үвәк** дип, эшкәртелергә алынган тиренең аяк, койрык, муен чыгынтыларын атыйлар. Тарихи җәһәттән **Үвәк~Үгәк~Үкәк** — хәзерге Самара тирәсендәге Иделнең кискен борылышы һәм шундагы Алтын Урда кальгасы (аны руслар җимерттереп, кирпечләреннән Самара кальгасын төзегәннәр).
«Өйәк» сүзе «Котадгу белек»тә оригиналь вариант. Ислам илләрендә **«өяк»**не күптәннән бирле **«бөреж»** дип атыйлар һәм Арат та **«бөреж»** дип язган. Йосыф Баласагуни **«бөреж»** сүзенең төп мәгънәсе «Кальганың почмак башнясы (башнялар саны уникe була)» икәнлеген белгән, күрәсең.

Арытабан — **Углан, Күнәк** һәм **Балык,**
Шуннан көннәр тагын озая барыр[9].

Өче — ут, өче — су, өче — җил булыр,
Өче — туфрак, шуннан дөнья җыелыр*.

Болар бер-берсенә дошман гонсырлар[10],
Күршеләр бер-берсен һаман кысарлар.

Килешмәс дошманнар һәрвакыт үчтә —
Тигезлек саклана ошбу рәвештә,

Иҗатчыл Тәңребез барсын бар итте,
Төзекләде, ишкә иш сыңар итте.

Бу шәйләрне мин күп өйрәнеп йөрдем,
Һәм үзем дә алдым акыл вә белем**.

ИНСАННЫҢ КАДЕРЕ БЕЛЕМ БЕЛӘН

 Яралтты Хак күркәм итеп инсанны,
Аңар бирде ирдәм һәм иҗатчанлык.

Күңел бирде аңар, теленә — сүзләр,
Оят бирде, холкы булсын, дип, гүзәл.

Белек бирде (шуннан бөеклек килә),
Уку бирде — барча төен чишелә.

Ходай кемгә бирсә акыл һәм белек,
Аның кулыннан күп килә изгелек.

Белекне бөек бел, укуны олуг.
*Бу ике күтәрә сайланмыш колын***.*

Моның исбаты бар — телемә килде
(Сүземне ишет һәм отып ал инде):

Акыл кемдә, шуңа олуглык килер,
Белек кемдә булса — бөеклек алыр.
Ушлы тыңлап аңлый, белекле — белеп,
Һәр икесе җитәр максатка ахыр.

Белек мәгънәсен бел — ул ни була, бак,
Белек булса, һәр чир ераклашачак.

Белексез кешегә аурулар тулыр,
Белмичә имләсәң, чирле тиз үлер.

Әй, белексез, ута наданлык утын,
Белексезләр — утын, белемле — котлы.

Уш, акыл — бер тезген, аны тотсаң бер,
Язмыш-ат уңышка сине җиткерер.

Уку хәтсез файда китерә иргә.
Белем алган кемсә һәрчак кадердә.

Уш-акыл күп эшне саладыр юлга,
Белек белән бәкләр асылзат булган.

ТЕЛНЕҢ ФАЙДАСЫ-ЗАРАРЫ ТУРЫНДА

Укуның, белемнең ачкычыдыр тел,
Йөзне якты иткән шул үзе дип бел.

Кемгә тел хөрмәт һәм бәхет китерер,
Кемне тел егар һәм башын кистерер.

Тел ул — бусагада яткан арыслан,
Читлектә булса да ашар ул, саклан!

Теленнән имгәнгән Ир әнә ни ди
(Бу сүзне истә тот — акылга өнди):

---

[9] Зодиак йолдызларының исемнәре дә «Кутадгу билик»тә үзенчәлекле: кайберләре саф төркичә, кайберләре Сирия календарендагыча һ.б. **Кузый** — Хәмәл; **Гуд** — Сәвер (үгезбозау); **Ирәндез** — Җәүзә (игезәкләр); **Кучык** — Сәратан (чаян); **Арыслан** — Әсәт; **Богдай башы** (башагы) — Сөмбелә (сары чәчле кыз, төп мәгънәсендә «башак»); **Өлге** — Мизан (бизмән, үлчәү); **Чадан** — Чаян; **Йа** — кавес (җәя); **Углан** — Җәди (кәҗәмөгез); **Күнәк** — Дәлү (сукояр); **Балык** — Хут (кит).

* Арат текстыннан алынган икеюллыклар йолдызчык белән билгеләнде.
Аратта: *«Өче яз йолдызы, өче җәйгелек,*
Өче — көз, өч кыш вакытын билгели».

[10] Гонсыр — бар дөньяны-галәмне хасил иткән элементларның берсе.

** Аратта: *«Моннан соң сүз китәр кеше турында,*
Аның кадре гыйлем һәм акылында».

*** Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча булган, әлбәттә.

Телем сала бәла-казага мине:
Башымны кискәнче, киссеннәр телне.

Сүзләреңдә сак бул — башың китмәсен,
Телеңне тыеп тор — тешне килтмәсен[11].

Халык теле яман-гайбәт сөйләрләр,
Кеше холкы явыз — итең җигәйләр.

Белемле һәм үткер булса никадәр,
Теле иясенә шулчаклы хәтәр.

Исәнлек теләсәң үзеңә үзең,
Телеңнән чыгарма яраксыз сүзне.

Белеп сөйләсәң, сүз белек саналыр,
Ашыгып сөйләсәң, башың ярылыр.

Чамасыз сөйләдем — файда күрмәдем,
Кайта-кайта сөйләп акыл кермәде.

Күмәртә сөйләмә — берәмләп сөйлә,
Төмән мең сүзеңне бер сүзгә төйнә.

Инсан сөйли-сөйли югары менә,
Ләкин күп сүз бик еш җиргә сеңдерә.

Күп сөйләсәң, яңшак[12] икән, диерләр,
Сөйләмәсәң, чукрак ул дип белерләр.

Әгәр шулай икән, уртача юл тот,
Кешене күтәрә уртача холык.

Телеңне аксатсаң, сау булыр башың,
Сүзеңне кыскартсаң, озаер яшең.

Сүзем абруйлы дип мавыкма бигүк,
Бер мактап, мең тапкыр ташларлар сүгеп.

Шулай икән, сүзең булсын шундый сүз:
Саңгырауга — колак, сукырларга — күз.

Белемсез, билгеле, сукыр кебектер,
Тыңла, надан, әнә ни ди белекле:

Тумыш затлар китә, кая — билгесез,
Игелеккә өндә — калыр өлге сүз.

Кешене яшәтә шул ике шөгыль:
Бере иге эш һәм бере иге тел.

Кеше туды, үлде, сүзе калды, күр,
Кеше үтте-китте, эзе калды, күр.

Карар итсәң, егет, үлмәскә бер дә —
Иге эш, иге сүз калыр хәтердә.

Менә телне сүктем дә мактап алдым,
Теләгем — белдерү сүзләрнең хакын.

Барча сүзне әйтеп бетереп булмас,
Кирәк сүзне, ләкин яшереп калма.

Бу сүземне әйтәм батыр углыма —
Түбәндәгеләрчә колак сал, тыңла:

Сиңа сөйлим икән сүземне, углым,
Бераз гына үгет бирмәкче булдым.

Сиңа калдырам бар алтын-көмешне,
Тик аннан кыйммәтрәк, бел, бу үгетне.

Көмешне эшкә тот — тиз үк азаер,
Сүземне эшкә тот — көмеш казаныр.

Атадан углына чын мирас — сүздер,
Мирас сүзне тотсаң, файда чиксездер.
....
Карама, и белкә[13], кашыңны төеп,
Гозеремне әйтәм сиңа үтенеп.

КИТАП АВТОРЫ ҮЗ-ҮЗЕНӘ ӘЙТКӘН СҮЗЛӘР

Теләгем шул инде, и батыр белкә:
Киләчәк буынга бер сүз әйтергә.

Акыл җитеп килде — әйтә дөресен:
Ялгыш сүз — зур хурлык ул синең өчен.

[11] «Тешеңне китерлек (килтерлек) итеп авызыңа сугарлар» мәгънәсендә.
[12] Бу сүз татар сөйләшләрендә хәзер дә бар: **җанышак** — «акыл өйрәтергә яратучы» (Кара: Татар теленең диалектологик сүзлеге. — Казан, 1969. — 569 б.
[13] **Белкә** — батыр һәм акыллыбаш; мәҗүси галим.

Халык теле яман — гайбәтне сөя.
Кеше холкы кире — итеңне җия[14].

Бер уйласам, авыр күрмим йөгеңне,
Күңел әйтә: «Сөйләп кал бар сүзеңне».

Ник дисәң, аерып әйтмәкче булам:
Син шуңа лаеклы, и батыр туган.

Яңлук[15] дип аталды кеше, ялгышкач,
Яңлышканча шундый исем ябышкач.

Ялгышмаган кеше бармы? Кайда? Кем?
Ялгышканнар исә, әйтсәм, төмән мең.

Белеклеләр бик аз, белексез — сансыз,
Уш-акылсыз күп, тик акыллы тансык.

Белексезләр дошман белеклеләргә,
Бит белексезләр дә хөкем йөртәләр.

Кешедән кешенең аермасы зур,
Белекле-белексез, төп аерма шул.

Белеклеләр өчен бу әйткән сүзем,
Белексезне аңлый алмыйм мин үзем.

Белексезгә әйтер сүзем юк минем.
И, белкә, сиңа мин бер хезмәтчеңмен!

Сиңа сүзләремне имәнеп сөйлим,
Сөйләгәнчә — гафу, гозерләп сорыйм.

Сүз сөйләүче бик еш азар һәм язар,
Зирәкләр ул сүзне дөресләп аңлар.

Сүз гүя борындык дөя борнында:
Шуны тартып, борып була муенын да.

Сөйли белүчеләр очрый күп кенә;
Алар, минемчә, бик кирәк кешеләр.

Барча игелекләр белемнән бит ул,
Фән белән табыла, мисал, күккә юл.

Белем белән сөйлә барча сүзеңне,
Белеменә карап үлчә һәркемне.

Зәңгәр күктән иңде сүз кара җиргә,
Инсан бөек итте үзен сүз илә.

Кеше күңле төпсез диңгез кебек ул,
Шунда яткан белем энҗе кебек ул.

Энҗене диңгездән чыгармасалар,
Сайлык ташына тиң бәя юк аңар.

Җир астында яткан алтын — таш кына,
Чыгарсаң, нур бирер патша таҗына.

Белемле әйтмәсә гыйльмен тел аша,
Белеме билгесез — ятар елларча.

Белем һәм зирәклек — яхшы шәй бик тә,
Белем алсаң — эшләт, күтәрел күккә.

Ни ди, ишет, әнә шәһәр башлыгы
(Шушы дәрәҗәгә илткән акылы):

«Дөнья көтү өчен зирәклек кирәк,
Идарәгә тагын — акыл вә йөрәк».

Җиһангирләр ничек өскә калыкты?
Белек илә җыеп кара халыкны.

Бу дөньяга Адәм иңгәннән бирле,
Зирәкләр изге эш башкарып килде.

Бозылган холыкны гыйлем төзәтер,
Болганган халыкка шул юл күрсәтер.

Ул икегә тәэсир итмәсә гыйлем,
Кылычка тик шунда үрелсен кулың.

Белем илә генә бий хәлдән чыга,
Кылычка сарыла тик надан гына.

Илен, халкын тота акыллы бер зат,
Егәре өстенә гыйлеме булса.

---

[14] Итеңне җию (ашау) — гаебеңне сөйләү.
[15] **Яңлук** — борынгы төркичә — Адәм галәйһиссәлам; гомумән, кеше.

Бу ике берексә, булыр ир төгәл,
Төгәл ирләр генә дөньяны биләр.

Һәр ике дөньяга ия буласың,
Игелек дип белсәң хөкем чарасын.

Әгәр: «Ил алдында мин изге булам», —
дисәң, кыл игелек, әйдә, вәссәлам!

Кеше мәңге калмый, тик кала, калса
Аның аты гына, ул изге булса.

Үзең мәңге түгел, исемең мәңге,
Исмең мәңге булгач, димәк, син мәңге.

ИГЕЛЕК ИТҮГӘ МАКТАУ: АНЫҢ ФАЙДАСЫ ХАКЫНДА[16]

Әгәр ил өстендә йөрсә хөкемең,
Эшеңдә һәм сүздә ит изгелегең.

Егетлек кичәр ул, тереклек үчәр[17],
Бу төштәй дөньядан кеше тиз күчәр.

Яшәвең — тауар ул, табыш — игелек,
Җәренгә ашамлык һәм дә иминлек.

Ишет әнә изге зат ни ди: «Кеше
Йөреп тын алгучы, ахыр үлгүче.

Җиһанда ни шәпле ирләр булдылар,
Бераз шәпләнгәч, күр, барыбер үлделәр.

Кирәк бәк, кирәк кол, яхшы вә яман —
Үлделәр, тик исем калды алардан».

Менә сиңа тиде кизүдә урын,
Гел изгелек кыл син үлмәстән борын.

Һәр тере зат үлә, җиргә түшәлә,
Кеше үлә белсә, изге ат кала.

Ике төрле исем торып калучан:
Йә бик яхшырагы, йә бик тә яман.

Ил каргый яманын, мактый яхшысын,
Шуннан сайла инде — кайсын карыйсың.

Үзең изге булсаң, атың мактаулы.
Яманны сүгәләр тик, и, акыллым.

Фәридунны һаман мактыйлар гына,
Зәххакны сүгәләр, таптыйлар гына.

Изге иде берсе — шуңа мактады,
Бере явыз булды — сүгәләр аны.

Сиңа яманатмы кирәк, яхшатмы?
Сүгешме телисең, бүтән максатмы?

Каюсын теләсәң, сайлап ал берен.
Ни килеп чыкса да, үкенмә җәрен.

Тәҗрибәле кеше әйтә шуңардан
(Ул ил-көн хәлләрен шактый сынаган):

«Изге кеше беркөн алкышланачак,
Яман исә барыбер каргыш алачак.
Сынадым — берәү гел кылса яманлык,
Көче беткәч, начар көнгә калачак».

Яманлык — яман ут: янмый, төти ул,
Һәм аның юлыннан тыныч китү юк.

Уйлап кара: бездән элек үткәннәр —
Гаммәләр һәм бийләр — дөнья тотканнар.

Боларның кайсында бар булса гыйлем,
Шулар җиң сызганып кайгырткан илен.

Кем белемле булса, көчле бийләрдән,
Тик шул тәртип куйган, канун бирәлгән.

Бу чакта изге дип аталса Кеше,
Тора-бара була изгеләр башы.

Каю бәк гыйлемгә якынрак тора,
Үзенә галимне якынлаштыра.

Эшенә керешеп, кул җаен белгәч,
Бий була, белемен куеп гамәлгә.

---

[16] Бу бүлекчә атамасы Араттан алынды. Үзбәк басмасы монда аерым бүлекчә аерып күрсәтми.
[17] **Үчү** — «сүнү» (бу сүз иске текстларда еш очрый, «үчәр», «сүнәр», тик аны ялгыш «очар» дип язып күрсәтәләр).

Илен баетуны бурыч дип саный.
Илен төзек итә, илаты[18] байый.

Аты изге, үзе юмарт атала,
Үлсә дә, ил өчен ул тере кала.

Үлерен белгәч, ул күрә чарасын —
Терекләргә төбәп яза язмасын.

Бүген кем укыса, белә ул шуннан —
Үзеңә үрнәк бий ничек, ни кылган.

Җиһанда гыйлемнән кадерле ни бар?
Надан ир сүгелер, тапмас игътибар.

Ни ди, ишет, әнә белекле кеше
(Бу дөньяны сынап олгайган яше):

«Белексезгә түрдә урын булса, күр,
Бу түр ишеккә тиң, ишек булыр түр.

Галимгә ишектә куелса урын,
Ишек урынына калачак түрең[19].

Фән-гыйлемгә хөрмәт кирәк ничек тә;
Кирәк — түрдә торсын, кирәк — ишектә.

Асылзат кешеләр ике төрле, бак:
Берәү — галим, берәү — идарәче, бәк.

Аннан калган гаммә елкы саныдыр,
Шуннан ике юлның берсен сайлый күр.

Сайлыйсың кайсы юл — әйт, сереңне ач,
Тәүге икедә бул, өченчедән кач.

Кылычтотар илне сафка тезә дә,
Каләмтотар халык юлын төзәтә.

Изгеләрдән калган ил кануннары,
Тотсаң, күтәрерләр сине югары.

Үлектән тереккә иң зур мирас — сүз,
Комарткы сүзне тот — файдасы йөз-йөз.

Белемсез, билгеле, сукыр шикелле.
Әй, надан, кара, ал белемнән өлеш.

Кеше күрке — сүз ул, сүзләр күптөрле.
Изге сүзләрне әйт, макта, әй, телем.

Бу хакта хәтердә бер төрки әйтем,
Үгет кебек булсын, сиңа мин әйтим:

«Зиһен күрке — телдер, ә тел күрке — сүз,
Кеше күрке — йөз ул, ә йөз күрке — күз».

Теле илә кеше сүзен уйната,
Сүзен сөйли белсә, абруе арта.

Инде карыйк безнең төрки бәкләрне,
Шулар арасында иң әйбәтләрне[20].

Бу төрки бәкләрдән иң-иң данлыклы
Тунга алпар иде, бәхетле-котлы.

Белеме зур, ушлы, ирдәмлеге бар,
Белекле[21] һәм илгә сөйкемле алпар*.

Таҗикчә исеме аның — Әфрасийаб[22],
Бу Әфрасийаб алды күп илләр яулап.

Ил тотырлык булсын ирдәм һәм белек,
Шуннан гына кулга ал син хакимлек.

Онытылыр иде (үтте заманнар),
Тәҗикләр бу хакта китап язганнар.

Элекке бер үткен егет ни дигән:
«Чи төенне чишә егетлек, ирдәм.

Мең-мең ирдәм кирәк җиһан тотарга,
Көр арыслан кирәк колан тотарга».

---

[18] Илат — «население» (**«халык»** сүзе бик төгәллексез мәгънәле: «население» дә, «народ» та).
[19] Кара, рус халык мәкале: «Не место красит человека, а человек —место».
[20] Аратта: *«Алар бар бәкләрнең иң әйбәтләре».*
[21] Белем — информация күләме, хәбәрдарлык; белек — белем һәм аны куллана белү; белемле кеше белексез булырга мөмкин, ләкин белемсез кеше белекле булмый.
* Аратта: *Ия иде холык, ирлек, белемгә,*
Чиксез абруйлы зат иде илендә.
[22] **Әфрасийаб** — иран дастаннарында (Фирдәүсидә һ.б.) иранлылар белән каты көрәшкән баһадир, хөкемдар. Төркиләр аны үзләренең җәтләреннән (предок) дип исәпләгәннәр. Ләкин Әфрасийаб исеме үзе ирани сүз.

Кирәк ил башына ирдәм-мең төмән,
Илдән китсен дисәң, бола вә томан,

Кылыч орып дошман муйнын өзәргә,
Заң белән халыкчан дәүләт төзергә.

БЕЛЕМ БЕЛӘН АКЫЛНЫҢ ЧАГЫШТЫРМА СЫЙФАТЛАРЫ ТУРЫНДА

Теләгем шул инде: и батыр белкә,
Сүземне борырга уку-белемгә.

Уку ул — чырактай караңгы төндә,
Белем чыгара ул яктыга-көнгә.

Уку, фәһем сине югары итәр.
Бу ике белән ир хөрмәткә җитәр.

Ышанмасаң, уйла ошбу дәлилне —
Гыйлем рухы тәмам яктыртты җирне*.

Ишеткәнем бар ки, имеш, котылган
Тәмуглы тәмугтан, гыйлеме булгач.

Байый халык, ханы бирсә төз заңын,
Гасырларга мирас итеп үз данын.

Кече оланны күр — укуга кучә,
Тик каләме йөрми, яшь җитмәгәнчә.

Ушлы кешеләр дә, бик картаешлый,
Зиһенем таралды дип, каләмен ташлый.

Әгәр тиле булса, укып та бераз,
Укуында уңмас — дәвасы булмас**.

Нигә алай дисәң, ул ушсыз кеше,
Асылда андый зат — өлешсез кеше.

Укыганча булыр алтындай хөрмәт,
Наданнарга бер уч кибәк — зур бүләк.

Уйлап кара: барча әйткәнем тугры,
Укымышлы кеше асыл, югары.

Кемдә белем, аң, шул асыл зат була,
Кемдә гыйлем — белек, шул бәклек ала.

Шушы җир йөзендә ни кылса кеше
Эшләнгән нәрсәләр — гыйлем
җимеше***.

«Асыл» була шулар, кемнәр белемле,
Белек илә бийләр җитәкли илне.

Мактаулы эшләрнең төмән мең төре,
Барсына да уртак гыйлем фикере.

Уку аз булса да файдасыз түгел,
Белемем аз дип үк төшермә күңел.

«Бу дүрт нәрсәне ир кичергән булсын
(Дигән ди бер белкә, тыңла һәм бел син):

Дүртнең бере — янгын, икенчесе — яу,
Өченчесе ауру — яшәвеңә ау.

Дүртенчесе менә — тәҗрибә, белек,
Шуларны онытма, бул бәкләр кебек[23].

Һәркайсының да күп зыян-файдасы,
Кайсы — бирәсе зат, кайсы — аласы.

Белем кимиясе[24] әкрен кузгала,
Акыл аны җыя, гүя, урдага[25].

---

* Аратта: *Ышанмасаң, Нушинрәванга (Нушиурван-Анушируан — Иран шаһы Хөсрәү I) син бак: Акылы дөньяны кылды яктырак.*

** Аратта: *Бер кешене тиле бәреп үтерсә, Үлем җәзасы юк, чөнки тилемсә (Тиләләрне тилеханәдә тотарга кирәк).*

*** Аратта бу юллар юк.

[23] Икенче бер борынгы версия буенча чын ир ачлык, сугыш, мәхәббәт һәм авыр хезмәт хәлләрен кичергән булырга тиеш.

[24] **Кимия** — химия, ләкин «кимия» сүзенә киңрәк мәгънә бирелгән. Монда «күренми торган процесс».

[25] **Урда** — төп мәгънәсендә «борынгы төрки күчмәчеләр дәүләтенең мөлкәте саклана торган җир асты амбары» булган. Арат төп тексттагы «урда» сүзе урынына «сәрай» дип яза.

Белемгә бик охшаш җофар исе дә:
Яшереп булмыйдыр — шундук сизелә.

Җофарны яшерсәң, исе белдертә,
Белемне яшерсәң, телең фаш итә.

Гыйлем бер байлыктыр ки, ярлы итмәс,
Аны бер карак та элдереп китмәс.

Кешегә ул кешән, акыл һәм белем:
Кешәнле ат юкка йөремәс җилеп.

Сөекле атын ир кешәндә тота:
Кирәкле вактына алдында тора.

Кешәнле ат качмас — йөрер кирәкчә,
Тышаулы еракка китмәс бигрәк тә.

Белем һәм акыл ул — антлы дустыңдыр,
Уку миһербанлы кардәшең булыр.

Тик акыл һәм белем булсын тиң-таман,
Акылың булмаса, белемең — дошман.

Төркичә мәкаль бар бу хакта — тыңла,
Тирән уйлап төшен һәм ал акылга.

«Ушлы кешеләргә уку тап кылә,
Ә белексезләргә сугу тап кылә.

Белеклегә белем бирер өй, аш, тун,
Белексезне явыз нияткә тартыр».

Ушлы ир, ерак тор үпкә-ачудан,
Белекле ир, язма изге атыңнан.

Үпкә, ачу илә тотынма эшкә,
Югыйсә үтәчәк гомерең бушка.

Үчләшеп эшләнгән эш үкенечле,
Ярсынган — языклы, адашыр үчле.

Ир-егет, тыныч бул, ягымлы, уңай,
Сабыр кирәк иргә һәркөн һәм һәр ай.

Олпатлык кирәк һәм иплелек кирәк,
Зирәклек кирәк һәм белем күп кирәк.

Ушлы булу кирәк һөнәр сайларга,
Белем кирәк эшне яхшы җайларга.

Ярый-ярамыйны ачык белергә,
Кирәк-кирәксезне ачып бирергә.

Аерсын, сайласын кирәккәннәрне,
Үзе шәп белсен ир һәрбер һөнәрне.

Эшең булса төгәл, бөтен һәм пеше,
Белекленең хәләл буладыр ашы.

Теләгенә егетирешсә шулай,
Һәр ике дөньяда яктыдыр чырай.

Каһәрләнү, үпкә инсанга дошман,
Кешенең җаны да имгәнә шуннан.

Ишет, ни ди әнә бөкә белкә бәк[26]
(Бу сүзне дә эшкә тотуың кирәк):

«Ачучан кешеләр белексез була,
Үпкәләүчән бәндә бик ипсез була.

Пыр тузучан затны үгетлә тотып,
Ачуланса, әйбәт кеше дә — утын».

Ишет, әнә, ни ди белкә инсаннар
(Аларның сүзләре мәлхәмдер җанга):

«Түбәндәге шәйләр бәндәгә дошман,
Белегез — котылу кирәк шулардан:

Беренчесе була телнең ялганы,
Аннары — сүзендә торалмаганы.

Өченчесе — артык сөю хәмерне,
Сизмәссең дә, зая үтәр гомерең.

Тагын бере — иргә артык кыланыш,
Артык кыланыштан булмас куаныч.

[26] **Бөкә** — гомумән көчле кеше: **белкә** — күп белүче; инструктор.

Тагын бер кирәкмәс шәй — түбән холык,
Шуннан гаиләдә төтен һәм корым.

Янә берсе — ачы теллек, хөсет бел!
(Үтерер кешене сүккән ачы тел.)

Әгәр бергә килсә шул юньсезлекләр,
Андый кешедән кот-бәхет тиз китәр.

Фәләк әйләнмәс, ир башы әйләнер[27].
Тәмам холкы бозгын булыр бәндәнең.

Йөре, коткар шуны, и изге кемсә,
Изгегә изгелек эшләү килешә.

Ни ди, ишет инде ипле кешеләр,
Күп эшкә кул яккан төпле кешеләр:

«Игелек картаймас еллар узганнан,
Мактап карасаң да, яманлык — яман.

Үкенечле үлә ахмак егетләр,
Укымышлы картлар үкенми яшәр.

Изгенең һәр яңа теләге уңга,
Яманның теләге илтер тик моңга.

КИТАПНЫҢ ИСЕМЛӘНЕШЕ ҺӘМ ШАГЫЙРЬНЕҢ АБЫШКАЛЫГЫ[28] ТУРЫНДА

Китапка «Котайткыч белек» диелде,
Котайтсын укыган затны, дип инде.

Сүземне сүзләдем — уйладым шуны:
Һәр ике дөньяны тотыйм берьюлы[29].

Кеше ике дөнья бәхтен казанса,
Ул бәхетле. Бу чын, әйтәм кабатлап,

Иң башта — Көнтугды илбик турында.
Сәбәбен дә әйтим, и изге туган.

Аннан сүз Айтулды егет хакында:
Ыеккотның[30] көнен шул ич актырткан.

Көнтугды дигәнем — гадел хөкем ул,
Айтулды белдерә бәхетле көнне.

Өченче — Үгделмеш — нәрсә белдерә?
Ул акыл һәм эшне гәүдәләндерә.

Азакта Уйгырмыш аты килә. Без
«Рухи саулык» дигән мәгънә бирәбез.

Бу дүрт шәй турында сөйләрмен сүзне,
Укысаң, ачылгай — җете кыл күзне.

Һәрвакыт шат булган ию яшь егет,
Сүземне заяга җибәрмә, ишет.

Яшьлек дәрте-көче сакланмас озак.
Билләрең биртелер, толымың тузар*.

Әле синдә бармы егетлек көче?
Сарыф ит аны дин-гыйбадәт өчен.

Үкенәм — яшьлегем заяга үтте.
Үкенеп файда юк. Һәм сүзем бетте.

Кемнең яше инде кырыктан ашты —
Егетлек еллары хушлаша башлый.

Кырык яшем артта, кул салды илле,
Кара башым булды аккош шикелле.

Түгәрәк илле яшь чакыра «кил!» дип.
Абынмасам урга[31], барамын инде.

Кем яшен яшәсә һәм тулса алтмыш,
Яшәү тәме китә: җәй түгел бу, кыш.

---

[27] Монда каламбур: фәләк (звёздный небосвод) чыннан да әйләнеп тора.
[28] **Абышка** — хатыны үлгән өлкән яшьтәге ир.
[29] Биредә авторның үзенә ироник мөнәсәбәте сизелә шикелле.
[30] **Ыеккот** — борынгы төрки идарәчеләрнең титулларыннан берсе *(Кара: Древнетюркский словарь. — Б.217-218)*.
Арат тәрҗемәсендә бу сүз юк.
[31] Ягъни «кабергә кермәсәм». **Ур** — «окоп, кабер».
* Элеккеге төрки егетләр толым йөрткәннәр.

Утыз яшь түреннән төштем иллегә,
Алтмыш яшькә җитсәм нишләрмен икән?

И, илле яшь, сиңа мин ни кылдым соң?
Мине бәйләп нинди үчең аласың…

Егет чакта татлы иде һәр эшем,
Хәзер агу миңа ашаган ашым.

Буем уктай иде һәм уем-җәя,
Хәзер күңлем уктай[32], тик буем җәя.

Гомерендә ниләр бирсә егет чак,
Картлык килеп барсын җыеп алачак.

Яклаучы фәрештәм, кил, коткар мине:
Картлык имгәгенә мин тоткын инде.

Кешәнсез бәйле — һич атламый аяк,
Күз алдым төн кебек — кара тирә-як.

Ашау таты китте, сүнде дәртләрем,
Ераклаша бара егет чакларым.

Ушыңа кил, и күңлем, үлемне уйла,
Үткәнне хәтерләп, үкереп ела.

Гафиллектә үтте ничә ай вә көн,
Үз-үзеңнән инде син гафу үтен.

И, кайгысыз Иям, мәңге тересең,
Үлем өчен сансыз җаннар түрәттең.

Дога кылып, синнән үтенәм бүген —
Тере кыл, ерак тот гомерем чиген.

Үзеннән сорап бу эшне башладым,
Тәмамларга көч һәм вакыт бир тагын.

Телем, тынмый макта Хак яралтканны,
Яраксызны миннән ерак кылганны.

Түрәтте, сайлады — бирде җанга нур,
Күңлемә күрсәтте изге туры юл.

Караңгыда идем — төнем яктырды,
Төнәр кебек идем — таңымны аттырды.

Азып йөрер идем, әйтеп бирде юл,
Көяр идем утка күзәтмәсә ул.

Аеруча сайлап күтәрде мине,
Азгыннар юлыннан китәрде мине.

Күңелемне бизәде яруклык[33] белән,
Телемне бизәде таныклык[34] белән.

Сөекле сәүчем ул — кертте юлыма —
Кыяматтә тотсын иде кулымнан.

Болар, барсы Иям биргән игелек:
Миндәй гафил колын күтәрде килеп.

Моңа, белмим, ничек шөкер итәрмен
— Тере булсам, күп ел һәм ай җитәрме?

Илаһым, беләсең гаҗизлегемне.
Сиңа тик ачамын зарым-моңымны.

Сиңа лаек шөкер итәлмәм инде,
Үзең генә белеп гафу ит мине.

Туры булсын һаман барган бу юлым,
Чишеп алма миннән иманым тунын.

Тәнемнән алганда минем җанымны
Шаһәдәт илә кис ахыр тынымны.

Кара җир катында ялгыз калганда
Рәхмәтеңнән ташлама мине һаман да.

Тәгатьсез колыңмын, языгым чиксез.
Игелегең илә син мине кичер.

Барча мөэминнәрне дә син ярлыка,
Аларны әзерлә мәңге барлыкка.

Дәвамы алдагы саннарда

Филология фәннәре докторы, профессор
Рифкать Әхмәтҗановның
шигъри тәрҗемәсе

[32] Ягъни «белемем, тәҗрибәм күп, ләкин билем бөгелгән».
[33] **Яруклык** — яктылык.
[34] **Таныклык** — «Котадгу Белек» телендә «белем».

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ХАТЛАРЫ

ГАББАС МӨХӘММӘТҖАНГА

Исхакыйның Япониядә, Кобе шәһәрендә яшәгән Габбас Мөхәммәтҗанга (1915-1995) язылган хатлары кулыбызга Рабит Батулла аша килеп керде. Аларны әдипкә Сан-Францискодан килгән Рокыя ханым Сафа тапшырган булган. Форсаттан файдаланып, Г.Исхакый исемендәге бүләк иясе Батулланың Г.Исхакыйга кагылышлы материалларны юллап табып, кадерләп саклап торуын әйтеп үтәсем килә. Ул 1980 елларда ук кулына кергән, Г.Исхакыйның революциягә кадәр басылган китапларының бишесен (бер төпләмдә) Яуширмәдәге музейга тапшырган иде. Сәйяр язучыбыз Батулла 1989-1995 елларда Америкага һәм Финляндиягә сәфәрләре вакытында милләттәш дуслары бүләк иткән «Солдат», «Бай угылы» китапларын һәм Г.Исхакыйның вафатына бер ел тулу уңаеннан 1955 елда Истанбулда нәшер ителгән «Милли көрәшче һәм милли әдип» исемле бик кыйммәтле истәлекләр китабының күчермәсен алып кайтты.

Без Рокыя ханым Сафа белән дә таныштык. Менә ул нәрсәләр сөйләде: «Мин 1945 елда туганмын. 1951-1955 елларда Кобеда татар мәктәбендә укыдым. Кечкенә чакта әтиләрнең Гаяз абзый турында сөйләшкәннәрен хәтерлим. Сан-Францискодагы милләттәшләр дә аның турында гел сөйли иде. Ә менә 1997 елда Казанга беренче килүемдә Г.Исхакый дип сөйләгәннәрен хәтерләмим, аны бик аз кеше белә иде. Без 1953 елда Төркия гражданлыгы алдык, 1964 елда Сан-Францискога күчеп килдек. Америка гражданлыгыбыз да бар. Ерак Көнчыгыштан күчкәннәр хәзер аз калды инде. 1993 елда безнең әни дә, аңардан ике елга соңрак әти дә вафат булды. Әтием вафаты алдыннан: «Аларның тарихлары өчен кирәк булса, илтерсең, татар музеена бирерсең», — дип, бу хатларны миңа тапшырды.

Хатларда телгә алынган мөһаҗирләрнең исемнәре «Милли байрак» газетасында даими бирелеп барган иганәчеләр исемлегендә еш очрый. 1933-1936 елларда Ерак Шәрекътә яшәгәндә, Г.Исхакый алар белән якыннан таныш булган.

1949-1951 елларда язылган әлеге хатларда Г.Исхакыйның Ерак Көнчыгыштагы илдәшләренә чын күңелдән ярдәм итәргә тырышуы күренә, ул аталарча һәм дипломатларча Төркия гражданлыгы алу турында нәрсәләр эшләргә, кемнәр белән ничек сөйләшергә, хәтта гаризаны ничек язарга кирәклеген дә өйрәтә. Аларның гозерләрен үтәү юлында үзенең нәрсәләр башкарганын тәфсилли. Ә бу тәфсилләр артында никадәр мәшәкать һәм кыенлыклар ята. Истанбулдан Анкарага барып йөрүләр, хөкүмәт кешеләре белән күрешүләр, дус-ишләрен дә шул юлда ярдәм итүгә тартулар һ.б.

Г.Исхакый әлеге хатларда үзенең хәле, сәламәтлеге турында ләм-мим сүз сөйләми. Ә бит бу елларда әдип бик фәкыйрьлектә һәм саулыкка туймыйча

ملی بایراق

Turko Tatars in the Far East

3-نچی یل. یراق شرقده‌گی ایدل-اورال تورک-تاتارلارینڭ آطنه‌لق گه‌زیته‌سی

۲۵ یللق ایسه‌لك.

آوروپاداغی اوزگه‌رشله‌ر.

Г.Исхакый нигезләгән «Милли байрак» газетасы

яши. Бу хакта ул кызына гына зарлана: утынының бетеп китүе, ә көннәрнең һаман суык торуы, ашказаны авыртуы, «һеморрой», «простат» белән интегүе турында яза. Ә шул арада ул Тукай көннәрендә үткәреләчәк «кичәнең репетицияләренә йөрибез», ди, 15 октябрь көне мәрәсименә чыгышлар әзерли. Әлеге тынгысыз мәшәкатьләр арасында хастаханәгә дә кереп ята. «Ашлары һәммәсе суык, тәмсез, татсыз, нәфрәт берлә көчләп ашаштыргалыйм, ... сөеп ашарлык бер аш булса, күбрәк ашый алыр идем. Беркөнне өемдә, чебеш шурпасы ясатып, өйгә кайтып, һәйбәт бер тарелка аш, ике канат, бер муен, бераз бот ите дә йидем (ашадым), һичбер авырлык сизмәдем. Тәмле иттереп чәй дә эчтем. Ашау мәсьәләсен юлга куя алганым юк», — ди ул кызына язган бер хатында.

Берничә хатында Г.Исхакый үзенә «Милли байрак» газетасын «башланганнан алып ябылганына кадәр» табып җибәрүләрен үтенә. Бу газета 1935-1945 елларда Маньчжуриядә Мукден шәһәрендә нәшер ителә. Аның 440 саны дөнья күрә. Һәр санында «мөәссисе (нигезләүчесе) Гаяз Исхакый», дип языла. «Әүвәл үзегездә булса, әрәм-шәрәм итмәгез. Аның нөсхәсе монда беркемдә дә юк. 1939 ел августына кадәр чыкканнары миндә, Варшавада, булса да, алар башка китапларым, әйберләрем берлә бергә сугыш вакытында янып беттеләр», — ди Г.Исхакый.

Алдырган мәгълүматларыбызга күрә, «Милли байрак» газетасы Европа илләренең төп китапханәләренә дә килеп торган. Кайбер елларның төпләмәләре аерым кешеләр кулында да сакланган. Сорау туа: ни өчен бу газета Төркиядә генә беркемдә дә юк? Әлеге сорауга җавапны узган гасырның 30 нчы елларында Төркия белән СССР арасында булган мөнәсәбәтләрдән эзләргә кирәк.

Кемаль Ататөрк хөкүмәте, 1923 елда төзелгән яшь Төркия Республикасын ныгыту, тышкы агрессиядән саклау өчен, Европа илләре һәм күрше илләр белән бик сак һәм сыгылмалы сәясәт алып бара. Вакыт-вакыт СССР белән дә дуслашып ала. Үз илендәге коммунистларны юк итеп барса да, үзенә кирәктә Советлар Берлегендәге коммунистлар белән дә әшнәлеккә керә. Мәсәлән, 1933 елда Төркия Республикасының 10 еллыгы уңаеннан

оештырылган бәйрәм тантаналарында Ворошилов, Кржижановский, Будённый җитәкчелегендәге совет делегациясе дә катнаша. Бу чорда Ататөрк илен дошманнардан саклый алырлык армия төзү белән мәшгуль. Ә СССР исә Төркияне сугыш кораллары белән тәэмин итеп тора. Әлеге дәвердә Европада дөнья сугышы күләгәләре куерып килә. Мондый вазгыятьтә яшь Совет хөкүмәте өчен дә көньяк чикләрне тыныч тоту кирәк.

Әмма Икенче Бөтендөнья сугышы алдыннан Төркиянең Гитлер Германиясе белән якынаюы Анкара-Мәскәү арасын шактый суыта. Ә инде 1943 елда немецларның һөҗүме туктатылып, совет гаскәрләре һөҗүмгә күчкәч, Советлар Берлеге сугышта җиңүче булып чыккан очракта, Төркияне дә басып алу куркынычы зур, дип санап, Төркия хөкүмәтенең «дуслык» кыйбласы тагын СССР ягына борыла.

Әнә шундый әле уңга, әле сулга уйнаклап торган сәяси шартларда Төркиягә барып сыенган төрк-татарларның хәле җиңелдән булмый. Төркиядә мөһаҗир халыклар чыгара торган газета-журналлар да әкренләп ябыла. Берлинда Г.Исхакый нәшер итә торган «Яңа милли юл» мәҗмугасы болар хакында бик борчылып яза. Ерак Шәрекътә, Мукденда чыгып килгән «Милли байрак» газетасын Төркиягә кертмәү, кергәннәрен конфискацияләү турында 1936 елның 20 апрелендә Ататөрк кул куйган хөкүмәт карары игълан ителә (бу турыда «Татарстан» журналында Азат Ахунов язып чыккан иде). Шулай итеп, Төркиядә яшәүче милләттәшләребез үзләренең сөеп укый торган газеталарыннан мәхрүм кала.

Әлбәттә, Төркия хөкүмәтенең мондый кискен карар кабул итүендә Г.Исхакыйның «гаебе» күбрәктер. Көнбатышта һәм Ерак Көнчыгышта ул оештырган матбагаларда һәрдаим большевикларның чын йөзе фаш ителеп тора. Крестьянны рәнҗетүләр, сүз иреген, динне тыю, «партиядәге чистартулар», азчылык милләтләрнең хокукларын чикләү турындагы хәбәрләр һәм, әлбәттә инде, милләттәшләрне бердәмлеккә, үз йөзләрен югалтмаска чакыру, киләчәктә үз дәүләтебезне корачакбыз дип ышандыру — болар барысы да илдәге махсус органнарны ярсытып тора. Ул чорлардагы совет матбугатында Г.Исхакыйны һәм аның матбагаларын хурлап язган мәкаләләр байтак очрый. Төркия хөкүмәтенең, СССР белән «дуслык» дәверләрендә, советларның Г.Исхакыйга булган мөнәсәбәтенә «сизгерлек» күрсәтүе бер дә гаҗәп түгел.

Г.Исхакый Габбас әфәндегә язган соңгы хатында: «Айлар, еллар маташа торгач, «Америка авазы» радиосын татарча сөйләтергә карар бирделәр», — ди. «Америка авазы» — АКШ хөкүмәтенең чит илләргә тапшырулар алып бара торган радиостанциясе. Вашингтонда 1942 елда нигез салынган радио 40тан артык телдә «сөйләшә», шул исәптән рус телендә дә (СССРда бу «аваз»ны тыңлау тыела). Күрәсең, мөһаҗирләр шул каналда татарча һәм башка төрки халыклар телендә тапшырулар алып баруны дәгъвалаган һәм уңышка ирешкән. Г.Исхакый Истанбулдан Анкарага кызы Сәгадәткә 1951 елның 15 июлендә язган хатында: «Татарча радионың сәгате 4.30да башлый, 15 дәкыйка (минут) сөрә, аннан соң Төркстан, аннан соң азәри...» — дип хәбәр итә. Кызына язган тагын бер хатында исә: «15 октябрь өчен мин «Америка авазы» радиосына үз исемемнән бер сүз сөйләп күндердем», — ди, ә икенчесендә: «Без бу арада биш татар көе җырлатып, «Америка авазы»на күндердек. Шуны вөҗүдкә чыгарыр өчен, айдан артык куыштым, телефоннарын санама да. Безнең мохитебез әле, дөньяның машиналануына карамастан, һаман урта чакның (урта гасырның) кустарьлык дәверендә чайпалана. **Бер кеше ачлыгына-туклыгына карамаен-**

«Милли байрак» газетасы редакциясе. Утырганнар (сулдан уңга): Ибраһим Дәүләткилде, Хәлиулла Ибраһим, Гаяз Исхакый, Рокыя Мөхәммәдиш. Басканнар: Әхмәтша Гыйззәтулла, Мансур Арсланбәк, Сәлман Айти. Мукден, 1936 ел

ча бер эшкә үзен баглый алса — бер эш туа. (Ассызык Г.Исхакыйныкы). Берләшү, ярдәмләшү нигезендә эш күрү зиһнияте әле бу мөкаддәм төрек йортта тумаган», — дигән юллар бар. Ниһаять, 1953 елның 17 октябрендә Сәгадәткә Гасәки хастаханәсеннән күндергән хатында Г.Исхакый мондый хәбәр яза: «Әмин бәк Рәсүлзадә (азәриләр лидеры) Таһирлар (Сәгадәтнең ире) берлә сөйләшеп, «Америка авазы»нда безнең телләрдә сөйләшүне туктатуга каршы бер риҗале (үтенечле) бер васита (арадашлык) кәгазе күндерделәр, мин дә имза иттем. Сора әле, шуны матбугатка (монда түгел, Мюнхенда) бирергә ярыймы-юкмы? Яраса, ай соңнарында чыгачак үз мәҗмугамызда (1953 елда Г.Исхакый Мюнхенга Америка инициативасы белән оештырылган гайре рус мөһаҗирләре конгрессына баргач, гарәп язуында нәшер ителә башлаган «Идел-Урал» халыкларының милли берлеге органы булган «Милли байрак» дигән кулъязма журнал күздә тотыла) һәм украиннарның «Освобождение» гәзитәләренә күндерер идек, Таһир шуны белешеп, тиз генә хәбәр бирeңез әле».

«Америка авазы»нда 1951 елның 24 июненнән 1953 елның сентябренә кадәр алып барылган, хәзер инде туктап калган татарча тапшыруларны мөһаҗирләр кабаттан «терелтә» алганмы-юкмы — бу турыда әлегә мәгълүматыбыз юк. Тик шунысын әйтергә кирәк: 1953 елда Мюнхенда шул ук Америка инициативасы белән оештырылган «Азатлык» радиостанциясе төрки телләрдә дә, шул исәптән татарча да сөйли башлый.

«Америка авазы» архивының саклану ихтималы зур. Чөнки бу илгә, Варшавадагы кебек, бомба төшмәгән, йортлар җимерелмәгән. Тикшертәсе иде ул архивны. Г.Исхакыйның тавышы язылган тәлинкә-тасмалар табылса, ни куаныч булыр иде! (Быел Г.Исхакыйның галим И.Гыйләҗев Германиядәге архивтан алып кайткан, «Татарстан» радиосы яңгыраткан тавышын тыңлау бәхетенә ирештек. Әдипнең дүрт минут дәвам иткән чыгышы Берлин радиостанциясендә язып алынган белган икән.) Шунысы да мәгълүм булсын: матбугатта 2011 елның март аенда «Америка авазы»ның эшчәнлеге бөтенләйгә туктатылу турында хәбәр иттеләр.

Габбас әфәнде белән хат алышулар әле бу 10 хат белән генә тукталмаган, күрәсең, әдипнең сүз сөрешеннән

шул аңлашыла. Рокыя ханымның әйтүенә караганда, Г.Исхакый милләттәшләренә Төркия гражданлыгы алдыруга ирешкән.

Бу хатлар Г.Исхакыйның чит мохиттә, тар кысаларда яшәгәндә дә милләттәшләренең тормышларын мәгънәлерәк итү, җиңеләйтү юлларын эзләшүен, инде үзе ярдәмгә мохтаҗ көннәрдә дә мөһаҗирләр турында кайгыртып, аларга таяныч булып яшәвен күрсәтә. Г.Исхакыйның зур абруе, эшчәнлеге Ерак Көнчыгыштагы мөһаҗирләргә генә түгел, Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң Германиядә калган әсир милләттәшләренә дә бик күп киртәләрне җиңелрәк үтәргә мөмкинлек биргән.

Хатлар гарәп язуыннан күчерелде.

БЕРЕНЧЕ ХАТ

Хөрмәтле Габбас әфәнде!

Сезнең сентябрьнең 8ендә язган мәктүбегезне алдым. Ни язганыгыз мәгълүм булды. Кайда гына булсалар да, милләттәшләребезгә кулдан килгән ярдәмне итү вә каршылыклы итешү һәммәбезнең милли вазифасыдыр. Мин дә Япониядәге милләттәшләремнең йомышларын үтәүне үземнең милли бурычым дип карыйм. Вә, шуңарга күрә, сезнең Төркия тәбәгасе (гражданины) булырга тырышуыгызга дустча, кардәшчә карап, кулымнан килгән кадәр тырышырга сүз бирәм. Ләкин бу теләгемезнең таман уңышлы чыгуын гарантия итә алмыйм. Эшләү, тырышу — бездән, уңышка муәффәкыять (уңышка ирешү) — Тәңредән. Үткән юлы язганымча кебек, үзегез ышанган, милләтчелегендә шөбһәсез булган ун-унбиш гаиләнең, аерым-аерым гаилә әгъзаларының листәсен (исемлеген) язып, рәсемнәрен куеп, кыскача гына:

«Төркия Җөмһүрияте Башбаканлык Макамы галиясенә.

Япониядә яшәгән шимал төрекләреннән (татарлардан).

Әгъзаларымызның исемнәре, яшьләре күрсәтелгән исемлектәге гаиләләрнең башлыклары Төркия Җөмһүрияте хөкүмәтеннән безне Төркия гражданлыгына кабул итүегезне, Ерак Көнчыгыштагы якташларыгыз аркылы безгә метрикә таныклыгы җибәрүегезне төреклек наменә түбәнчелек белән сорыйбыз. Гражданлыкка кабул ителгән очракта Ватаныбызга вә милләтебезгә тугрылыклы калачагыбызга вә хөкүмәтнең безгә йөкләячәк бөтен вазифаларны башкарачагыбызга намусларыбыз белән сүз бирәбез. Һәммәмез дә үз хәятебезне хезмәтебез белән көн күрергә ирешеп, милләтебезгә, хөкүмәтебезгә йөк булмаячагыбызны да вәгъдә итәбез.

Хөрмәтләребез белән (имзалар)».

(Хатта бу мөрәҗәгать төрекчә язылган, тәрҗемә ителде. — Л.Г.)

Шундый кәгазьләрегез килеп, кулыма төшсә, Анкарага барып, бөтен зур кешеләрен күрергә вә сезнең үтенечләрегезне тутырырга тырышырмын. Сугышның беренче елларында сәфир (илче) Фәрид бәк булган чакта, ул сезгә, Япониядә калып та, Төрек тәбәгасе алырга карар биргән иде. Шул вакытта Төрек сәфарәтеннән (илчелегеннән) берәр кәгазь алган булсагыз, аны да күндерегез. Ләкин бу эшне мөмкин кадәр яшерен эшләгез вә мондагы дуст-ишеңезгә, кардәш-кабиләңезгә дә алдан хәбәр бирмәгез. Анкарадан алган мәгълүматымны сезгә әхакан (һичшиксез) язармын. Бу листәгә Фузандагы Вәлиәхмәд Гобәйдулла әфәнде берлә Токиодагы Әхмәт Апанай гаиләсен дә беркетүегезне үтенәм (үзләре теләсәләр). Бу язуларны аеры-аеры берничә пакетта, берике көн аралаша күндерегез. Хөсәен әфәндегә, Дәүләтша әфәндегә вә бөтен милләттәшләргә сәламнәремне сөйләгез.

Бу мәктүптән шул ун-унбиш гаиләдән башкаларын читтә калдырырга тели дип аңламагыз. Беренче мөрәҗәгатьтә, мондагыларны куркыт-

мас өчен генә, аздан башларга уйлыймын. Юлы ачылса, барысын да шул юлдан эшләрмен вә эшләргә дә уңай булыр.

Гаризагызны латин хәрефләре берлә машинада яздыра алсагыз, яхшы булыр. Әгәр ул мөмкин булмаса, ачык итеп гарәп хәрефләре берлә языгыз. Имзалары ачык булсын. Хушыгыз.

Айаз Исхакый-Иделле
Истиклял җәддәсе, Иске Чәчәкче sok.
N 40/4, Бәйуглы, Истанбул.
1949 ел, 10 октябрь

ИКЕНЧЕ ХАТ

Хөрмәтле Габбас әфәнде!

Унөч гаиләнең 36 әгъзасы илә [җибәрелгән] кәгазьләрегез кичә генә килеп җитте. Язулар, минем күрүемчә, монтазамдыр (тәртиптәдер). Ләкин Рәшид Акчуринның листәсендә фотограф рәсеме чыкмады. Бу рәсем төрле йирләрдәге тикшерүләрдә төшеп калган булырга кирәк. Шул рәсемне бик тиз иттереп таир (очкыч) берлә күндерегез. Монда [исемлеккә] кертелгән агай-эне арасында бер данәдә, Нагуялы милләтчеләргә очрамадым, бәлки, мин оныткамын. Ләкин Дәүләтша Сәзгәннәр, Сәидгалиләр кебек хәтеремдә калганнарның исеме очрамады. Бәлки, боларын икенче [чиратка] куйгансыздыр. Бу эшнең әле ничек нәтиҗә бирүе, әлбәттә, мәгълүм түгел. Ләкин шул мәсьәләнең башлангычында милләтчеләремезне үпкәләндерә торган, арадагы тигезлекне бетерә торган хәлләр чыга күрмәсен. Аннан бик сакланыгыз. Бу кәгазьләрне алып, үзем, Алла кушса, 1950 елның 15 гыйнварларында Анкарага китәчәкмен. Хәзер яңа ел алды булганга, киләчәк айның уннарына кадәр Анкарада хөкүмәт әрбабы (башлыклары), хосусан, депутатларның күбесе, читтә булачаклардыр. Мин эшләремне күбрәк депутатлар аша йөрткәнгә, аларның тупланган хәлдә булулары мәтлубтыр (таләп ителә).

Әгәр анда икенче чиратка языларга теләүчеләр булса, аны да тиз күндерегез. Мин бу язулар берлә бергә хатыңыз да булырмы әле дип көткән идем, хат-фәлән чыкмады. Вәлиәхмәт Гобәйдулла әфәнде Кореядә булганга, аның берлә, бәлки, языша алмагансыздыр. Анкарага барып, шул теләгегез хакында хөкүмәт кешеләренең фикерен алгач, тәфсилле мәктүб берлә әхвәлне белдерермен. Җитмәгән нәрсәләр булса, аларны да язармын. Вә сез мөмкин кадәр тиз җаваплаңдырырга тырышырсыңыз. Бу җавабыңыз да бик соңга калды.

Мондагы агай-эне сау-сәламәт. Берике көн элек Тәнзиннән Закир Яушның олуг углы Салих гаиләсе берлә, Тәнзин мулласы Хатыйб Халиди гаиләсе берлә килеп чыктылар. Сездән монда килүче булганда, берәрегездә сакланган булса, «Милли байрак» гәзитәсенең башланганнан ябылганына кадәр бөтен нөсхәләрен миңа күндерсәгез, бик рәхмәт укыр идем. Әүвәл, үзегездә булса, әрәм-шәрәм итмәгез. Аның нөсхәсе монда беркемдә дә юк. 1939 ел августына кадәр чыкканнары миндә — Варшавада булса да, алар башка китапларым, әйберләрем берлә бергә сугыш вакытында янып беттеләр.

Хушыгыз. Дуст-ишкә хөрмәтләремлә
сәламнәр. Гаяз Исхакый
1949, 24 декабрь. Истанбул

ӨЧЕНЧЕ ХАТ

Хөрмәтле Габбас әфәнде!

Мин ун көннән бирле сәфәрдә идем. Бик күп зур вә мөһим затларны күреп, сезнең гаризаларыгызны юлына куя алдым. Кичә Хариҗия вәкаләтенең (тышкы эшләр вәкиллегенең) мөһим бер шәхесенә кәгазьләрне тапшырдым. Хөкүмәтнең зурлары принцип ягыннан сезнең теләкләрегезне кабул итүләрен сөйләделәр. Ләкин эшләр бүген-иртәгә тәмам булачак түгел. Бераз көтәргә кирәк булачак.

Мөгамәләнең башлануы өчен хәзерге көннәрдә Корея эшләрен караучы комиссиянең әгъзасы булган Касыйм

Гүләк дигән затның Анкарага кайтуын көтәләр. Ул затка, гомумән, безнең Идел-Урал мөһаҗирләре хакында мәгълүмат тупларга кушылган икән. Иншалла, яхшы мәгълүмат китерер. Ләкин гариза бирелгән кешеләр өчен (ягъни сезнең өчен) артык мәгълүматка хаҗәт юк. Монда мин кыйммәтле дусларымнан сезнең хакта яхшы вә тугры фикер бирдердем. Алла насыйб итсә, эшегез үзегез теләгәнчә булачак. Касыйм Гүләк бәк Токио[дан] Кобега килсә, үзенә хөрмәт күрсәтегез вә гаризаңызда язган рәвештә дәртеңезне аңлатыңыз. Төрек тәбәгалегенә кабул ителәчәксез.

Тәфсилле хатны Истанбулдан язармын. Февральнең 15ендә Истанбулда булыначагым.

28 декабрь тарихлы мәктүбегезне вә эчендәге бүләгегезне алдым. Бүләгегез өчен рәхмәт.

Бөтен дуст-ишкә хөрмәтләремлә сәламнәр.

Бу эшне әлегә сер тотыгыз. Яңа гаризалар әле күндермәгез. Истанбулдан үземнең хатымны көтегез. Бу эшне юлга кую бик авыр булды. Аллага шөкер, дусларның ярдәме берлә башкара алдым.

Әлегә хушыгыз. Гаяз Исхакый.

Берлинда басылган мәҗмугалар, китаплар һәммәсе дә үземдә бар. Юк нәрсә — Ерак Шәрекътә нәшер ителгән китаплар берлә «Милли байрак» гәзитәсе генәдер. Аларны кулга төшереп, җибәрә алсагыз, мәмнүн булырмын.

Хатны бик ашыгыч яздым. Кореядән килгән милләттәшләрнең маллаларын таможнядан чыгарту артыннан йөгерәм.

Хушыгыз. Гаяз
1950, 28 гыйнвар. Анкара

ДҮРТЕНЧЕ ХАТ

Хөрмәтле Габбас әфәнде!

Моннан өч көн элек кенә, өч атнага якын калып, Анкарадан дүндем (кайттым). Анкараның һавалары бик суык вакытка очрадым да, бераз зәхмәт тә чиктем. Суыклар мин анда вакыт 20 дәрәҗәдән ким булмады. Кай көннәрне 25-26га кадәр чыкты. Безнең мәмләкәттә бу — зур суык булмаса да, мондагы өйләр, кием-салым кышка каратып эшләнмәгәнгә, халыкка бик авыр килде. Мин үзем, Аллага шөкер, авырмый-нитми, сау-сәламәт кайттым. Барыр-бармас дуст-ишне эзләп таптым. Сезнең мәсьәлә тугрыдан-тугры вә Хариҗиягә тәгаллекъ иткәнгә (тышкы эшләргә бәйләнешле булганга) Хариҗия назыйре (министры) Нәҗметдин Садыйк бәк бер-ике көн соңра Аурупадагы бер конференциягә китәчәк булганга, дуст бер депутатым аша аның берлә күрештек. Хариҗия назыйре бу эшне үз башына гына хәл итә алмавын сөйләгәнгә, тагы бер дустым васитасы (арадашлыгы) берлә Дахили (эчке эшләр) вәкиленә мөрәҗәгать иттек. Ул да шул ук җавапны биргәнгә, баш вәкил Шәмсетдин Көналтай бәккә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр калдым. Икенче бер дусларымнан зур бер кеше аркылы мәсьәләне аңарга ачтык. Боларның барысына да сугыштан элек, Фәрид бәк сәфир (илче) булганда, Япониядә калып, тәбәгагә (гражданлыкка) кичү хакында Төркия хөкүмәтенең бер карары булганны сөйләдек. Өченче бер мөһим дустым аркылы 1940 елдагы Төркия хөкүмәтенең бу карарын да эзләтеп таптык. Баш вәкил хәзрәтләре: «Мин бу эшкә тарафдармын. (Ягъни моның эшләнүен телим.) Корея мәсьәләсен карашыр өчен, иске министрлардан Касыйм Гүләк бәк Ерак Шәрекъкә китте. Аңарга Ерак Шәрекътәге мөселман төрк-татар мөһаҗирләренең хәлен өйрәнеп кайтырга куштык. Ул кайтсын да анда алган мәгълүматка карап эшкә керешермен», — диде.

Инде шул төрле яктан алынган шул фикерләрне бер җепкә тезеп, юлына куярга гына калды. Ул вакыт Хариҗия вәкиле дә Аурупага киткән

Г.Исхакый Кобеда уздырылган корылтай делегатлары белән. 1934 ел

иде. [Үтенечләремез] Хариҗия вәкиленә булганга, бу эш Хариҗия вәкаләте карары берлә эшләнәчәк булганга, Хариҗия вәкаләтенең вәкилдән соң беренче зур мәэмүре (чиновнигы) булган Хатыйб Гомуми бәкне зиярәт иттем. Вә аңарга бөтен теләкләремне тәфсилле аңлаттым. Бу зат, әүвәле Русиядә сәфир булып торганга, безнең эшләрне белә иде. Башка вәкилләр берлә дә бу хакта сөйләшкән иде, ахрысы. Мине дә таный икән. Дустанә каршыландым. «Әүвәлдә, бу мәсьәлә принцип ихтыяры илә макбүлдер (принципта кабул ителгән). Ләкин моның эшкә ашырылуы бүген-иртәгә булачак хәлдә түгелдер. Буңарга шактый зур киртәләр бар. Әүвәлән, без әле һаман Япония берлә солых ясый алмаганга, анда сәфарәтемез юк. Андагы эшләрне [вакытлы килешү] комиссиясе аша йөртергә мәҗбүрмез. Америка, инглизләрдән башка, бу эшкә дошманча карый торган дәүләтнең дә әгъзасы бар. Ул бу эшне бутарга маташачак вә, бәлки, андагы кардәшләремезгә зарары да тиячәк. Шуңарга Касыйм бәкнең кайтуын көтәмез. Болар хакында акрын гына тәхкыйкать ябачагыз (тәфсилле тикшереп башкарачакбыз)», — диде. Истидгаларны (үтенеч кәгазьләрен) алды. Тәхкыйкать хакында үземнең сезгә кәфил (җаваплы) булачагымны [әйттем] вә тагы берничә затны күстәрдем. Япониядә булынган бер мөһим шәхесеннән дә сезнең хакта дугры, дөрест мәгълүмат бирүен үтендем. Ул да кабул итүен әйтте. Эш юлына куелды. Ләкин бик тиз чыгар дип өмет итмим. Фәкать, бу эш булачак дип, мине канәгатьләндерделәр.

Бу араларда монда сайлаулар көтеләдер. Шуңарга эшләре баштан ашкан инде. Сез шау-шусыз гына көтеп торыгыз. Әгәр бер нәрсә кирәк булса, сезгә язармын. Хәзергә һәр эш җирендә, диделәр. Ләкин моны һаман әле сер тотыгыз. Бер юл ачылса, башкаларына да җиңеллек булыр.

Күндергән бүләгегезне алуымны язган идем, аңарга рәхмәт. Ул бүләкнең мондагы базарда бәһасе шактый зур булды. Сез күндергәнчә булганда — ике йөз җитмеш алты лира бирделәр. Базар берлә генә караганда — йөз илле лира кадәр югалттык. Хәерле булсын.

Бу хәбәрне шауламагыз. Монда мин аны үземезнең мөһаҗирләремезгә сөйләмәдем. Сез дә беркемгә дә язмагыз. Гайбәт күбәйсә, эшкә зарар итеп, дошманны уяттыру ихтималы бар. Кирәге чыкса, бәлки, тагы бер мәртәбә Анкарага барып чыгармын. Әлегә шулкадәр. Хатымны дошманнар кулына төшермәгез.

Хушыгыз. Бөтен дуст-ишкә сәламнәр,
хөрмәтләрлә Гаяз Исхакы
1950, 12 февраль. Истанбул

Г.Исхакый Мукденда, мәктәп укучылары белән. 1935 ел

БИШЕНЧЕ ХАТ

Хөрмәтле Габбас әфәнде!

Сезнең 21 апрельдә язган хатыгызны алдым. Ни язганыгыз мәгълүм булды. Моннан элек бер хатыгызны алган идем. Язылачак яңа бер хәбәр булмаганга, вакытында җавап яза алмаган идем. Гафуыгызны үтенәм. Касыйм бәк бер-ике атна элек мәмләкәткә кайтты. Ләкин үзен әле күрә алмадым. Истанбулга килеп чыкмады, аны күрер өчен генә Анкарага бара алмадым. Барсам да, зур бер эш эшли алмаган булыр идем. Монда хәзер Милләт мәҗлесенә сайлау үтте. Хәзерге эш башындагы партия берлә яңа партияләр бик каты тартышалар. Бөтен эшләрнең алайга вә болайга китүе шул сайлауларның нәтиҗәсенә баглыдыр. Хәзер монда сайлау-сайланудан башканы уйлаган кеше дә юктыр. Бөтен көч шул сайлауга юнәлгән.

14 май, якшәмбе көн, бөтен мәмләкәттә яңа кануннар буенча сайлау булачак. Дәүләт башы сайланачак. Вә яңа хөкүмәт корылачактыр. Бу хөкүмәт хәзерге партия әгъзаларыннанмы йә яңа партияләрдәнме булачак Алла үзе генә belә. Шул яңа хөкүмәт төзелеп, эшләрен кулга алгач кына, безнең эшләргә чират киләчәк. Ул да июнь аеның 10нары — 15ләреннән элек булмаячак. Шул вакытта, кирәк булса, бәлки, тагы бер мәртәбә Анкарага барып килермен. Мин эшегезне онытканым юк. Анкарадагы дустлар берлә дә шул хакта язышып торам. Вакыты шулай булганга, безнең кызулау берлә генә эш ашыгып йөрми. Яңа хөкүмәт нинди партиядән төзелсә дә, иншалла, дустларыбыз табылыр. Ләкин мондагы гадәт буенча, яңалар искеләрнең күп эшләрен үзгәртәләр. Иншалла, сезнең теләкләрегезне алай итмәсләр. Эш бераз юлга куелыр-куелмас җавап язармын. Сез дә сабыр берлә генә көтеп торыгыз.

«Милли байрак» гәзитәсен берәр килүче булганчы үзегездә саклагыз, почтада югалмасын иде. Мәмләкәткә аннан гәзитәләрне кертергә һәркемнең хакы булганга, алып килүчеләргә һичбер зарар булмас. Ишетүемезгә күрә, Кореядән килүчеләр Япония аша китәләр икән. Вә шуннан килүчеләр бар, имеш. Шулар арасыннан ышанычлы милләтчеләр берлә сездәге бөтен калган милли эшләрнең ничек баруын аңлатып язган хатларыгызны күндерә алырсыз.

Эшегезне милли вазифа дип белеп, ышанып, һәрвакыт артыннан йөриячәкмен. Кулымнан килгән кадәр сез теләгән рәвештә тәмамлануына тырышачакмын. Моннан әмин (тыныч) булыгыз. Бөтен милләтчеләргә,

дуст-ишкә бик күп сәламнәр, хөрмәтләремне белдерегез. Кореядән килгән иптәшләреңез һаман әле таможнядан малларын чыгарып бетерә алмадылар. Әйберләре арасында соңгый (ясалма) җефәк бар, диләр. Килүчеләр, гомумән, бертөрле дә җефәк мал китермәсеннәр.

Әлегә хушыгыз. Гаяз Исхакый
1950, 1 май. Истанбул. Бәйуглы

АЛТЫНЧЫ ХАТ

Хөрмәтле Габбас әфәнде!

Сезнең 28 июльдә язган мәктүбеңезне алдым. Ни язмышыңыз мәгълүм булды. Сезнең эшләрне онытмаганмын. Моннан әүвәлге хатымда язган идем, иншалла, алган булгансыздыр.

14 майда сайлаулар монда көтелмәгән бер үзгәреш тудырды. Иске хөкүмәтнең башлаган эшләренең күбесе туктап калды. Яңа хөкүмәт бик күп яктан чуалчык эшләр каршысында калганга, кыска вакытта гына иске хөкүмәттән күчкән эшләрне кулына алып бетерә алмады. Яңа Милли мәҗлестә бик күп яңа эшләр чыгарганга, сезнең эшләр вә аның кебекләргә чират җитмәде.

Яңа хөкүмәт корылгач, Анкарага үзем бара алмасам да, үземнән дә көчле дустларым аркылы эшләрегезне юлга куйдырырга тырыштым. Нинди сүзе үтә торган кешеләр булса да: «Бераз көтегез. Башымызны кашырга да вакытымыз юк», — җавабын алдылар. Шуның өстенә Корея сугышы килеп чыкты. Ул сугыш монда зур тәэсир ясаганны газиталәрдә укып та белә торгансыздыр. Бу да яңа хөкүмәткә зур мәшәкатьле эшләр йөкләде. Менә шул эшләр безнең мәсьәләмезгә барып җитәргә имкян бирмәде. Сезнең эшләр вак-төяк кечкенә мәэмүрләр берлә генә эшләнә торган эш булмаганга, теләр-теләмәс, зурларның вакытын көтәргә мәҗбүр булдык. Хәзер Милләт мәҗлесе тәгътыйлга (каникулга) таралган вакыт. Ул ноябрь башында гына тупланадыр. Яңа хөкүмәт тә чираттагы мәсьәләләрне караштырып, бераз сулыш алыр. Шул вакытта сезнең эшне тагы да хәрәкәткә китерермез, иншалла. Үзем шул эшегезне тагы бер мәртәбә, яңа бөекләр берлә күрешеп аңлатыр өчен, көз фасылы кергәч, ягъни октябрь айларында, Анкарага барачакмын. Иншалла, бу юлы эшегезне сез теләгәнчә хәл иттерергә муафикъ улурмыз. Яңа хөкүмәт ияләре искеләре кебек безнең халыкка дошманча карамыйлар. Араларында таныдык-белдекләрем дә шактый күп. Кореядән килгән мөһаҗирләремезнең иске хөкүмәт ундүрт ай буенча таможнядан малларын чыгартмаганнар иде. Яңа хөкүмәт бер әмер берлә һәммәсенә таможнядан малларын белдерде. Сезнең эшне дә, иншалла, шулай итәр.

Фузандагы Вәлиәхмәт Гобәйдулла Япониягә чыга алдымы? Шуны коткарырга тырышыгыз. Бик һәйбәт милләтчебез иде.

Моннан Кореяга ярдәмгә китә торган төрек гаскәрләренең башларына берәр мәҗлес ясарга тырышыгыз. Алар берлә күрешегез. Гаскәрләр сезнең эшләрне белмәсәләр дә, күңелләре булсын.

Килүче булганда гына «Милли байрак» газитәсен ышанычлы кеше аркылы гына күндерегез. Әрәм булмасын.

Ул хатымда сезнең адресыгызны Габбас дип кенә язганмын. Фамилиягезне язарга оныткамын. Иншалла, ирешкәндер. Монда агай-эне исән-сау яшәп килә.

Хушыгыз. Хөрмәтләрчә Гаяс Исхакый
1950, 10 август, Истанбул

ҖИДЕНЧЕ ХАТ

Хөрмәтле Габбас әфәнде!

Мин Анкарада ике атна калып, төрек тәбәгасенә күчүегез хакында тагы бер мәртәбә тырыштым. Хариҗия вәкиле кореяле Фуад бәкне мәкамында (урынында) зиярәт итеп, мәсьәләгезне аңлаттым. Хариҗия вәкиле хәзрәтләре фикеремне кабул итте. Сезнең Япониядә калып, Төркия тәбәгасенә күчүегезне мәгъкуль

күрде. Вә башка вәкилләргә мәсьәләне аңлатуны өстенә алды. Фуад бәкнең тәүсыясе (киңәше) берлә Хариҗиянең баш кятибен (секретарен) хиярәт иттем (күрдем). Ул да мөгамәләгә башларга булды. Хәзер Токиода Төркиянең гаскәри һәйәте (комиссиясе) бар. Шулар аша сезнең хакта бәлки бераз мәгълүмат алырга теләр. Әхмәт Апанайга язып, гаскәри һәйәт берлә күрешергә, эшне сорашсалар, аңлатырга кушыңыз. Бу — мөһим! Икенче, Анкарадан минем якын дустым, иске Италиядә сәфирлек иткән Җамал Хөсни бәк шул арада Токиога Төркия хөкүмәтенең илчесе сыйфаты берлә китү ихтималы бик якын. Аны килер-килмәс күреңез, мәсьәләгезне аңлатыгыз. Мин Җамал Хөснигә аңлаттым. Ярдәм итәргә сүз бирде. Җамал Хөсни Төркиянең зурларыннандыр. Аңарга хөрмәт итегез. Хариҗия вәкиленнән башка мәгариф вәкилен дә күрдем. Аңардан да шул эшкә ярдәм эстәдем. Ул да кабул итте. Вир кач (берничә) таныш мәгбүсләргә (депутатларга) да ярдәм итүләрен рәҗа иттем (үтендем). Шулай итеп, сезнең бу эшегез юлга куелды. Ләкин бик тиз эш тәмам булыр дип сүз бирә алмыйм. Мондагы гадәт буенча, монда инде эшләр озын йөри. Монда бер кирәкле кәгазь бер кятинкә килгәч, артыннан йөрүчесе булмаса, бик озак урынында кала, кайвакыт шунда «йоклап» та китә. Бу сәнә эшнең бу ягын, мин Анкарада булмаганга, мәгатәэссир (кызганычка каршы) эшли алмыйм. Әлбәттә, кайбер дуст-ишкә хат язгалармын. Үзем еш-еш Анкарага китә алмыйм. Аңарга вазыятем рөхсәт бирми. Юллар шактый озын, тормышлар монда да җиңел түгел. Әлбәттә, берәр юлым төшсә, Анкарага китә алсам, эшегезне тагы җанландырырга тырышырмын.

Менә бүгенгә шулкадәр. Бөтен дуст-ишкә, Хосусан, Хөсәен әфәндегә вә башка милләттәшләргә бик күп сәлам. Берәр төрле эшегезгә кирәк булсам, һәрвакыт милли вазифа кысьмен кулдан килгән кадәр эшләргә хәзермен.

Хушыгыз. Адресым һаман Истанбулда, искечә.

Гаяс Исхакый

1950, 2 декабрь. Анкара

СИГЕЗЕНЧЕ ХАТ

Хөрмәтле Габбас әфәнде!

Анкарадан кайткач, сездән бер хат алган идем. Моннан бер атна — ун көн (элек) Хөсәен әфәндедән дә бер хат алдым. Ләкин боларның берсендә дә сезнең (хакта), ягъни әүвәлге груп хакында Токиода төрек гаскәри даирәләрендә бер сорау булу-булмау хакында бер сүз дә юк. Анкарада миңа Токиодагы гаскәри һәйәт тарафыннан болар хакында мәгълүмат алырмын дигәннәр иде. Моны белеп тору минем өчен мөһимдер. Икенчедән, инде минем сезгә беренче хат язуыма ике ай булып үтсә дә, икенче груп хакында һичбер мәгълүмат килмәде. Хөсәен әфәндenең мәктүбендә шау-шуга сәбәп булмасын дип, игълан иттек, диелсә дә, бу вакытка кадәр сезнеке кебек прошениеләр миңа бер данә дә килеп җитмәде вә аларның шул эшләренең эшләнәчәк нәкъ вакыты иде. Гәзитләрдә безнең андагы агай-эне хакында, кайдан килгәнен язмаганга гына булса да, төрек гаскәренә ярдәмнәре хакында бик күп нәрсә язылды. Шуның кызусы берлә эшнең юлга куелуы уңайрак булачак иде. Аннан соң дәүләт эшендә бит безнекеннән башка да бик күп эшләр вә мәшәкатьләр бар. Шул хәл эчендә хөкүмәт эчендә үзгәрешләр булып, танышларымның урыннарын үзгәртү ихтималы да юк түгел. Шуңарга күрә, бу эшләрне мөмкин кадәре тиз тоту лазем иде. Бәлки анда тугрыдан-тугры гаскәри һәйәткә прошениеләрне бирү фикеренә килгәнсездер. Ләкин бер эштә бер юлы табылганның соңында, ахырына кадәр шул юлдан йөрү вә яңа юллар эзләмәү муафикъътыр. Мәшәкать, зәхмәт берлә хәзерләнгән юл бар вакытында тәҗрибәсе үтмәгән бер юлга сабу файдасыз булуы бик ихтималдыр. Бу ва-

кытка кадәр ни эшләнгән булса, шуны миңа ачып белдерүегезне үтенәм. Икенче групның (документлары) килсә, тагы бер мәртәбә Анкарага барып, берьюлы беренче груп эшен дә тикшерермен дип тора идем. Озак хәбәрегез булмагач, хәзер бер дустым аркылы беренче групның мөгаләмәсе нинди юлда икәнен тикшертергә мәктүб яздым. Җавабы килсә, сезгә белдерермен. (Документлар) сезнеке кебек хариҗиягә язылырга тиештер. Токиодагы гаскәри һәйәт берлә Әхмәд Апанай вә башка берәр танырлык милләтче дустыгыз аркылы мөнәсәбәттә булып торыгыз, файдасы булачактыр. Тиздән җавабыгызны көтеп калам.

Кобедан тәфтиштән (тикшерүдән) кайткан генерал Шиһаб безнең халык хакында мактаулы сүзләр сөйләде. Сез, кобелеләрнең төрек гаскәре берлә алдырган рәсемнәреңез булса, безгә дә күндерегез. Без монда дуст гәзитәләргә бирермез. Соңгача һаман Токиодан гына язып торалар. Газеталар мөхбирләрен Кобега бер чакыра алсагыз, яхшы булыр иде.

Моннан дуст-ишкә сәламнәр. Хөсусан, Хөсәен әфәндегә вә гаиләсенә.

Мәктүбләрегезне почта аша йөртеңез. Килүче — китүче гаскәрләр артыннан җибәрелсә, кырык кулга төшеп, бик соң килүе, йә югалып китүе ихтималы да юк түгелдер.

Хушыгыз, Гаяс
1951, 2 февраль. Истанбул

ТУГЫЗЫНЧЫ ХАТ

Хөрмәтле Габбас әфәнде!

Мин ике атнадан бирле Анкарадамын. Сезнең хатны Истанбулда алган идем. Хөсәен әфәнденең бүләген алгач та, үзенә җавап язган идем. Хатыгыздан андагы әхвәлне өйрәндем. Үзем дә шуннан берәр мәгънәсезлек бардыр дип шөбһәләнеп тора идем, хәерле булсын.

Инде эшкә килсәк, әүвәлән, Америка консулына килгән кәгазьгә зур әһәмият бирмәгез. Ул теге (исемлектән) төшкән халык(ның) яртысы — хөкүмәтнең эшедер. Ул вакытта үзләре тәбәгага алабыз дип сүз биргән булсалар да, ахырдан шул виза бирүгә әйләндергәннәр. Аны мин, соңыннан белгән булсам да, ул хөкүмәт төшкәнгә, сезгә язмаган идем. Бу бетте.

Инде хәзерге хәлгә килик. Килер-килмәс эшегезне тикшертергә тотындым. Бу юлы бәянамәләр мөгамәлә куелган берничә өстәлдән үтеп, кечкенәрәк мәэмүрләр өстәленә килеп кергән вә алар үзләренә мәсъүлият (җаваплылык) төшмәсен дип, законнарын да ачып күрсәткән юл булмаганга, безнең Япониядә болар хакында тикшерү өчен сәфиребез дә, консулыбыз да юк, дип, шулар булганчы бу эш торып торсын дигән карарга килгәннәр. Миңа да шул җавапны бирделәр. Мин анда баш орып, монда баш орып, кәгазьләрегезне тагы югарыгы дәрәҗәдәге мәэмүрләргә күтәрттем. Вә алар берлә озын-озын сөйләштем. Алар да «Бер кешене тәбәгалеккә алу өчен йирендә тәхкыйкать ясарга (тикшерергә) кирәк. Бу — канунда ачык күрсәтелгән», — диделәр. Мин үзем һәм дә мин анда вакытта атташе — мейстер булган Рәсди бәк(кә) (хәзер Рәсди патша): «Бу әфәнделәр хакында кәфил (җаваплы) булабыз. Кирәк тапсагыз, тагы милләт вәкилләрен дә кәфилләр күрсәтәм», — дидем. Мәэмүрләр арасында бу эшкә тагы чынлабрак караучыларга очрадым. Алар үзара сөйләштеләр, күрсәттеләр. Күрәсең, минем өченче, дүртенче күрешүләремдә хөкүмәт боларны тәбәгалеккә, анда калсалар да, алуын кабул итте.

Ләкин канун ачык булганга, мондагы кешеләрнең кәфәлате берлә генә эшне бетереп булмый. Шуңарга күрә, шул якын атналарда Япониягә бер консул җибәреләчәк. Ул бу эшне урынында тәхкыйкать ясаячак.

Сезнең бәяннамәләрне биргән әфәнделәрне ул кабул итеп, башкалары да шул юлдан үткәреләчәк,

диделәр. Минә хәзер шул консуллыкка кемнең тәгаен нтелүен күтәргә калды. Бу арада хариҗия назыйре (тышкы эшләр министры) Аурупага киткәнгә, Япониягә консул тәгатен итү бер-ике атнасыз булмас дип уйлыйм. Ул кадәр озын бер вакыт Анкарада көтә алмаганга күрә, берничә куәтле дусларыма бу эшне аңлаттым. Иртәгә актык мәртәбә хариҗиягә барып, Япониягә җибәрелүләре тәхмил булган (йөкләтелгән), ул як эшләрен белә торган берничә мәэмүрне күреп, тагы сөйләшәчәкмен. Кемнең тәгаен ителүе Истанбулда беленер-беленмәс, Анкарадагы дусларыма хатлар язып, эшегезне көтәчәк консулга аңлатырга үтенәчәкмен. Сез дә консул килү хәбәрен ишетер-ишетмәс бик тиз консулны күреп, мәсьәләне аңлатырга вә тәхкыйкать ясар өчен Кобегә чакырыгыз. Икенче групның бәянамәләре хәзер булса, аларын үз яныгызда саклап торып, килер-килмәс консулга тапшырыгыз. Ләкин шул эшләрне бер кулдан йөретеп, бер урыннан бер төрле сүз сөйләгез. Бер-берегез өстенә кирәкмәгән сүзләр сөйләмәгез. Тәбәгалеккә кабул ителү һәр мәмләкәттә — зур бер мәсьәләдер. Японидә утыз ел яшәгән агай-эненең берсенең дә бу вакытка кадәр тәбәгалеккә кабул ителмәве шуның ачык дәлиледер. Төркиядә дә ул җитди бер әйбер. Үткән-барган кешеләр ун көндә эшли торган эш түгелдер. Монда, гомумән, эшләр озак йөридер. Ун көндә трамвай билете, тимер юл билете генә сатып алып буладыр. Шуны халыкка аңлатыгыз. Минем бер кешегә дә дошманлыгым юк. Һәммәгезгә шул юлда хезмәт итүне милли вазифа дип кенә эшлим. Ләкин мин дә көче-куәте чикле бер кешемен. Монда хөкүмәтнең дә мең бер төрле эше бардыр. Безне генә көтеп тормас. Иртәгә хариҗияне зиярәт итүемдә Япониягә җибәреләчәк консул бер-ике көндә тәгаен ителәчәк кебек күренә. Тагы берничә көн Анкарада калачакмын. Генерал Шиһаб Анкарада булганга, үзен күрә алмадым. Бер дустына мәсьәләне аңлаттым. Ярдәм үтендем. Бу көнгә шулкадәр. Эшләрнең баруыннан еш-еш мине хәбәрдар итә торыгыз. Бәлки тагы мондагы берәр төрле кнопкага басарга мәҗбүрият хасил булыр. Бөтен милләтчеләргә хөрмәтләр илә сәламнәр.

Гаяс Исхакый
1951, 10 март. Анкара

УНЫНЧЫ ХАТ

Хөрмәтле Габбас әфәнде!

Сезнең күндергән рәсемнәрегезне алгач та, янына бер мәкалә кушып, Кобедагы халыкны танытыр өчен, «Яңа сабак» гәзитәсенә биргән идек. Бүгенртәгә чыга, дип тоттылар, ахырдан рәсемнәрне дә, мәкаләне дә бездән алган мөхәррирнең «югалттым» диюе берлә каршылаштык. Шулай итеп, сезнең дә хезмәтегез, минем биш-алты мәртәбә идарәгә барып йөрүләрем бушка чыкты.

Анкарадан Япониягә (консул) тәгаен ителгән зат һаман китә алмады. Сәбәбе нидер, белмим. Монда һәртөрле эш бик озын йөрегәнгә, безгә бу гаҗәп кебек тоелмаса да, сезгә, анда көтә-көтә көт булганнарга, бик авыр килә. Моны без дә беләбез. Ләкин мондагы үгез арбасы берлә йөрергә өйрәнгән машинаны (кызганычка каршы) кызуландыра алмыйбыз. Ләкин ул әфәнденең барып чыгуы берлә эшегез тәмам булачак. Монысыннан әмин (тыныч) булыгыз. Китү җирен алыралмас берегезгә мәктүб берлә белдерермен.

Инде икенче бер мәсьәлә уртага чыкты. Айлар, еллар маташа-маташа «Америка тавышы» радиосын татарча сөйләтергә карар бирделәр. Июньнең 24ендә беренче мәртәбә татарча сөйләргә башлаячаклар. Әле сәгате безгә мәгълүм түгел. Көн якынлашкач, Американың һәр җирдәге консуллыктан сәгате мәгълүм ителәчәк, диделәр. Сез дә аннан сорашып-белешеп куегыз һәм дә бөтен агай-энегә

Г.Исхакый «Жан Баевич» спектаклендә уйнаучылар белән. Уң ягында Жан Баевич ролен уйнаган Хөсәен Габдүш. Харбин. 1934 ел

шул көнне, сәгатен белдереп, барыгыз да тыңлагыз. Американың безнең халкыбызга каршы бу кадәр мәшәкатьле бер эшкә керешүе безнең төрки-татар халкымызны милләт уларак тануы дигән сүздер вә безнең өчен бик зур казаныштыр. Бу эштә сезнең Япониядәге агай-эненең америкалыларга үземезне сөйдерүемездә роле зурдыр. Безнең уртак танышларыбыз шул эшне яхшы иттереп тулы көенчә алып баручылар, Америкадагы бу эшнең башында булучылар – Нияз әфәнде Максуди һәм Габдулла Атлас (Гаффар угылы)…

Киләчәктә программаны киңәйтү өчен, төрле тәдбирләр (чаралар) алып ятабыз. Хәзергә әле моңгарчарак кына, Америка теләгәнчә генә булса да, бара-тора һәммәмез канәгатьләнерлек булачактыр. Инде шул эштә һәм безгә йөкләнгән бер милли бурыч бардыр: моның берсе – шул эшне башлаучы «Америка тавышы» радиосы мөәссәсенә (оешмасына) бер рәхмәт мәктүбен күндерүдер. Моны никадәр күп бир[сәк], никадәр күп булса, шулкадәр халыкның үз файдасын белә торган милләт булуын күрсәтеп, дәрәҗәбезне арттырачактыр. Шуны игътибарга алып, сезгә үтенеч шул: 24 июньдә беренче мәртәбә татарча радионы тыңлагач та, адресы аерым кәгазьдә куелган радио мөәссәсенә бик бәһале булмаса, бер анкета вә бер телеграмм бирегез. Икенче: татарча иттереп, булдыра алсагыз, янына инглизчәсен дә куеп, берничә мәктүб күндерегез. Мәктүбтә әүвәкән тәшәккер (рәхмәт сүзләре) вә тәбрик әйтелсен. (Шулай ук) Русия мөселманнарының йөздән туксан бише аңлый торган Казан ләһҗәсендә (сөйләшендә) сөйләшүнең тууы вә файдалы булуын белдерегез. Өченче: программага татар музыкасын, татар җырларын кертүне сорагыз. Дүртенче: Идел-Уралдагы халкыбызның мәдәнияте хакында да сөйләвен үтенегез. Бишенче: Ерак Шәрекъ мөһаҗирәтенең эшләгән милли, дини эшләрен, корган мәсҗедләрен, мәктәпләрен, матбагаларын аңлатуын да теләгез. Мәктүбләрегездә Идел-Урал төрек-татарлар мөһерене кулланыуыңыз мәгъкульдер.

Мөмкин булса, күндерелгән телеграмм вә хатларыгызның мөһерләренең копиясен үзеңездә саклагыз. Шул эшне милли бер вазифа дип эшләвегезне бик үтенәбез. Хөсәен әфәнде гаиләсенә, … Фазлый әфәнде Әгерҗе гаиләсенә, Дәүләтша… гаиләсенә вә гомумән милләтчеләргә бик күп сәлам. Дәүләтша әфәндегә сөйләгез, үзенә «Сибилер Ришад» дигән бер мәҗбуга яздырдым.

Хушыгыз. Хөрмәтләремлә
Гаяс Исхакый.
Токиолы Ибраһим Аги (төрек забиты – офицеры) аркылы хатлар җибәрдем.
1951, 12 июнь. Истанбул

ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВАНЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ

ЯРАЛЫ ЯЗМЫШЛЫ ШАГЫЙРӘ

МАРС ГАИТОВ,
Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты өлкән фәнни хезмәткәре, икътисад фәннәре кандидаты, доцент

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЫ, ТАТАРСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН СӘНГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ, ШАГЫЙРӘ ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА (1928-2005) ИҖАТЫН ТАТАР ХАЛКЫ, ӘДӘБИЯТ, СӘНГАТЬ СӨЮЧЕЛӘР, БИГРӘК ТӘ ҖЫР ЯРАТУЧЫЛАР ЯХШЫ БЕЛӘ. ҮЗЕНЕҢ ХАЛЫКЧАН, ОПТИМИСТИК КИҢКЫРЛЫ (ШИГЪРИЯТ, ДРАМАТУРГИЯ, ПУБЛИЦИСТИКА) ИҖАТЫ БЕЛӘН УЛ КҮПЛӘР КҮҢЕЛЕНДӘ.

Халкыбыз мәхәббәте лауреаты, мәшһүр шагыйрә җыр шигъриятендә ярты гасыр дәвамында бик уңышлы эшләп мәйдан тотты, милләтебезгә олуг мирас калдырды. Аның иҗаты белән телевидение, концерт залларында яңгырый торган, Тукай әйткәнчә,«җәүһәр вә кыйммәтле» җырлары аша танышырга була.

Казанның Хөсәен Мәүлетов урамындагы 13 нче китапханәдә Гөлшат Зәйнашева музее (2006 елда ачылды) бар. Биредә шагыйрә иҗатына багышланган, Яр Чаллы педагогика институты доценты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Дания Сибгатуллина-Нигъмәтҗанова язган диссертация һәм монография саклана, башка бик күп бәяннар, документлар игътибарны җәлеп итә, кызыклы мәгълүмат бирә.

Бу язмамда мин Гөлшат апа Зәйнашеваның туганы буларак (әтисе Хисам әбием Фәрхисрур белән бертуганнар), аның яралы язмышына бәйле кайбер хатирәләр белән уртаклашам.

Ни аяныч, Гөлшат апабыз гомер буе диярлек (1989 елда әтисе реабилитацияләнгәнче) Сталин, НКВД нахак яла яккан, ул елларда бик куркыныч ярлык —«халык дошманы» кызы саналды. Шул җинаятьче, җанкыйгыч даирәләр күзәтчелеге астында укыды, эшләде, иҗат итте, күп кыерсытуларга дучар булды. Бу турыда туганнары һәм бик аз кеше белде.

Ә кыскача тарихы болай.

Гөлшатның бабасы Хөснетдин хаҗи, әти-әнисе Хисам һәм Әнвәр Зәйнашевлар гаиләсе Минзәлә өязе (хәзерге Тукай районы) Иске Теләнче авылында булдыклы, хәлле крестьяннар була. Иген игәләр, мал-туар асрыйлар, революциягә кадәр кибет тә тоталар. Шушы гаиләдә 1928 елның 13

гыйнварында өченче кыз бала — Гөлшат туа. Авылда көчләп коллективлаштыру башлангач, яңа оешкан колхозга 1929 елда Хисам абыйлар да кушыла.

Әмма шул елда, Сталин уйлап чыгарган, хәлле крестьяннарны «кулак» дип репрессияләү чаралары киң колач ала. Бу кара исемлеккә Хөснетдин бабай (82 яшендә) да эләгә. НКВД башкисәрләре, авылга килеп, аны Соловкига сөргенгә озатмакчы булалар. Хисам абый, әтисен кызганып, аның урынына үзем китәм, ди.

Хисам абыйны 1930 елның 6 мартында кулга алып, канунсыз «өчлек» аны 27 майда РСФСР Җинаятьләр кодексының 58-10 нчы маддәсе нигезендә гаепли. Имеш, совет хакимиятенә каршы пропаганда алып барган, дип, бер гаепсез колхозчыны 5 елга концлагерьга озаталар. Җәһәннәм читендәге Соловки дигән ул шомлы җирнең тәмугка тиң куркыныч урын икәнен ишетеп, гомеренең шунда өзеләсен алдан белгәндәй, юлдан җибәргән бердәнбер хатында (төрмәдә хат алышу тыелган була) Хисам абый болай яза:

Капчык астык иңнәргә,
Киттек ерак җирләргә.
Әҗәлебез мондадыр дип,
Җиттек Архангельләргә.

Хисам абыйның туганы Нәҗип ага (инде вафат, урыны җәннәттә булсын) шагыйрәгә: «Син, Гөлшат, әтиеңә охшагансың, ул шигырь, җыр ярата иде, сөйләшкәндә дә шигырь куллана иде», — дигән.

Хисам абыйны белгәннәр аның теләсә-нинди эшне оста оештыру сәләтен, булдыклылыгын искә ала торган булганнар. Ул моны Ак диңгез каналын төзүдә тоткын кол буларак эшләп тә исбат итә, аңа кызыл төстәге мактау кәгазьләрен күпләп бирәләр. 1935 елда, күп михнәтләр чигеп, хөкем срогын тутырып авылына кайткан Хисам абыйны, миллионнарча башка мәхбүсләр кебек, тагын кулга алып, сөргенгә озаталар, ул инде әйләнеп кайтмый, шунда һәлак була. Меңнәрчә инсаннар язмышында бик начар эз калдырган, аларны коточкыч җәфаларга, соңгы чиктә үлемгә дучар иткән Соловки нинди җир соң ул?

Гөлшат Зәйнашева. 1959 ел

Төрле чыганакларны, энциклопедияләрне өйрәнгәч, шулар мәгълүм булды: Архангельск өлкәсенә кергән Соловки утраулары (Соловецкие острова) Ак диңгездәге утраулар төркеме икән. Аларның гомуми мәйданы 347 кв.км. Әле XV гасырда ук утрауларның берсендә Россиядә иң зурлардан саналган Соловки монастыре булдырыла. Аның биләмәсе 4-6 м калынлыкта, 8-11 м биеклектәге таш дивар белән әйләндереп алына, 7 капкасы, 8 күзәтү манарасы була.

XVII гасырда биредә 350 монах һәм барысы 700гә якын хезмәтче, һөнәрче, крестьян көн күрә. 1668 елда биредәге халык, патша һәм түрәләрнең кысуына түзә алмыйча, баш күтәрә. 7 ел дәвамында хакимияткә буйсынмыйча, фетнәне бастыру өчен җибәрелгән гаскәрләрне крепостька кертмичә саклана, көрәшә. Әмма сатлыкҗан Феоктист

исемле монах дошманга Ак манараның ныгытылмаган тәрәзәсен күрсәтә. Нәтиҗәдә, яугирләр, эчкә үтеп, 500ләп кешене үтерә, фетнә бастырыла.

XVI гасыр ахырыннан XX йөз башына кадәр Россия патшасы монастырьны мәхбүсләр өчен сөрген-төрмә итеп файдалана. Бирегә патшага һәм православие диненә каршы кешеләрне китереп ябалар.

Тарихчы В.В.Скопин язуынча, рус патшасы Иван IV XVIII гасыр башында көчләп чукындырылган малайны — татар ханы улын, 6 ел дәвамында биредә сөргендә тота. Хәтта үзенең якын кешесен — ил белән бергәләп идарә иткән кенәз Симеон Бикбулатовичны да шушы төрмәгә яптыра.

Төрмә бик рәхимсез, каты режимлы булып, даны еракларга тарала.

Соловки төрмәсе 1903 елда ябыла. Әмма хакимиятне яулап алган большевиклар аны 1920 елда, яңадан ачып, «эшкә җигәләр». Утрауларда мәҗбүри эшләр лагере оештырыла һәм 350 кеше тотыла. 1923 елдан ул «Соловецкие лагеря особого назначения» (СЛОН) буларак мәгълүм һәм 1939 елга кадәр эшли [1]. Ун меңләп гаепсез, сәяси тоткыннар биредә җәфалана, мәсхәрәләнә. Иске юеш землянкаларда, тынчу бараkларда, монастырьның җылытылмый торган биналарында ярым ач көн күргән тоткыннарның шактые шунда җан тәслим кыла. Бу җанкыйгыч лагерьда татар халкының мәшһүр уллары Мирсәет Солтангалиев, Һади Атласи, Бакый Урманче, аның бертуган энесе Ади Урманче (һәлак була), Сәгыйть Сүнчәләй, Мәхмүт Бөдәйли һ.б. михнәт чигә.

1930 ел башында каһәр төшкән әлеге утрауларга «кулак» ярлыгы тагылган меңнәрчә крестьяннарны, шулай ук дин әһелләрен, интеллигентларны күпләп китерә башлыйлар. Шулар арасында әле нәни Гөлшатның әтисе Хисам абый да була. Язучы Александр Солженицын «Архипелаг ГУЛАГ» әсәрендә 1930 елда Соловкида 50 мең тоткын булган, дип яза [2].

Татарстанда 1930 елның апрель аена 13,7 мең крестьян хуҗалыгы (гаилә әгъзаларын кертеп, 40 меңнән артык кеше) «кулаклар» дип репрессияләнә. Шул елның уртасына андый хуҗалыклар саны 20 меңгә җиткерелә. «Тоташ коллективлаштыру» елларында илдә 2 млн. крестьян нахак репрессияләнә һәм һәлак була. Бу санны миһербансыз Сталин үзе дә икърар итә, зур казаныш итеп мактана [3]. Аларның хатыннары, балалары да эзәрлекләнә, сөргенгә җибәрелә.

Тоткыннарны 1931 елның июленнән Ак диңгез-Балтыйк каналы (аңа Сталин исеме бирелә) төзелешенә китерә башлыйлар. Ноябрь аенда Соловки һәм Карел-Мурманск концлагерьлары базасында Ак диңгез-Балтыйк хезмәт белән төзәтү лагере оештырыла. Тоткыннар бу канал төзелешендә бары тик кул көче (кәйлә, көрәк) белән чиктән тыш авыр эш башкара. Ач, ялангач, туңган мәхбүс, көн саен кыядан 2 куб. метр гранит таш чокып алып, тачка (бер тәгәрмәчле кул арбасы) белән 100 метр ераклыктагы текә ярга (канал 3,7 м тирәнлектә) ташырга тиеш була. Бу эшкә өч мәртәбә бармый калганнарны атып үтерәләр.

Канал төзүгә вакыт бик кыска билгеләнгән — барысы 20 ай (сентябрь, 1931 — апрель, 1933). Шулвакыт дәвамында бик ашыгыч рәвештә 37 км озынлыкта канал казыла, 21 млн.куб.м ташлы грунт чыгарыла, 390 млн.куб.м бетон салына, 921 мең бура (биеклеге 15 метр) төзелеп, аның эченә балчык (грунт) тутырыла; 19 шлюз, 15 буа, 12 су төшергеч, 49 дамба, 33 кече канал төзелә. Күлләрне дә кертеп, бу су юлы 227 км.га җитә. Безнең Хисам абый да шушы төзелештә михнәт чигә. Кызганыч, бу турыда бернинди мәгълүмат юк. Әлбәттә, бөтенесе Сталин хакимияте һәм НКВД җәлладлары тарафыннан тирән яшерелгән. Хәтта мәетләрне дә ГУЛАГ үзенеке санаган, гаиләсенә, туганнарына тиешенчә җирләргә рөхсәт итмәгән.

Берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала

белән йорт-җирсез, ач, ялангач, хәерче хәлендә ялгыз калган әнисе ике яшьлек Гөлшатны Хисам абыйның бертуганы, Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче баласыз Мәһнуй (тулы исеме Өммеһани) апага асрамага илтеп бирергә мәҗбүр була. Гөлшат бу гаиләдә ачлы-туклы үсә, апасының икенче ире, эш сөймәүче Хөрмәкәй эчүгә сабыша, еш тавыш чыгара, мәктәптә бик яхшы укучы балага дәрес хәзерләргә комачаулый. Башлангыч мәктәптән соң, Гөлшат күрше Хуҗәмәт авылына 5 чакрым җәяү йөреп белем ала. Аннан соң 1942-1945 елларда Минзәлә педагогика училищесында (хәзер көллият) 14 яшеннән үз көнен үзе күреп, бик яхшы укый. Кешеләргә идән юып, бәрәңге бакчаларын казып җан асрый. Берничә кыз янгын сүндерүчеләр каланчасы астындагы җылытылмый торган бүлмәдә яшиләр. Кышкы салкыннарга түзәр чама калмагач, Гөлшат, кирпеч ватыклары җыеп, кечкенә генә галанка миче чыгарып куя. Моңа янгын сүндерүче абыйлар да шакката. Ә иптәш кызлары чиксез шатлана. Гөлшат бик елгыр, җитез кыз була, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, сәхнәдә җырлый, шигырьләр сөйли; үзе дә шигырьләр яза башлый, алар стена газетасында урын ала һәм район матбугатында басылып чыга.

Ә НКВД Гөлшатны даими күзәтү астында тота. Чөнки 1937 елның 15 августында сәяси репрессияләр тарихында иң рәхимсез боерык чыгарыла, ә партия Үзәк Комитеты аны хуплый. Ялган «юридик» төшенчә уйлап чыгаралар — имеш, репрессиягә дучар ителгәннәрнең балалары да «социаль куркыныч балалар» икән. Әлеге карар нигезендә, 15 яшьтән өлкәнрәк балалар кулга алынып, хезмәт белән төзәтү (тапканнар бит исем!) лагерьларына ябылырга, ә кечерәкләре, бертуганнарыннан аерып, төрле төбәкләрдәге балалар йортларына урнаштырылырга тиеш була. Карар аяусыз тормышка ашырыла.

Ул елларда дәүләт башында икенче шәхес (Сталиннан соң) булган Молотовка 1991 елда журналист Ф.Чуев сорау бирә: «Ни өчен репрессияләр гаепләнүчеләрнең хатыннарына һәм балаларына да кагылды?» Җавап болай: «Алар изоляцияләнергә тиеш иде, чөнки төрле зар-моң таратып, шикаятьләргә сәбәпче булырлар иде» [4].

Җинаятьчел хакимият үз халкына нәрсә кылганын яхшы белгән, хәтта балалардан да курыккан.

Ә НКВД үзенең мәкерле эшен дәвам итә. Педучилищедагы Гөлшат Зәйнашевага кагылышлы барлык документларны җыеп ала. 2011 елда көллият музеенда шагыйрәгә багышланган экспозиция булдырырга ниятләгән директор аларның берсен дә тапмады.

1945 елда Гөлшат, кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырып, Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Тик аңа тулай торакта урын бирмиләр. Сәбәбе — сугышта беркеме дә катнашмаган. Бу турыда, кимсенеп, Гөлшат үзенең көндәлек дәфтәренә язган була, соңыннан бик үкенә. Бер шымчы курсташы ул көндәлекне рөхсәтсез алып укый да комсомол оешмасы җитәкчесенә әләкли. Оешма җыелышында Гөлшатны бик каты тәнкыйтьлиләр. Соңрак Гөлшат апа: «Ул җыелышта мине тәнкыйть итеп кенә калмадылар, ә бик нык кыйнадылар», — дип язды. Комсомол активистлары аны тормыш авырлыгыннан зарлануда гаепләгән. Имеш, совет студентлары тормышын хурлап, төшенке рухта язган.

Гөлшат Зәйнашева бик тырыш, пөхтә студентка була, «бик яхшы» билгеләренә генә укый, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, сәхнәдә моңлы итеп җырлый, шигырьләр сөйли.

Әмма ул «халык дошманы» кызы ... һәм менә бервакыт аны институт директоры Йосыф Туишев кабинетына чакыртып, тетрәндергеч хәбәр әйтә: «Гөлшат, мин Сезне институттан чыгарырга мәҗбүр, НКВД таләп итә». Гөлшатны «халык дошманы» кызы булуда һәм институтка кергәндә әлеге



Прокуратура Российской Федерации

Татарстан Республикасы
ПРОКУРАТУРАСЫ
420503. Казан ш., Кремлевская ур., 14 йорт

ПРОКУРАТУРА
Республики Татарстан
420503, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 14

30.10.97 № 13-798-97

на № ______

СПРАВКА
О РЕАБИЛИТАЦИИ

Зайнашев Хисам Хуснутдинович,1896 года рождения,уроженец и житель с.Ст.Тлянчи,Абдуловской волости,Челнинского кантона Татарской АССР,крестьянин.

Был арестован 6.03.30 г. органами ГПУ Татарской АССР и постановлением тройки ГПУ Татарской АССР от 27 мая 1930 года заключен в концлагерь сроком на 5 лет по обвинению в совершении преступления,предусмотренного ст.58-10 УК РСФСР.

На основании Указа Президиума Верховного Совета СССР от 16.01.89 г. "О дополнительных мерах по восстановлению справедливости в отношении жертв репрессий,имевших место в период 30-40-х и начала 50-х годов",постановление тройки ГПУ ТАССР от 27.05.30 г. отменено и Зайнашев Х.Х.,как жертва политических репрессий,31 мая 1989 года реабилитирован.

И.О.Прокурора Республики Татарстан
государственный советник
юстиции 3 класса К.Ф.Амиров

Ф-ка КПИ 285р-10000

фактны яшерүдә гаеплиләр. Ике яшьтә әти-әнисеннән аерылуга дучар ителгән ятим бала әтисен бөтенләй хәтерләми. Шуңа карамастан ул совет власте өчен бик куркыныч җан иясе булып чыга.

Бу җан әрнеткеч вакыйганы яшь кыз бик авыр кичерә, әмма югалып калмый. Шунда ук Казан театр училищесына укырга керә. Берничә айдан соң институт директоры Гөлшатны эзләтеп таба һәм яңадан укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирә. (Курку белмәс, әхлаклы, бик миһербанлы кеше булган Йосыф ага.)

Институтны тәмамлагач (1949 ел), бик җаваплы эшләрдә хезмәт итә Гөлшат апа. Татарстан радиосында 16 ел дәвамында башта әдәби-драматик, соңрак музыкаль тапшырулар мөхәррире була, вазифаларын иҗади якын килеп, җиренә җиткереп башкара. Биредә ул язучылар, күренекле сәнгать эшлеклеләре белән аралаша, үзе дә иҗатка кереп китә, җыр текстлары, шигырьләр яза. Аннан соң 21 ел Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, кадрлар бүлеге башлыгы (башы да, түше дә берүзе), язучыларның Тукай клубы директоры булып бик нәтиҗәле эшли, иҗатта да үрләр яулый. 1958 елда аның «Тыңларсыңмы җырымны?» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә, иҗат дәверендә нәшер ителгән аерым китаплар саны 25кә җитә. Бик күп җырлары күмәк җыентыкларда миллионнарча тираж белән басылып чыга.

Инде 20 елдан артык нәтиҗәле иҗат итеп, җәмәгатьчелеккә, халыкка танылса да, Гөлшат Зәйнашеваны Язучылар берлегенә 1969 елда гына кабул итәләр. Гөлшат апа куштан, ялагай булмады. Кайбер кирәгеннән артык кызыл язучылар, шагыйрьләр кебек Сталинны, КПССны мактап шигырьләр язмады. Аның сәясәткә төпле үз фикере, үз карашы бар иде. Рәхәт яшәү өчен, иманын сатмады.

Гомеренең күп өлешен Гөлшат апа кысан, тузган торакларда яшәп үткәрде. Ниһаять, 1990 еллар башында аңа Мусин урамында ике бүлмәле «хрущёвка» бирделәр. Фатирыннан күчәргә җыенып йөргәндә, таныш түгел бер ир кеше килеп, аннан бушаячак бүлмәсен күрсәтүне сорый. Бу кешене район башкарма комитетыннан җибәргәннәр икән, әле генә төрмәдән чыккан. Фатирны карагач, ул: «Юк, мин мондый фатирга риза түгел», — дип чыгып китә. Ә Гөлшат апа үз вакытында бик шатланып килгән иде бирегә.

Тузган торак газапларын үз башыннан кичергән шагыйрә беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең проблеманы бик вакытлы һәм уңай хәл итүенә ихлас куанды. Гөлшат апа язучылардан беренче булып шушы вакыйгалар турында 2004 елда «Тузган торактан күчкәндә» исемле телеви-

зион нәфис фильмга сценарий язды. «Татарстан — Яңа Гасыр» студиясе төшереп, экранга чыгарган күпсерияле бу фильмны тамашачы кызыксынып карады һәм ошатты, матбугатта да уңай бәяләмәләр чыкты.

Гөлшат апа үзнең күпкырлы, бай иҗаты белән татар теле, татар мәдәнияте һәм сәнгате сагында нык торды, аяусыз көрәште. Милләтебез һәм тарих алдында Гөлшат Зәйнашеваның йөзе ак, вөҗданы пакь булды, һәм ул шулай булып кала да.

Язмышы яралы булса да, Гөлшат апа дөнья ямен, яшәү кадерен белеп, тормышка гашыйк булып гомер итте. Тормыш аны төрлечә, ә кайчакта аяусыз сынады. Әмма ул бөгелмәде, сынмады. Малга, байлыкка кызыкмады. Аның байлыгы — табигать биргән мул таланты, сәламәтлеге, гаиләсе, дуслары, халык мәхәббәте булды.

2008 елда Татарстан милли китапханәсе оештырган конкурста, Гөлшат Зәйнашеваның вафатыннан соң, 2006 елда нәшер ителгән «Сайланма әсәрләр»е «иң күп укыла торган китап» исеменә лаек булды. Димәк, шагыйрәнең иҗаты бүген дә актуаль, шигырь, җыр сөючеләрне үзенә тарта, тормышка ямь өсти.

Соңгы елларда шагыйрә иҗатын пропагандалау, якты исемен мәңгеләштерү җәһәтеннән, шактый гамәли адымнар ясалды. 80 еллык юбилее вакытында Минзәлә, Тукай, Алабуга һ.б. районнарда «Дулкыннар» дип аталган республикакүләм фестиваль үтте. 2012, 2013 елларның язында Минзәлә районында Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган «Кояш гомере телим мин, Минзәләм, сиңа» исемле әдәбимузыкаль җыен бәйрәм төсен алды. Шундый ук җыен Казан (Идел буе) федераль университетының Яр Чаллы педагогика институтында бик җылы, истә калырлык итеп оештырылган иде (2013 елның апрель ае). Казанның 13 нче китапханәсендә (җитәкчесе Сания Минкина) Гөлшат Зәйнашева музее актив эшли. Анда әледән-әле мәшһүр сәнгатькәрләр катнашында әдәбимузыкаль кичәләр гөрләп уза. Шагыйрә укыган мәктәпләрдә, Минзәлә педагогика көллиятендә истәлек такталары куелды, төбәк музеенда экспозиция булдырылды. 2011 елда Казанның яңа урамына Гөлшат Зәйнашева исеме бирелде. Татарстан китап нәшрияты шагыйрә турында истәлекләр китабы чыгарды. 2013 елда шагыйрәнең тормышы һәм иҗатына багышланган «Гөлшат Зәйнашева» дип аталган телевизион фильм төшерелеп, зәңгәр экраннарда күрсәтелде. «Татар энциклопедиясе»ндә тирән эчтәлекле мәкалә һәм шагыйрәнең фоторәсеме бирелде.

Искәрмәләр

1. Скопин В.В. На Соловецких островах. — М.: Искусство, 1990 — 200 с.
2. Солженицын А.И. Собрание сочинений: В 9 т. / [Ред.Н.Солженицыной]: Т.5: Архипелаг ГУЛАГ, 1918-1956. Ч.3 и 4. — М.: Терра, 2000. — 655 с.
3. Борев Ю.Б. Сталлиннада. — Рига: Паритет, 1990. — 368 с.
4. Чуев Ф.И. Сто сорок бесед с Молотовым: Из дневника Ф.Чуева. — М.: Терра, 1991. — 623 с.

Әдәбият

1. Гөлшат Зәйнашева: истәлекләр, мәкаләләр / [төз.: Ә.Хөсәенов, Р.Шакирова]. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2011 — 168 б.
2. Сәяси репрессия корбаннарының Хәтер китабы: Татарстан Республикасы. — 5 т.: «Е», «Ж», «З» / [редкол.: З.Р.Вәлиева һ.б.] — Казан:«Хәтер китабы» нәшр., 2002 — 446 с.
3. Солженицын А.И. Собрание сочинений: В 9 т. / [Ред.Н.Солженицыной]: Т.6: Архипелаг ГУЛАГ, 1918-1956. Ч.5, 6, 7. — М.: Терра, 2000. — 591 с.
4. Султанбеков Б.Ф., Хакимзянов Р.Г. Политические репрессии 30-х годов. Законы, исполнители, реабилитация. — Казань: Книга памяти, 1999. — 114 с.
5. Татар энциклопедиясе: 6 томда / Баш мөхәррир М.Х.Хәсәнов, җаваплы мөхәррир Г.С.Сабирҗанов/.— 2 т.: Г-Й. — Казан, 2010 — 656 б.
6. Фаттахов Г.М. Мамадышский район в годы великих потрясений. — кн.2. — Казань: Дом печати, 2009. — 295 с.
7. Шайдуллин Р.В. Крестьянство Татарстана: экономический и общественно-политический аспекты (1920-1929 гг.). — Казань: ФЭН, 2004. ■

ӘДИПЛӘРЕБЕЗ МИРАСЫННАН*

«...ТИК ГАРМУННАР ГЫНА УЙЧАН КАЛГАН, БӘХИЛЛӘШЕП КИТКӘН ЕГЕТЛӘР...»

***

Борынгыча минем тын алуым,
Борынгыча йөрәк тибешем,
Чалымым да ерак бабайлардан,
Шул дәвамны яшәп килешем.

Эстафета — уллар-оныкларда,
Каннар-моңнарыбыз бүлемсез:
Гасырларны алыштырып кына
Без атлыйбыз Җирдән үлемсез!

ОНЫТАЛМЫЙМ СИНЕ

Унҗидедә сиңа гашыйк булдым,
Үз-үземне онытып сөйдем мин.
Кая басканымны белми йөрдем,
Синең өчен яндым, көйдем мин.

Кайберәүләр әйтте: «Яшьлек үтәр.
Яшь чакта кем шулай шашмаган!»
Сәхнәләргә чыктым синең белән,
Һаман бергә йөри башладым...

Яшьлек узды, ләкин онытылмадың,
Синдә һаман минем күңелем,
Сизә барам, синнән башка миңа
Яшәү инде мөмкин түгелен...

Мине өзелеп сөйгән, якын иткән
Кеше булганда да куенымда,
Күңелемдә минем һаман да син,
Син гүзәлем генә уемда.

Әрсезләнеп киттең үзең дә син,
Трамвайда да яныма киләсең,
Урамда да мине табасың син,
Эш вакытында килеп керәсең...

Һәрвакытта күңелем синдә генә,
Башым уйлар белән шыгырым,
Язмыш мине кая ташласа да,
Мин ташламам сине, шигырем!

* Укучыларыбызга тәкъдим ителгән әлеге шигырьләр Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев (1928-2011) мирасыннан.

ОЧА ИДЕМ

Сабый чакта күргән төшем
Гомер буе чыкмый истән:
Каенсардан йөгерәм дә,
Канатланып очып китәм!

Кошлар очкан биеклектә
Манзаралар хозур иде,
Яшьтәшләрем сокланалар,
Рәхәт иде. Горур идем!

Күнектем ул очуларга,
Шуннан соң гел кабатланды,
Өнемдәге хыял-илһам
Төшләремдә канатланды.

Хәзер инде сирәк очам,
Төшләргә дә күчкән заман:
Адымнарым авыр икән,
Таныш түгел юлда калам...

...Зираттагы исемнәргә
Сагышланып карап бардым:
Ничек очыйм бер ялгызым —
Монда ята канатларым...

***

«Кайтам!» дигәннәр дә читтә кала —
Язмыш кемне кайда табадыр...
«Кайтам! Кайтам!» дигән теләкләре
Чит туфракка һаман кагадыр...

...Буш урамнар буйлап ялгыз йөрим,
Һәммәгез дә исән кебекләр.
Тик гармуннар гына уйчан калган,
Бәхилләшеп киткән егетләр...

ЮК ИКӘН КҮРӘСЕЛӘР

Үткәннәргә кайту, диләр,
Минем әле киткәнем юк,
Шушы булдымы киләчәк —
Сугышларның беткәне юк?..

Чын киләчәк юатыр, дип,
Каннар койдык, күз яшь йоттык.
Киләчәккә бара торгач,
Үткәннәргә килеп чыктык...

***

«Яшьлегемә кайтам», — диеп,
Могҗизалар көткәнем юк.
Йөрәгемдә йөртәм аны —
Минем әле киткәнем юк..

Яшьлек сүнмәс мәхәббәтем
Гомер буе үзем белән,
Күңелемә канат биргән
Әфсенле бер сүзен беләм.

Ул сүзне мин дәшми генә
Рәхәтләнеп гел яңартам.
Аны Ходаем яраткан —
Күзләремнән күр. Яратам!

***

Борчулар йөрәкне таласа,
Күңелне шом үртәп торганда,
Тынычлык табам мин урманда,
Үзгәрәм дә куям мин анда.

Күтәрәм күземне түбәннән,
Текәләм наратлар башына;
Югала минутлык йомшаклык
Йөзьеллык сабырлык каршында...

ЧЕЛЛӘДӘ
(Балачак истәлеге)

Көтүеннән качып кайткан сарык
Ышыккарак барып сыена,
Тавык-чебеш, тузгып, кабарынып,
Нигез туфрагында коена.

Казык башларында, авыз ачып,
Әлсерәгән итек тик тора.
Саргылт чирәмнәргә палас җәеп,
Әби — карчык бодай киптерә.

Чолан җиләсендә бала-чага,
Ялый-ялый агач кашыкны,
Ак мыеклар ясап, гадәтенчә
Ялт иттерә салкын катыкны.

Ишегалды мич башыдай кайнар,
Яланаяк бассаң, пешерә.
Каралтыга сөялгән дә чана,
Салкын кышны искә төшерә... ■

МӘКТӘП ЯШЕНДӘГЕ БАЛАЛАРГА

ОЛУГ ШӘҺӘРДӘ КУНАКТА

(1235 елның җәе)

РУХИЯ АХУНҖАНОВА,
шагыйрә, Ш.Маннур исемендәге әдәби премия лауреаты

ЭЧКЕ ШӘҺӘРДӘ

Ике кат имән дивар белән әйләндереп алынган эчке шәһәргә юл Көнчыгыш капка аша үтә. Теләй абзый Ак кашканы шул якка борды.

Монда йортлар тыгыз урнашкан. Аларның ике кырлы түбәләре без күзәтеп килгән манзарага әкияти төсмер өстәп тора. Юлыбызда очраган мәсҗидләрнең манара чатырлары да очлаеп килгән матур бер калыпта эшләнгән. Кабатланмас гүзәл күренеш…

— Биләр — бик зур кала, — дип сүз башлады Теләй абзый. — Күрегезче мондагы йортларны! Таштан, кирпечтән салынганнар. Минем танышымның да йорты гөмбәзсыман түбәле, ике катлы. Үзе кирпечтән эшләнгән. Зур мичтән килгән җылы һава, идән астындагы һәм диварлардагы һава юллары буенча үтеп, барлык бүлмәләрне дә җылыта. Шулай булмаганда, Хан сарае хәтле ул йортны ничек җылытып бетермәк кирәк?! — диде ул, безгә борылып карап.

Менә сәүдә рәтенә дә килеп җиттек. Уң кул якта, бер рәт булып, сәүдә гөрли.

Тактадан тар сәке рәвешле итеп ясалган урыннарга күпләп төрле нәрсәләр тезеп куелган. Сатучылар үз әйберләрен мактап, алырга чакырып торалар.

— Сурәтле йозаклар сатып алыгыз!

— Пычак һәм балталарның йөзләре корычтан коелган!

— Бакыр казан, җиз комган! Кемгә кирәк?

— Бизәкле көзгене башка җирдә таба алмассыз!

Малайларны үзе белән ияртеп, Теләй абзый урта рәткә таба китте. Без, кызлар, бизәнү әйберләре янында тукталып калдык.

Озынча өстәлгә сөяктән зәвык белән эшләнгән әйберләрне

Манзара — күренеш.
Манара — мәчет түбәсендә яки аның янында гадәттә түгәрәк, дүрт яисә күпкырлы тар конус рәвешендә эшләнгән биек корылма.
Данә — бер төрдән булган әйберләрнең берсе; экземпляр.
Хәттат — матур язу остасы, каллиграф.

* Дәвамы. Башы 10 нчы санда

рәт-рәт итеп тезеп куйганнар. Тараклар, төймәләр һәм сәдәфләр янына күзне кызыктырырлык матур хәситә дә куелган. Күлмәк өстеннән күкрәккә киеп куела торган мондый бизәнү әйбере минем әнкәйдә дә бар. Ул аңа бик килешеп тора.

Кинәт якында гына энемнең:

— Без күн аяк киемнәре, капчыклар, матур каешлар күрдек, — дигән тавышы ишетелде. Безгә яңалык итеп әйтүе икән.

— Сатуда нәрсә генә юк! Нәрсә генә юк! — диде Теләй абзый, әллә шатланып, әллә борчылып. Шунда ук үз сүзләренә үзе үк җавап та бирде. — Китап юк! Китап! — диде ул, кем беләндер бәхәсләшкәндәй. — Чөнки бер генә данәдә була ул! Күчергәндә дә, матур итеп, еллар буена кулдан язарга кирәк. Хәрефләрне энҗедәй тезеп, аны хәттатлар күчереп яза. Кыйммәтле туар! Кыйммәткә күрә, кадерле дә...

Теләй абзый, кирәксенеп, язу тарихын да сөйләп алды. Мамыктан ясалган кәгазьне безнең бабайлар IX-X гасырларда ук Сәмәркандтан китерткәннәр икән. Язу карасын яндырылган балчык кулланып эшләнгән савытка салганнар. Аңарчы очлы сөяк таякчыклар ярдәмендә каен тузына, балавыз сөртелгән тактага яза торган булганнар. Сөяккә, балчык чүлмәкләргә, бизәнү әйберләренә дә язганнар, һөнәрчеләр үз тамгаларын салганнар.

Теләй абзый:

— Гарәп язуы өчен иң кулае — кәгазь икән, — дип куйды.

ҖАМИГЪ МӘСҖИДЕ

Олау хуҗасын тыңлап бара-бара, шәһәр үзәгенә килеп җитүебезне сизми дә калганбыз.

Ике катлы кирпеч йортларның күплегенә шаккаткан энем кинәт:

— Нигә монда йортлар бик күп?! — дип сорады.

— Халык күп яши биредә, Айтимер энекәш, — диде Теләй абзый, — шуңа күрә йортлар да күп. Аксөякләр, бай сәүдәгәрләр, оста һөнәрчеләр шушында бит инде. Менә син дә, зур кеше булгач, шушында яшәрсең!

Мин дә, абзыйның сүзен җөпләп, энемнең башыннан сыйпап куйдым.

Матур агач диварлар белән уратып алынган үзәктә Хан сарае, Җамигъ мәсҗиде, дәүләт хезмәте биналары урнашкан икән. Мәхәллә мәсҗидләре белән чагыштырганда, Җамигъ мәсҗиде бигрәк мәһабәт бина шул. Аның биек манарасы ерактан ук күренеп тора. Җомга намазлары шушында укыла икән инде.

Борынгырак өлеше — юан бүрәнәдән, яңасы ак таштан салынган изге йортка энем белән икәүләп тәэсирләнеп карап тордык. Белемчәк белән Айсылуның Җамигъ мәсҗиден беренче генә күрүләре түгел икән.

Ак таш белән кызыл кирпечтән салынган манара мәсҗидтән ике адымлап читтәрәк. Манараның кечкенә тәрәзә уемнары төрле биеклектә ясалган. Эчке яктагы бормалы баскычлардан өскә

Аксөяк — затлы, югары нәселдән булган кеше; аристократ.
Җөпләү — яхшы дип табу.
Мәхәллә — шәһәр һәм авылның бер мәчеткә караган өлеше; квартал.
Мөәзин — мәчеттә азан әйтүче дин әһеле.
Мөселман — ислам динендәге кеше.
Намаз — көндәлек гыйбадәт.
Җәмигъ — бөтен, барлык, һәммә.
Әрвах — рух (җан).
Балигъ — үсеп җиткән.
Мөбарәк — ка-

күтәрелеп, мөәзин моңлы, аһәңле тавышы белән мөселманнарны биш вакыт намазга чакырадыр. Намаздан соң, җыйнаулашып, җәмигъ әрвахларга дога кылалардыр…

Безгә мәсҗиднең тышкы ягын карарга мөмкинлек биреп, бераздан үз тирәсенә туплаганнан соң, Теләй абзый:

— Җомга намазлары фәкать Җамигъ мәсҗидләрендә генә укыла, — дип сүз башлады. — Җомга намазын ир кешеләр генә укыйлар. Ир баланың 12 яшькә җитүе, ягъни мәсәлән балигъ булуы шарт. Кыскасы, шушы җирлектә яшәүче, акыллы, саусәламәт, күзләре күрә, аяклары йөри торган һәр ир-ат җомга намазын укырга тиеш.

Теләй абзыйга мин дә сорау бирергә булдым.

— Ул намазны нигә нәкъ менә җомга көнне бергә җыелып укыйлар?

— Балалар, җомга көн — мөбарәк һәм бәйрәм көн. Бу көнне догалар һәм изге гамәлләр кабул була. Тагын шунысы бар: җомга намазлары туганлык, бердәмлек рухын ныгыта. Башка намазларны да җәмәгать намазлары итеп укырга мөмкин. Ялгыз укуга караганда, сәвабы да күбрәк була. Өйлә намазы вакытында укыла торган җомга намазларының башка намазлардан аермасы шунда: ул көнне имам кешеләргә вәгазь сөйли, дини белем бирә. Аңлашылдымы?

— Әйе, Теләй абзый, аңладык, — дидем мин, барыбыз өчен дә җавап биреп.

Мәсҗид бинасы кыйблага карап тора. Бер ягы белән бина диварына кертеп ясалган дүрткырлы терәк баганалар мәсҗиднең алгы ягына матурлык өстиләр. Керү ишеге бизәкләп эшләнгән.

Әүвәл уң аягын атлап, эчке якка Теләй абзый узды. Без дә аңардан калмадык. Ул:

— Йә Рабби, миңа рәхмәт ишекләреңне ач һәм рәхмәт хәзинәләреңне чәч, — диде. Доганы без дә кабатладык.

Барыбыз да эчкә уздык. Мондагы дүртәр терәк багана нәкъ алты рәт булып тезелгән. Димәк, түбәне егерме дүрт багана күтәреп тора. Бинаның түшәме биек. Мәсҗиднең идәненә фарсы келәме җәелгән.

Түр диварда эчкә таба уеп, кыйбла тарафын күрсәтү өчен, михраб ясап куелган. Бу махсус урын, намаз укырга дип, мулла өчен билгеләнгән. Баскычлы биек урын мөнбәр икән. Мулла шуннан кешеләргә гыйбрәтле вәгазьләр сөйли, ди. Димәк, гыйбадәтне мәсҗиднең таштан салынган шушы өлешендә кылалар.

Теләй абзый:

— Мәсҗидне карау өчен генә кергәнгә күрә, «Тәхийәтел мәсҗид намазы» дип аталган намаз укып алырбыз. Ул мәҗбүри намаз түгел, әмма аны кеше күңеле теләп укый, — дип аңлатты.

Үзебезне тиешле рәвешкә китергәч, икегә бүленеп, намаз укып алдык.

Бинаның эчке ягын тагын бер кат күздән кичергәннән соң, әүвәл сул аякны атлап, Аллаһ йортыннан чыгарга кузгалдык.

Теләй абзый, туктап:

дерле, хөрмәтле.
Олуг — олы.
Гамәл — эш.
Җәмәгать — җыелган халык.
Сәваб — савап, әҗер (яхшы эш өчен бирелгән бүләк).
Өйлә намазы — төш үткәч тә укыла торган намаз.
Имам — кешеләрне үзенә ияртеп намаз укытучы мәхәллә башлыгы, өлкән мулла.
Вәгазь — үгетләп, өндәп сөйләнгән сүз.
Мәгълүмат — белем, хәбәр.
Кыйбла — Мәккәгә караган як; намаз укыганда, мөселманнарның йөз белән торган ягы.
Гыйбадәт — Аллаһка табыну, сыгыну, аңа гозерләнү, ялвару, аны олылау, мәдех әйтү (мактау) белән бәйләнгән дини йола.



Җамигъ мәчете янындагы «бай феодал йорты». Альфред Халиков реконструкциясе; Алексей Мазанов рәсеме

Шәмсираван шушы йортта яши.

— Йә Рабби, мин Синнән олуг рәхмәтеңне сорыймын, — дип дога кылды. Без дә авыз эченнән әлеге теләкне пышылдадык.

Без мәсҗидтән урамга чыктык.

Теләй абзыйның Җамигъ мәсҗиде турында сүзе бетмәгән икән әле.

— Соңрак мәсҗиднең турыпочмаклы агач бинасына терәп, таштан яңасын төзеп куйганнар. Җамигъ мәсҗиден «Бараҗ» дип атаганнар. Төзелешкә акчаны Субаш атлы эре сәүдәгәр үзеннән чыгарган. Ул үләннәр белән дәвалаучы атаклы табиб та булган. Биләрдә хастаханә төзетеп, шунда ук даруханә дә ачкан...

Хәтеребездә калдырырга теләгәндәй, бинаның тышкы ягын тагын бер мәртәбә җентекләп күздән кичердек. Җамигъ мәсҗиден энемнең дә, минем дә күрәсебез килгән иде. Менә күрдек инде.

— Тагын да соңрак, — диде Теләй абзый, сүзен дәвам итеп, — шул «Бараҗ» мәсҗиде каршында дарелголум, ягъни гыйлем йорты ачканнар. Минем танышым Шәехби бүгенге көндә шунда тыйб фәнен укыта. Шәкертләргә кешенең тән төзелеше, дару үләннәре турында белем бирә. Ул әнә теге йортта яши.

Теләй абзый бик зур йортка таба төртеп күрсәтте. Аннары арбадагы әйберләре арасыннан бизәкле бер тартма алды да:

— Таҗетдин бине Юныс әл-Болгариның «Әт-тиръяк әл-кәбир» — «Агуланудан көчле дәва» дигән китабы бу. Иясенә тапшырыйм, — дип, гөмбәзсыман түбәле, ике катлы зур кирпеч йортка кереп китте. Ә без арбага менеп утырдык.

Рәкәгать — намазның аягүрә тору, иелү һәм башны җиргә куюны эченә алган бер өлеше.
Табиб — врач, доктор.
Хастаханә — шифаханә, больница.
Дарелголум — гыйлем йорты.
Тыйб — медицина.
Шәкерт — мәдрәсәдә укучы.
Таҗетдин бине Юныс әл-Болгари — XII гасырның икенче яртысы — XIII гасырның беренче чирегендә яшәгән болгар табибы һәм фармакологы.

ШӘМСИРАВАН

Теләй абзый озак көттермәде. Үзе белән бер ир бала ияртеп чыгып та җитте. Аңа безнең яннан урын күрсәтеп:

— Шәмсираван, урнаш шунда, — диде.

Чөңгерү — атны куалаганда үзенә бертөрле сызгырып җибәрү.

Җиңел сөякле малай арбага җитез генә менеп кунаклады. Сәлам бирештек. Айсылу минем янәшәмә көчеп утырды.

Теләй абзый, дилбегәсен кагып:

— Йә, малкай, әйдә, — дип, җиңелчә генә чөңгереп җибәрде. Шуны гына көткәндәй, Ак кашка урам буйлап юыртып китте.

Белемчәк тә:

— Әйдә, бахбай, әйдә! — диде, куллары белән ат куалаган хәрәкәт ясап.

Без ат юырткан көйгә як-ягыбыздагы биек-биек йортларның яшькелт төстәге тәрәзә пыялаларына сокланып карап бардык. Бу, чыннан да, бик матур манзара. Барыбызның да күзләре шунда. Кунак малае Шәмсираванның гына исе китмәде. Чөнки үзләренең дә тәрәзә пыялалары яшел төстә ич. Ул аңа ияләнгәндер инде.

Энем Айтимер генә һаман:

— Әллә-лә! — дип тел шартлатты.

— Бу йортларда бай кешеләр яши, — диде Теләй абзый, хисләнгән энемә карап.

Бераздан:

— Байларның зиннәтле йортлары — шәһре Биләрнең мактанычы, — дип өстәде һәм, артына борылып:

— Шулаймы, Шәмсираван? — дип, аңа күз кысып алды.

Шәмсираван матур итеп елмайды. Юл буена «әйе», «юк»тан узмаган, сүзгә саран малай бу юлы да тыныч кына утыра бирде. Белемчәк белән Айтимер шикелле такылдамады.

— Шәмсираван тел бистәсе түгел.Сүзен үлчәп кенә әйтә. Әз сүзле, — диде Теләй абзый. — Иллә мәгәр укуын күп укый. Биләр җегетләре хосусан шундаен алар.

Әтисенең сүзенә Белемчәк тә кушылды:

— Моназарә вакытында Шәмсираван гел алга чыга, әйеме, әткәй...

— Шулай, углым. Шәмсираван сүз көрәштерүдә алдынгылыкны бирми. Шәп моназир!

Мондый мактау сүзләреннән Шәмсираван борсалана башлаган иде инде.

Теләй абзый сүздән туктауга, ул:

— Без — болгарлар ич. Ә «болгар» сүзендә «белемле» дигән мәгънә ята, — дип куйды.

— Аңладыгызмы?! — диде Теләй абзый, безнең якка сораулы караш ташлап.

Аңламыйбызмы соң?!. Аңладык, әлбәттә!

Бахбай — атка иркәләп эндәшү.
Зиннәтле — кыйммәтле, затлы.
Шәһре Биләрнең — Биләр шәһәренең.
Такылдау — кызу һәм бик күп сөйләү.
Тел бистәсе — сүзгә оста һәм кирәгеннән артык күп сөйләүче кеше.
Иллә мәгәр — бик тә, бигрәк тә.
Хосусан — хосусән, аеруча, бигрәк тә.
Шундаен — шундый.
Моназарә — моназара, сүз көрәштерү, бәхәсләшү; дискуссия.
Моназир — бәхәсләшүгә, сүз көрәштерүгә оста кеше.
Борсалану — тынычсызлану, борчылу.
Болгар — Идел буе Болгарында яшәгән халык.

АК КАШКА

Без, кайтышлый, җигүле ат белән сәүдә рәтенә килеп җиткәндә, сату-алу эшләре төгәлләнеп килә иде инде. Сәүдәгәрләр, әйберләрен җыйнап, өйләренә таралышырга торалар иде.

Теләй абзый Ак кашканы туктатты:

— Тыпруу! Тукта, малкай!

Белемчәк тә:

Кыерчык — түгәрәк итеп пешерелгән икмәктән башлап кисеп алынган зур телем.
Гамь — игътибар, күңел кую.

— Трр, бахбай, трр! — диде.

Без арбадан җиргә коелдык. Оеган тәннәребезне язып, үзара төрткәләшеп алдык.

Атына Теләй абзый ипи кыерчыгы каптырды. Аннары, яратып, башыннан сыйпап алды. Шуннан соң арбадагы төенчекләр арасыннан кечкенә капчык тартып чыгарды. Җитен тукымадан тегелгән капчыкка арпа салынган иде.

Малайлар ат тирәсендә кайнаштылар.

— Баһ! Баһ!

Ак кашканың аларда гаме юк. Ул һаман тәмләп ашавын белде.

Айсылу белән икебез ат дугасына беркетелгән кечкенә җиз кыңгырауны карадык.

— Шөлдер чең-чең, чең-чең итә. Ишетәсеңме?

— Ишетәм, Айсылу, җиз кыңгырау «җырлый»!

Белемчәк ат тотучы малай булып әтисе урынына менеп утырды. Кулына кыска гына нечкә таяк тотты. Аның артыннан Айтимер белән Шәмсираван да Теләй абзый булып кыланып күрсәттеләр.

— Миңа алмашка ат башында йөрерлек җегетләр үсеп килә, шөкер… — диде дә Теләй абзый арбадан бер дәү генә төенчек алып, аны чишеп җибәрде. Төенчек эченнән тәмле-томлы ризыклар килеп чыкты.

Без тамак ялгап алдык та юлга кузгалдык.

Бераз юл алуга:

— Ак кашка-а! — диде Теләй абзый, сузып.

Ак кашка, кинәт адымнарын акрынайтып, ике колагын да торгызды.

— Менә күрдегезме?! Ат — нинди сак, акыллы хайван! Аңа эндәшсәң — аңлый. Хуҗасын шундук танып ала, аңа берсүзсез буйсына.

Теләй абзыйның Ак кашка турында сөйлисе килә иде, ахры. Тел төбеннән шул аңлашылды.

— Ат — үзенчәлекле хайван. Түземле, көчле. Өстәвенә аңлы да. Ат үзен кайгырта белә. Мәсәлән, җил чыга икән, болында утлап йөргән җиреннән китеп, ул үзенә тиз генә ышык урын таба. Андый очракта «югалган» атыңны урман тирәсеннән яисә чокыр-чакырлы урыннардан эзлисең. Һәм ул шунда була да. Ат бигрәк тә агач төпләрендәге үләнне кырып ашарга ярата.

— Ат төнлә генә йоклыймы?

Сорауны энем Айтимер бирде.

— Атлар теләсә кайсы вакытта йоклый алар. Аяк өсте йоклыйлар. Әйтик, хуҗасы йомыш белән кемгәдер кереп китте, ди. Капка төбендә калган ат, хуҗасы кире әйләнеп чыкканчы, бик рәхәтләнеп черем итеп алырга өлгерә.

— Ничек егылмый соң ул?!

— Ат, йокыга киткәч, аяк буыннарын «йозакка» бикләп куя икән. Җиргә аумавы шуннан. Аллаһы Тәгалә аны шундый итеп яралткан.

— Атларның да дуслары буламы?

Шөлдер — кечкенә кыңгырау.
Ат башы — ат йөртүче.
Шөкер — ризалык, канәгатьләнгәнлек белдерү.
Тамак ялгау — ачыгуны басар өчен аз гына ашап алу.
Тел төбе — сүзнең эчке мәгънәсе, әйтелгән сүз, сөйләү артында торган теләк, максат.
Черем итү — ярым йокы хәлендә булу.
Аллаһы Тәгалә — бөтен нәрсәне бар итүче, бөтен дөнья белән идарә итүче илаһи зат.
Яралту — барлыкка китерү.
Тимеркүк — кара көлсу төстәге ат.
Улак — юан агачтан чокып ясалган озынча савыт, тагарак (хайваннарга болгатып азык бирү һәм су эчертү өчен кулланыла).
Камыт — ат муенына кидерелә торган җигү әйбере.
Дирбия — кирәк-ярак.
Камыт сугу — ат муенын камыт белән кырдырып чиләндерү.
Ыңгырчак — атның сыртына куелып, өстеннән аркалык үткәрелә торган җайланма, өсте күн белән капланган киез мендәрчек.
Җәрәхәт — тәндәге яра.
Тояк — атның

— Була, Айтимер, була. Аларның да аерым якын күргән дус атлары була. Атлар ерактан ук кешнәшеп сәлам бирешәләр. Аларның сәламләшүеннән һавалар чыңгылдап китә. Дус атлар ризыкны да бүлешеп ашыйлар.

— Ак кашканың дус аты бармы соң?

— Аның да дус аты бар. Тимеркүк безнең күршедә генә.

— Ак кашка нәрсәне дә булса алдан сизенәме?

— Хайваннар алар барысы да сизгер. Шул исәптән атлар да. Улагындагы ризык арасында ялгыш килеп эләккән чит нәрсә була икән, Ак кашка аны ашамыйча аралап калдыра. Гомумән, атлар хәтта энәне дә сизәләр. Хуҗаның да атка карата һәрчак игътибарлы булуы кирәк. Атны озак һәм кызу йөртеп, шабыр тиргә батырырга, хәлдән тайдырырга ярамый. Моны «атны яндыру», диләр. Атка артык авыр йөк төяп, өшәндерергә дә ярамый. Ат муенын камыт белән чиләндергән хуҗалар да очрый. Тиресе чиләнмәсен өчен, дирбиясенең үлчәме дөрес булырга тиеш. Камыт «суккан» яки ыңгырчак «тигән» атны җәрәхәте төзәлмичә җигәргә ярамый. Шула-ай, ат башы бик күп нәрсәләрне күрә. Дөньяда күпне күргән кешегә дә «тояк суы эчкән кеше», диләр бит.

Тояк дигәннән, безнең урманда тояк үләне дә үсә ич. Аны «тайтояк» дип тә йөртәләр. Усак агачларын ярата тайтояк үсемлеге, шулар арасында үсә дә. Аның җиргә коелган орлыкларын, имеш, эшчән кырмыскалар үзләре белән алып китәләр икән. Алып китәләр икән дә, орлыгына тимичә, аның ак үсентеләрен генә ашыйлар икән. Исән-имин калган әлеге орлыклардан өр-яңа үсентеләр тишелеп чыга икән. Тишелеп чыгалар икән дә, матур булып үсеп китәләр икән. Куе яшел яфраклары янында көрәнсу-кызыл төстә нәфис чәчкәләр «борын төртә» икән.

Әйе, тайтояк, дөрестән дә, нәкъ ат тоягы сыман эре һәм каты яфраклы. Рәвеше белән бөергә дә охшап тора үзе. Әмма үләннең исеме — тайтояк...

Тәүге тайтояк үләне атның тояк эзеннән үсеп чыккандыр сыман. Минем үземә шулай тоела...

Теләй абзый, безгә таба борылып, серле генә елмаеп куйды.

— Атны кулга беренче ияләштерүче халык — безнең бабаларыбыз ич! — диде ул, горур тавыш белән. — Алар атларны авыр эштә, сәүдәдә, сәфәрдә, яуда кулланганнар. Озын торыклы, озын муенлы аргамак — иң яхшы гаскәри ат. Андый ат сыбайны, ягъни атлы гаскәрине аңлый, тыңлый, төрле оста хәрәкәтләр башкара белә. Бу һөнәрләргә атны махсус өйрәтәләр. Сыбай аты өстендәге гаскәри белән бергә авышып, тиз генә борыла алса, ат үзе дә, җайдак та үлемнән котылып кала. Атның бу һөнәре «дим» дип атала. Әлеге һөнәргә ия булган ат димле ат була. Андый ат бик кыйммәт тора.

— Яу атларын чыныктыралардыр да әле...

— Әйе, Шәмсираван. Алар чыныксын дип, ерак арага ат ярышлары үткәрәләр. Ярыш алдыннан атны яраулаталар, ягъни

аяк бармакларын каплап торган мөгез сыман катлау.
Тояк үләне (тайтояк) — кирзазончалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; тояк сыман эре һәм каты яфраклы күпьеллык агулы үлән (копытень).
Торык — аяк, бот.
Аргамак — чабышкы ат.
Җайдак — атка атланган кеше.
Ак — кар, сөт һәм акбур төсенә якын ачык төс.
Акбүз — сизелер-сизелмәс кенә күк төсмере булган ак төс.
Алмачуар — аксыл таплары булган җирән яки күк төс.
Бурлы — кара яки кызыл өстендә бөртек-бөртек ак йонналы булган төс.
Бүз — соргылт, аксыл соры төстәге.
Бүртә — саргылт яки аксыл таплары булган туры төстәге.
Кара — корым, күмер төсендәге.
Коба — аксыл, сыек көрән төс.
Коба кызыл — җирән кызыл.
Коба туры — бурлы ат.
Кола — кара койрыклы һәм кара яллы аксыл җирән төс.
Коңгырт — карасу көрән төстәге.
Көрән — дарчин яки кыздырылган кофе төсендәге;

чабышка әзерлиләр. Махсус ашаталар, тәрбиялиләр, ерак араны чабып әйләнергә күнектерәләр.

— Нигә кайбер атлар әкрен, ә кайберләре тиз йөриләр икән соң?

— Афәрин, Айтимер, бигрәк күзәтүчән икәнсең. Атларның йөрешләре аларның холыкларына бәйле. Чаман ат әкрен йөри. Чалык ат тиз йөри. Чарыс ат — тиз йөрешле ярсу ат. Артак ат — өйрәтелмәгән, кыргый ат.

— Атларның төсләре…

— Әйе, Шәмсираван. Атларның төсләре төрле-төрле була. Ак, акбүз, алмачуар, бурлы, бүз, бүртә, кара, коба, кола, коңгырт, көрән, күк, күк-ала, күкбүз… Булдымы? Тагын саныйммы?

— Әйе, әйе.

— Сары, тимер-күк, туры, тәңкәчуар, чал, чуар, җирән. Шунысы бар: тимер-күк төстәге колыннар бик сирәк туа.

Мин эчемнән: «Ак кашканың дус аты Тимеркүк сирәк атларның берсе икән», — дип уйлап куйдым.

— Хәрби атлар элек «тулпар» дип йөртелгән. Димле тулпарларга атланган бабаларыбыз III гасырда вак атлы кытай гаскәрләрен тар-мар иткәннәр. Шуннан соң кытайлар да үз атларын яхшырту чарасына керешкәннәр, — дип, Теләй абзый сүзен тәмам итте.

Энем Айтимер кинәт:

— Конан, дүнән атлар нинди атлар? — дип сорады.

— Син аны каян беләсең?! — дип гаҗәпләнде Теләй абзый.

— Әткәйдән ишеткәнем бар.

— Ә мәгънәсен сорамадыңмыни?

— Ул чакта сорамадым шул. Хәзер исемә төште…

— Конан — өч яшьлек ат. «Дүнән» дип дүрт яшьлек атка әйтәләр. Бер яшькә кадәрге ат баласын — «колын», ә икенче яшькә чыкканын «тай» дип атыйбыз, — диде Теләй абзый.

коңгырт төстәге.
Күк — аксыл соры төстәге.
Күк-ала — нинди дә булса таплары булган аксыл соры төстәге.
Күкбүз — аксыл соры төстәге.
Сары — ком, әфлисун, алтын төсендәге.
Тимер-күк — кара көлсу төстәге.
Туры — кара койрыклы һәм кара яллы кызылсу җирән төс.
Тәңкәчуар — алмачуар (аксыл таплары булган җирән яки күк төс).
Чал — бурлы (кара яки кызыл өстендә бөртек-бөртек ак йоннары булган төс).
Чуар — төсендә кара яки карасу таплар булган төс; аклы-каралы, аклы-кызыллы.
Җирән — кызгылт-көрән төс.
Тулпар — бик шәп, чапкын ат.

Дәвамы алдагы саннарда

Әдәбият

1. Әхмәтьянов Р. Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. — Казан: Татар.кит. нәшр., 2003.
2. Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш. Булгарская цивилизация на Волге. — Казань: Татар. кн.изд-во, 2011.
3. Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1999.
4. Измайлова С., Измайлов И. Булгарское вооружение X-XIII вв. Буклет.
5. Ислам (белешмә-сүзлек). — Казан: Татар. кит.нәшр., 1993.
6. Мифтахов З.З. Курс лекций по истории татарского народа. — Казань: Издательство «Дом печати», 1998.
7. Мөхәммәтшин Җ., Вәлиев Р. Бөек Болгар — болгар-татар цивилизациясенең һәйкәле. — Анкара, 2000.
8. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1981.
9. Хәмзин К.З., Мәхмүтов М.И., Сәйфуллин Г.Ш. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1965.
10. Хуҗин Ф. Биләр — Олуг шәһәр. — Казан: «Печатный Двор» типографиясе, 1997.
11. Хуҗин Ф. Җир астында серләр бар. — Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2008.
12. Хузин Ф. Биляр — Великий город. — Казань: Татар.кн.изд-во, 2007.
13. Хузин Р., Измайлов И. Волжская Булгария глазами живописца и историка. — Казань: Заман, 2011.
14. Яхин Ф. Пәйгамбәрләр тарихы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1992. ■

ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ЯЗМЫШЫ*

БӘТҮЛ ҖОШКУН,
филология фәннәре кандидаты,
Истанбул Фатих университеты фән-әдәбият факультетының төрек теле һәм әдәбияты бүлеге доценты

«Язучы үз биләмәләренә, язмышы очраштырган чорга хуҗа булырга тели, ул үз дулкыннарын уйнатып, үз агымын тудырып, халкына, милләте каршына бара: мә, ал, халкым! Бу әсәрләрдә минем газап-сөенечләрем, безнең уртак язмышыбыз. Мин сезне күрәм, ә сез мине күрәсезме?»

А.Гыйләҗев

Милләтләрнең яшәеше милли мәдәниятләрнең дәвамлылыгына бәйле. Ә аның дәвамлылыгы бары тик милли хәтерне саклап калган очракта гына мөмкин. Ассимиляция сәясәте нәтиҗәсендә юкка чыгарга тиешле милләт, аның яшәешен дәвам иттерү хакына алып барылган көрәш — әдәбиятны югары кимәлдә тота. Соңгы берничә гасырда Россия басымы астында булган төркиләрнең милли үзаңын югалтмас өчен алып барган көрәшләре әдәбиятта да чагылыш тапкан. Советлар Союзы чорында илдәге төркиләрдән яңа кеше — Совет кешесе ясауга юнәлтелгән коммунистик сәясәт милли үзенчәлекләрне саклауга мөмкинлек бирми. Шулай ук төрки әдипләр өчен иҗат каләмен иҗтимагый тәнкыйть коралы буларак куллану башка сыймаслык хәлгә әверелә. Язучылар я иҗтимагый темалардан читләшкән, яки символларга, эзоп теленә сыенырга мәҗбүр булган. Кайберәүләр генә батырчылык итеп, үз җаннарын куркыныч астына куеп, тәвәккәлләп, каләмнәрен «газиз милләт» юлында хезмәт иттергән. Советлар Союзы чорында төркиләрне ассимиляцияләштерү мәсьәләсе Төркиядәге әдәби мохиткә дә күчә һәм Мәшрутият дәверендә «Туранчы әдәбият» төркиләрнең төп мәркәзе булган илгә ишарә кыла. 1918 елда: «Мәктәп-мәдрәсәләр, зиһеннәр, башлар руслаштырыла», — дип оран салган Мүфидә Фәрит, Россия төркиләренә янаган куркыныч киләчәкне күреп, Госманлы «әфәнде» шәрык төркиләре «кол» хәлендә булуга, «аяусыз дошман тарафыннан изелүгә» басым ясый [1]. Госманлы дәүләтеннән соң төзелгән Төркия җөмһүрияте алып барган «Төркия төрекчелеге» сәясәте нәтиҗәсендә, «Төп Ватан — төркиләр иле» төшенчәсе әкренләп Төркия әдәбияты хәтереннән җуела һәм көн тәртибеннән төшеп кала.

Советлар Союзы чорындагы атамасы белән әйткәндә, Урта Азиядә руслаштыру сәясәте башлангач, бу җирлектә яшәүче төрки әдипләр милли хәтерне саклау өчен зур көрәшкә керешә. Шул елларда тавыш-тынсыз утыру урынына җан ачысы белән оран салу юлын сайлаган, иҗатында милли-дини кыйммәтләрне кыю һәм тәвәккәл рәвештә чагылдырган әдипләрнең бер-

* «Кардәш каләмнәр» (Анкара) журналында (Bir coğrafyanın kaderini yüklenmek «Cuma günü akşam...» // Кардәш каләмнәр. – 2013. – №77. – Б.84-89) дөнья күргән әлеге мәкалә А.Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән» повесте төрек теленә тәрҗемә ителеп басылу уңаеннан язылган.

се — татар халкының классик язучысы А.Гыйләҗев.

Әдипнең иң мөһим вазифасы — «Халыкның җанын табарга булышу» [2]. А.Гыйләҗев әдәбиятның төрле жанрларында биргән әсәрләре аша татар милләтенең мәдәни мирасын терелтеп, зыян күргән мәдәни-рухи мирасны саклап калырга, «тар сандыкка бикләнгән» татар рухын, аның хәтерен җанландырырга тырыша.

А.Гыйләҗевнең 1979 елда язылган «Җомга көн, кич белән...» әсәре Фатих Кутлу тарафыннан «Өч аршын җир» повестеннан соң төрек теленә тәрҗемә ителгән икенче әсәре булып тора. «Җомга көн, кич белән...» язылып, утыз дүрт ел вакыт узгач, тәрҗемә ителсә дә, эстетик байлыгы һәм техник өстенлеге белән беррәттән, төрек укучысын әдәби зәвыгы һәм мәдәни байлыгы белән җәлеп итә. Кырым татарлары өчен Җәнгиз Дагҗы кем булса, Казан татарлары өчен Аяз Гыйләҗев шулдыр. Төрекләр, хөрмәтле әдип Җәнгиз Дагҗыны белгән кадәр, татарның Стендале [3] буларак бәяләнгән А.Гыйләҗевне дә танып белергә һәм аңларга тиеш.

«Җомга көн, кич белән...» — Көнбатыш әдәбиятында бик еш кулланыла торган «bildungsroman» тибында иҗат ителгән әсәр. «bildungsroman» (немец теленнән) сүзе «барлыкка килү», «тәрбияви роман» мәгънәсенә туры килә. Ул немец әдәбиятында яратып кулланыла, геройның әхлакый, фикри үсешен тасвирлый торган роман тибы [4]. «Bildungsroman»да кешенең эзлекле рәвештә зыялылана баруы, матди-мәгънәви яктан үсеше күз уңында тотыла. А.Гыйләҗев повесть башында ук үзен «Бибинур булып сезгә дәшкән татар баласы!» дип таныта һәм повестьның төп каһарманы Бибинур белән тиңләштерә. Тууыннан үлеменә хәтле үткәнгә кайтулар аша тәрҗемәи хәле турында сүз алып барылган Бибинурның тора-бара ялгыз калуы һәм Җиһангирга карата ярату хисенең үсүе



тасвирлана. Бибинур әсәрнең онытылмас каһарманы гына түгел, ул әдипнең үзе һәм татар милләтенең бер символы булып тора. Әсәрдә Бибинур аркылы шәхси үсеш, милли-рухи кыйммәтләр өлкәсендәге казанышлар һәм милли рухның терелүе гәүдәләндерелә. Шул ук вакытта «үсеш романы» буларак кабул ителгән «bildungsroman»нарда камилләшкән каһарман тәрбияләүче персонаж буларак та кулланыла ала. «Җомга көн, кич белән...» әсәрендә «яшәү мәгънәсен милләткә хезмәттә күргән» А.Гыйләҗев, Бибинурны камилләштергәндә, татарларны да милли-дини кыйммәтләр ягыннан үстерергә, шул нисбәттә мәгърифәтле итәргә тели.

Повестьта вакыйгалар Бибинур образына бәйле рәвештә ике сюжет сызыгына корылган. Беренчесе Җиһангирның вафатыннан алып Бибинурның үлеменә кадәрге бер атна вакытны үз эченә ала. Тугыз бүлектән торган повестьның биш бүлеге — хәзерге заманда, ә дүртесе — үткән заманда. Әсәрнең икенче сюжет сызыгы Бибинурның тууы, яшь кыз вакыты, кияүгә чыгуы, тол калуы һәм балаларының аны ташлавы, япа-ялгыз калуыннан гыйбарәт булып, вакыйгалар үткән заманда бара. Повесть ахырында бу сюжетлар тоташа.

Беренче вакыйга чылбырында татар җирләренең колхозлаштырылу күренеше читләтеп һәм символик ча-

ралар аркылы (эзоп теле) тасвирлана, тәнкыйть ителә. Бибинурның хәзерге заманнан үткәнгә кайтуы, эчке дөньясында барган бәхәсләр үзен камилләштерүгә китерә. «…Барысын уйлап, хәтернең тишек-тошыкларын ямап ятам шунда», — диюче Бибинур гомер буе колхозда ирләр эшен башкара. Ул гына түгел, Аксыргак халкының барысы да «…бар булганын, тир түгеп булдырган мал-туарларын бер сүзсез колхозга илтеп» тапшырган. Бибинур әлеге фидакарьлекнең мәгънәсез һәм рәхмәтсез бер гамәл икәнлеген бары тик хәзерге заманда — ятимлеккә, ялгызлыкка дучар булгач кына аңлый. Беренче һәм икенче сюжет сызыгының иң мөһим уртак ноктасы ул — колхоз. Икенче вакыйга бөҗрасында Бибинур һәм авыл кешесенең үз эченә бикләнүенең, милли-мәгънәви кыйммәтләр бетүнең төп сәбәбе колхозлашуга барып тоташа. Чөнки ул еллар «Колхозлар калкып чыккан», «Замана да, кешеләр дә, мөнәсәбәтләр дә тамырдан үзгәрә башлаган чак» була. Авылны, аның бәрабәренә барлык илне тамырыннан тетрәткән тагын бер вакыйга — Икенче Бөтендөнья сугышы. 1941 елда «Аксыргак авылы белән Ташлыяр елгасы бер көн эчендә ятим кала». Әшәке ниятле колхоз җитәкчеләре-вәкилләр ялгыз калган авыл хатыннарының намусын пычратып йөри. Аларның ирләре фронтта. Шул елларда татарлар үз милли-рухи кыйммәтләрен, борынгыдан килгән гаилә йолаларын әкренләп җуя башлый һәм бер-берсеннән читләшә.

Беренче вакыйга бөҗрасы татар халкында килеп чыккан мәсьәләләрнең сәбәбен, асылын күрсәтүгә хезмәт итсә, икенче вакыйга бөҗрасында колхозның бүлгәләнгән «яңа» татар халкына килеп җиткән фаҗигале соңы тасвирлана. Әдип милли-рухи кыйммәтләр алдында иң зур куркыныч дип авылдан шәһәргә күченүләрне, ялгызлыкны, капитализм һәм модернизм тәкъдим иткән материалистик яшәү рәвешен күрсәтә. Бибинур яшьлеген багышлаган колхоз, биредә җаны-тәне белән хезмәт итүе, гомумән, коммунистик идеология, капитализм кебек үк, әлеге ялгызлыкның сәбәпчесе булып тора. Заманында халык колхозга бар нәрсәсен тапшырган. Бүген исә күмәк хуҗалыклар үз хезмәт ветераннарын бөтенләй онытkan, бик түбән пенсия аларны мохтаҗлыкта калдырган. Мохтаҗлыкка өстәлгән ятимлек — татар гаиләсенең гореф-гадәтләре җимерелүгә китергән сәбәпләрнең берсе. Ялгызлыкка дучар ителгән Бибинур рухы белән хакыйкатьне аңлаган мизгел — Җиһангир вафат булган мизгел. Әлеге аңлау Җиһангирдан калган буа суының көчәйгән тавышы ярдәмендә повестьның ахырына тагын да үстерелә. «Борынгыны бик олылый» торган Җиһангир Бибинур күңелен исән чакта түгел, ә вафат булганнан соң нурландыра. Икесенең дә «борынгы»га һәм шул рәвешле «тамырлар»га чын күңелдән тартылуы берләштерә аларны. Бибинур Аксыргакта салам түбәле йортта яшәүче бердәнбер кеше булса да, өен яңартуга каршы. Чөнки бу йорт — иреннән калган алыштыргысыз истәлек. Әйберне матди яктан бәяләмичә, аның күзгә күренми торган рухи ягын ачкан колхоз рәисе Җиһангир Бибинурны аңлый алган бердәнбер зат була. Җиһангирның үлеме Бибинурны үткәне белән хисаплашуга этәрә. Аның үткәнендә җуела башлаган иҗтимагый төзелешнең эзләре чагыла һәм алар югалган кыйммәтләрнең дә чыганагы булып тора. Бибинур картайган саен нидер югалта: гаиләсен, ирен, атын, казларын һәм, ахыр чиктә, балаларын. Героиняның фаҗигасе бар гомерен багышлаган балаларыннан сигез ел буе көн дә хат көтүе аша тирәнәя. Әдип балалары ташлаган Бибинурның ялгызлыгын: «Балалар түгел, заман үзгәрде», — дип аңлата. Бу аның яңа тормыш алып килгән «кыйммәтләр»гә кискен мөнәсәбәте. Ялгызлык, ятимлек — Бибинурның гына түгел, барлык авыл халкының язмышы. Авылдан

шәһәргә күченүләр, авылда калган карткорыларның иң бәхетлеләре дә бары Сабан туенда гына искә алына... Югалган рухи кыйммәтләр нәтиҗәсендә, авыл кешесе эчке дөньясында да ялгыз. Авылда калган яшьләр дә картлар белән яшәргә теләми. Мәсәлән, Галикәйнең килене «авылда яшәп тә, аның гадәтләрен санламаучылардан». Повестьның ахырына таба ялгызлык, ятимлек үлем көткән Бибинурның иң якыннары булган ут күршесе Зәкия карчык һәм сеңлесенең — рух козгыннары кебек аның өен кулга төшерү хыялы белән яшәүләрендә дә ачык күренә: «Бибинурның өен ватып утын итәрбез. Урынына кызыл кирпечтән, яңача итеп, верандалар киртләп өй салырбыз да олы урамны башка чыгарырбыз! Чаллыга китәм, дип котырып йөри, җибәрмәбез, Алла боерса!..»

Авыл һәм аның кешеләренең рухын җуюы — модернизм уяткан афәт ул. Сарыф итүгә корылган матди тормышның нәтиҗәсе шуңа барып тоташа. Бибинур укучы күз алдына әлеге тормышта рухын җуймаган бердәнбер кеше булып килеп баса. «Хәзер кемгә барып кермә, кукраеп ап-ак холодильник утыра. Стеналарда гына түгел, идәннәрдә дә кыйммәтле келәмнәр. Ялтыр-елтыр шкафлар. Кемгә Берлиннан кайткан, кемгә Бухаресттан. Казан чыгарганын алып ваксынмый хәзер авыл халкы! Ялтыр-елтыр шкафларда алтын-көмеш путалы чынаяклар, бәллүр чәркәләр. Көмеш кашыклар, көмеш чәнечкеләр. Итне дә кул белән ашау бетте, көмеш чәнечке очына гына эләктерәләр». Балаларының Бибинурны ташлавының сәбәбе — хәзерге тормыш тәкъдим иткән яшәү рәвешенә мөкиббән булу. Өстәвенә фатирлар, дачалар, машиналар Бибинурның «кыз чагыннан килгән ашъяулыкларны, тастымалларны, кашагаларны, түрләмәләрне, чиккән сөлгеләрен, аякчуларны, паласларны, энҗеле калфагына тиклем шунда илтеп саткан» акчасына алына. Бу яктан Аксыргак авылы татарларның ватаны ролендә. Авыл ул — татарның шәхси таныклыгы. Анда югалган барлык нәрсә татарның милли-рухи кыйммәтләреннән читләшүе турында сөйли. Моның нәтиҗәсе буларак, әлеге югалтулар Бибинур балаларының берәм-берәм юкка чыгуына, үз ватаныннан читләшкән кешеләргә әверелүенә китерә.

Модерн тормыш бәрабәренә татарлар үз кыйммәтләрен, мәдәниятен, ягъни чын йөзен, төп асылын югалта. Җиһангир авылда ялгыз калу фаҗигасен бик иртә абайлый. «Авылларның үз төсен сакларга кирәк! Менә нәрсә борчый мине!..» — ди ул. Авылда иң беренче эш итеп зиратны төзекләндерергә керешә. Әдипнең моны ассызыклавы очраклы түгел. Зиратлар — изге хәтернең символы һәм алар вафат булганнарны искә алу, бу дөньядагыларны уйланырга этәрү урыны. Бибинур, Җиһангир үлгәч, үзенең асылы хакында уйлана, ягъни кемлеген ача. Төп герой күңелендә барган әлеге төшенү һәм хәтерләүләр татар халкының кемлеген ачу, милли үзенчәлеген табу мәгънәсенә ия. Бибинур, Җиһангирны җирләү вакытында, Ислам динен, Аллаһны исенә төшерә: «Дини ягына килгәндә дә, белгәне сай, бар очракка да шул бер үк «Әлхәм» сүрәсе белән «Көлһуалла» ярап торды, сөенгәндә дә, көенгәндә дә, алар таяныч булды, шулар коткарды. Тик бүген аның теле әллә нишләде, күңеленә моңарчы беленмәгән гаҗәеп кадерле сүзләр иңде: «Тар каберләрең киң булсын, — дип теләк теләде карчык, — исемең кешеләрнең якты күңелләреннән мәңге онытылмасын. Кыямәт газапларын татыма, бар гөнаһларың кичерелсен, оҗмахлы бул!..» Иман биеклеге дәрәҗәсендә башланган әлеге үзаң үсеше татарларның барлык рухи кыйммәтләрен хәтерләп бару белән дәвам иттерелә. Повесть ахырында, үзен ташлап киткән балалары кыен хәлдә калмасын өчен, журналисттан качучы Бибинурның фаҗигале үлемен традицион мөнәсәбәтләрне саклар өчен

көрәшүе дип аңларга кирәк. Икенче яктан, бу җирлекнең дә үзгәрүенә каршы торучы бердәнбер кешенең үлеме авылның сафлыгын-пакьлеген бөтенләй җуюы мәгънәсен ачып бирә. Бибинур үлемен Сабан туеннан бер көн алда, җомга көн, кич беләнгә туры килүе аеруча игътибарга лаек. Сабан туе — татарларның милли, ә җомга көн — дини бәйрәмнәре. Авылга бәйрәм итәргә җыелган татарлар арасында ялгыз калган Бибинурның үлү вакытын әлеге милли-дини көнгә туры килүе повестьтагы символик хикәяләүнең дәвамы булып тора.

А.Гыйләҗев: «Ничә кат укыганмындыр инде! Йөзме, әллә йөздән дә ашып киттеме?» [5] дип әйткән... Габриэль Маркесның «Йөз ел ялгызлык» романы белән «Җомга көн, кич белән...» повесте арасындагы эстетик охшашлык игътибарга лаек. Ике әсәрдә дә телгә алынган авыл халкы ялгызлыкта яшәргә дучар ителгән. Сихри чынбарлыкның бар элементлары чагылган «Йөз ел ялгызлык» романына караганда, «Җомга көн, кич белән...» повесте тагын да классик югарылыктагы бер хикәяләүгә ия. Габриэль Маркесның «Йөз ел ялгызлык» романында «картлыкның котылгысыз ялгызлыгы» дип характерланган Урсула исемле карчыкның ялгыз үлеме белән «Җомга көн, кич белән...»дә ялгызы үлгән Бибинур арасындагы охшашлык игътибарга лаек. «Җомга көн, кич белән...»дә чынбарлык (состав элемент) һәм фантастик элементлар вакыт-вакыт бергә үрелә. Повестьның бигрәк тә баштагы бүлекләрендә Бибинурның җеннәрдән шүрләве, балаларының Каф тавы артында булуына ышануы — «Йөз ел ялгызлык» романына ассоциация ясаган фантастик компонентлар.

Күтәргән мәсьәләләр белән бергә эстетик яктан да көчле булган «Җомга көн, кич белән...» повестенда кулланылган лейтмотивлар музыкаль аһәңгә хас. Әсәрнең башында Җиһангир Ташлыяр елгасы тарайган урында буа бусдыра, аның нәкъ каршысына Ватан сугышында шәһит булган авыл кешеләре өчен һәйкәл һәм янәшәдә генә элемтә бүлеге салдыра. Бибинур, еш кына авыл кешеләренең җыелу урынына әверелгән җиргә барып, суга багып хыялланырга ярата торган була, тик су тавышын беренче тапкыр Җиһангир үлгән көнне генә ишетә. Буа аның өчен «күңелне моң белән тутырып, йөрәкне җирсетеп, үзе белән әллә кайларга чакырып шаулый» торган, «сагыныр өчен гаҗәеп бер урын»га әверелә. Повестьта буа тавышы Бибинурны үткәннәргә чакыра, дәшә.

«Ут белән суга уй тоташа...» дип, А.Гыйләҗев шырпы капларын лейтмотив итеп сайлый. Мохтаҗлыкта көн күргән Бибинур кибеттән очсызлы шырпы сатып ала. Ялгызы булган вакытларда шырпыларга сыена. Җиһангир җирләнгән төнне зиратта курыкмас өчен шырпы кабыза. Повесть ахырында этләр белән көрәшкәндә дә, алардан сакланыр өчен, кулында бердәнбер корал — шырпылар була. Әсәрдәге вакыйгалар Бибинур шырпы белән кабызган ике учак арасында уза.

Дөнья әдәбиятында үлем шәүләсе буларак кара төс кулланылуга карамастан, повестьта үлемнең символы булып ак төс кулланылган. Әлеге хәлне әдипнең, татар милли-рухи йолаларына бәйле рәвештә, үлемгә мөнәсәбәтне башкача белдерүе дип аңларга була. Повестьның башында Җиһангир әсәр геройларыннан, беренче буларак, «аксыл-тонык шәүлә»се белән укучы күз алдына килеп баса. Бибинур Җиһангир үлгән төнне һәм җирләнгән көнне төш күрә. Үлем хәбәре ирешәсе көннең төнендә аның күргән төшен автор түбәндәгечә сурәтли: «Ак казлар өере каңгылдашып ак күпер аша чыкты... Кайдадыр ак әләмнәр җилфердәде... Болын өстен ап-ак энҗе чәчәкләр каплаган иде...» Бибинурның зираттагы төшенә «ямь-яшел болында иртәнге томанда чабышып йөргән ак атлар» керә. Бибинур, Җиһангир үләр алдын-

нан, аның «ап-актан, киҗе-мамыктан тукылган» күлмәкләрен юа. Кабат киелмиячәк ак киемнәр үлем якынлашуны укучыга сиздерә.

Җиһангир белән Бибинурның тәүге очрашуы вакытында Бибинурның кулында бер таяк була. Җиһангирны күргәч, таягы кулыннан төшеп китә, аны җирдән алырга оныта. Җиһангир белән танышканчы, ялгыз карчыкның кулында еш кына бердәнбер таянычы булган таяк символын күрәбез. Повесть ахырында этләр белән сугышканда, исән калыр өчен тырышкан мизгелдә дә аның иң зур таянычы тагын таяк була. Таяк белән судан, ләмнән чыгарга тырыша һәм «кулындагы нәзик таякны», этләргә ыргытканнан соң, күп тә үтми көрәше төгәлләнә.

Повестьның бөтенлеген булдырган һәм аһәңлелеген көчәйткән тагын бер ысул ул — хайваннарга бәйле метафоралар. Элек ат һәм казлар, табигать белән укмашып яшәгән Бибинурның хәзерге заманда алардан читләшүе, табигатьнең бозылуы җәмгыятьтәге пычраклыкларның икенче бер күренеше булып тәкъдим ителә. Мәсәлән, Бибинурга иренең фронтта һәлак булу хәбәре кызыл айгырдан аерылу хәсрәте «кара кан тулган йөрәккә ук булып кадалган» мизгелдә ирешә. «Табигать белән уртаклыгының тукталуы» казларын, атын, этен югалтуы белән бер яссылыкта бара. Әдип, авыл халкының үзенчәлекле сыйфатларын күрсәтү максатында, башка хайван-җәнлекләргә дә мөрәҗәгать итә. Бибинур — күбәләккә, кибетче Әсмабикә — песигә, Галикәй — каракошка, Зөһрәбану еланга тиңләнә. Повесть башында «соңгы ризыкларын бүлешкән аның эте Карабай» юкка чыга, бары ахырда гына пәйда була. Бибинур аңа ташланган эт өеренең башында Карабае булуын күрә. «Карабай, Карабай, нишлисең? Күрче, мин ич бу, Бибинур нәнәң!» — дигән инәлүенә карамастан, эт рәхимсез кылана. Эт — рухи кыйммәтләрен җуйган татар халкын һәм Бибинурның балаларын символлаштырган метафора. Чыннан да: «Кеше янында сабак алып, иясез калып кыргыйланган этләр! Алар кешене дә бер дә яратмыйлар. Тырышып-тырышып бүреләрне кырып бетердек, котылдык мәңгегә явыздан, дип шапырынабыз, ә табигатькә бүре бик тә кирәк икән! Көч икән ул кеше дусты!» — диюче автор инде нык үзгәргән татар халкына ишарә ясый. Бибинурның мәрхәмәтлелегеннән, матди мөмкинлекләреннән тулысынча файдаланган каты бәгырьле, рәхимсез балалары белән этләр арасындагы мөнәсәбәт зур игътибарга лаек.

А.Гыйләҗев «Җомга көн, кич белән...»дә, тезиска бирешмичә, повестьта эстетик мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланып, «изге бурычы» санаган «халыкның җанын табарга булышуны!» уңышлы башкара. Автор бу яктан эстетик байлыгы белән дә, күтәргән мәсьәләләре буенча да универсальлеккә ирешкән. Төрек модернизацияләшүендә дә вакыт-вакыт моңа охшаш мәсьәләләрнең очравын күз алдында тотсак, А.Гыйләҗевнең әлеге повесте төрек укучысы өчен бары тик тугандаш бер халыкның дөньясын чагылдырган көзге генә түгел, ә үзебезнең рухны табарлык әсәр буларак алдыбызга килеп баса.

Әдәбият

1. Мүфидә Фәрит Тәк. Айдәмир. – Истанбул: Кәкәнүс. – Б.15.
2. Язучының шәхси архивы: Вахит Юнысовка 1983 елның 3 маенда язган хаты. – Б.3.
3. Yenisafak.com.tr/kitap/?i=109525 – Идел. – №4. – Б.64.
4. Büyük Larousse sözlük ve ansiklopedisi. – 24 cilt: C.4. – İstanbul: Milliyet Yayın, 1986. – S.1631.
5. Язучының шәхси архивы: Көндәлекләр. – 15.11.1994.

Төрекчәдән
***Фатих Кутлу** тәрҗемәсе*

ФИНЛЯНДИЯДӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ҮСЕШЕ

КАДРИЯ БӘДРЕТДИН,
Хельсинки университеты гуманитар фәннәр факультетының дөнья мәдәнияте, Азия һәм Африка тикшеренүләр кафедрасы докторанты

ХӘЗЕРГЕ ВАКЫТТА МИН ФИНЛЯНДИЯ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ӘДӘБИЯТЫН ӨЙРӘНӘМ ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЯЗМА МӘДӘНИЯТЕ ТУРЫНДА КАНДИДАТЛЫК ДИССЕРТАЦИЯСЕН ЯЗАМ. МАГИСТРЛЫК ЭШЕМ ХӘСӘН ХӘМИДУЛЛА ҺӘМ САДРИ ХӘМИД ИҖАТЫНА БАГЫШЛАНГАН ИДЕ. ФӘННИ ЭЗЛӘНҮ ЧЫГАНАКЛАРЫ БУЛЫП ФИН ӘДӘБИЯТЫНДА ӘҺӘМИЯТЛЕ УРЫН БИЛӘГӘН Х.ХӘМИДУЛЛА ҺӘМ С.ХӘМИД ИҖАТЛАРЫ ТОРА.

Татарлар арасында гарәп графикасы белән язылган текстларны укый белүчеләр бүген инде аз, шуңа күрә әлеге әдипләрнең иҗаты турында мәгълүмат алу шактый кыен. Х.Хәмидулла һәм С.Хәмид язган әсәрләрне укудагы кыенлык алар яшәгән чорда татар теле өчен орфографик нормалар әле эшләнмәгән булуга бәйле.

1. Туган тел китабы

2011 елның көзендә Хельсинки шәһәрендә Финляндиянең милли китапханәсе җирле татар әдәбиятына багышланган күргәзмә оештырды. Күргәзмә Кадрия Бәдретдин тарафыннан язылган «Туган тел – Финляндия татарлары язмалары» дип аталган китапның басылып чыгуы белән туры килде. Ошбу җыентык Финляндия татарларының тарихы, мәдәнияте һәм көнкүреше турындагы мәкаләләрне берләштерә.

Финляндия татарлары йөз елга якын әлеге җирлектә татар телендә газета-журналлар, китаплар бастырган. Арада Хәсән Хәмидулла (1900-1988) һәм Садри Хәмид (1905-1987) – иң күренеклеләрдән. Алар Финляндиядә үз халкының телен һәм мәдәниятен саклап калу өчен, бар көчләрен куеп тырышкан. Х.Хәмидулла һәм С.Хәмид – күренекле тарихчы, шагыйрь, мөхәррир һәм татар җәмгыяте тәрбиячеләре. Финляндиядә гарәп һәм латин графикасында бастырылган татар әдәбиятының күп өлеше әлеге ике автор тарафыннан иҗат ителгән. Әдипләр күп кенә китапларын бушлай тараткан. Х.Хәмидулла һәм С.Хәмидтән кала башка татар язучылары да милләткә күп файда китергәннәр.

Татар өйләре, гаиләләр һәм дини бәйрәмнәр – татар телен, мәдәниятен яшәтә торган төп көч. Татарларның халык авыз иҗаты, массакүләм мәгълүмат чаралары, мәгариф системасы булмаса, фин мәдәнияте һәм теле доминанта булган җәмгыятьтә милли үзенчәлекләрне саклап калу бик кыен булыр иде. Шул уңайдан фәнни эзләнүем зур кызыксыну тудырган мәсьәләне алга куя: татарлар, фин җәмгыятендә яшәү татарлык сыйфатларын саклауда каршылык

Хәсән Хәмидулла



Финляндия татарлары турында «Туган тел» китабының (авторы – К.Бәдретдин) тышлыгы

тудырмый, дип саный. Киресенчә, бу ике омтылыш бер-берсенә терәк булып тора. Финляндия татарларының аерым бер халык буларак җирле җәмгыятькә уңышлы гына катнашып китүе — үрнәк күренеш.

ФИНЛЯНДИЯ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ӘДӘБИЯТЫ

XIX гасыр азагы — XX йөз башында Идел буе татарлары Россия төркиләре арасында иң күп китап бастыручы халык булып саналган. Хәзерге заман әдәбияты ике этаптан тора: беренчесе — 1860-1905 еллар, икенчесе — 1905-1917 еллар, аннан соң совет чоры башлана. «Turcica» (тюркология буенча җыентык) — көнбатыш стандартлары буенча уникаль җыентыкның бездә булуы зур бәхет. Хельсинки университеты хисабына ошбу җыентык өчен Россиядә бастырылган һәрбер язманың күчермәсе Финляндия милли китапханәсенә алдырыла торган булган. Җыентык 1828-1919 елларда Россиядә берничә төрки телдә бастырылган кайбер китапларны да үз эченә ала. Мәгълүматлар Гарри Халенның «Финляндиядәге көнчыгыш җыентыклары» китабында җентекләп яктыртылган: кулъязмалар, ксилографияләр, язытлар (язма) һәм рус әдәбияты үрнәкләре.

Боларның барысы да Идел буе татарларының Финляндиядә бастырып чыгарган әдәбиятына бәя бирүдә безгә ярдәм итә. Әлеге хезмәтләр — аерым татар әдәбияты бүлекчәсе буларак, иске традицияләрнең дәвамы.

Сан ягыннан күп булмасалар да, Финляндия татарлары үзләреннән соң гаҗәеп бай әдәби мирас калдырган. Дини тәрбия, музыка, мәдәният өлкәсенең башка тармаклары, тел өйрәнү кебек төрле темаларны үз эченә алган басмалар әнә шундыйлардан. Алар арасына җыеннарында, ачык лекцияләрдә, җәйге курсларда, тел өйрәнгәндә кулланылган аерым китап һәм брошюралар һәм газета-журналлар кергән. 1930-1950 еллар иң күп басмалар чыгу чоры булып санала, бүген дә бу эш дәвам итә. Соңгы елларда Финляндиядә басылган татар әдәбияты 200дән артык исемлекне тәшкил итә.

2. Казан басмасы / Хәсән Хәмидулланың Коръән турында басмасы. Гарәпчә Коръән Казанда 1897 елда басылган.

Финляндия татарлары XIX гасырда Казанда бастырылган Коръән, аның шәрехләре, хәдис китаплары, дини һәм дөньяви дәреслекләр, шигырь җыентыкларын кулланган. Укучылар өчен Финляндиядә факсимиль басмалар булдырганнар һәм бу китаплар, соңрак җирле үзенчәлекләргә яраклаштырылып, яңа әдәбият өчен үрнәк буларак кулланылган. Финляндия татарлары җәмгыяте әле дә булса Казанда бастырылган дини китапларны куллана.

Басмалар арасында Свеаборг, Хельсинки һәм Выборг имамнарының рус гаскәрендә хезмәт иткән мөселман иратлар һәм аларның гаилә әгъзалары турында татар телендә теркәлгән мәгълүматлары аеруча кызыклы.

ОРФОГРАФИК ТРАДИЦИЯЛӘРНЕҢ КИЛЕШҮЕ

1917 елдан соң Финляндия татарлары белән Идел буе татарлары арасындагы багланышлар өзелә, сөйләм теле дә шактый аерыла башлый. Фәкать 1960 еллар азагында Татарстанда кулланылган Казан татар әдәби теле белән күпмедер якынаю күзәтелә. Нәтиҗәдә, норматив Казан татар орфографиясе, кириллицада булуга карамастан, Финляндия татарларының орфографиясенә йогынты ясый башлый.

3. 1935 елда бастырылган «Уку китабы» (Туган тел)

1920 һәм 1930 елларның башында дөнья күргән бөтен материаллар гарәп хәрефләре белән язылган. Текстлар Хельсинкидагы «Сана» (сүз) типографиясендәге кебек, татарларның ярдәме белән җыелган. 1935 елда «Уку китабы» дәреслегендә татар халык шагыйре Габдулла Тукайның «Туган тел» шигыре үрнәк текст булып тора. Әлеге «Уку китабы» да башка кулланмалар кебек үк Фин конгрегациясенең Дәреслекләр төзү хәяте тарафыннан әзерләнгән.

1930 еллардан алып төрек теле реформасы йогынтысы һәм Советлар союзының төрки төбәкләрендәге латинга күчү (яңалиф) хәрәкәте белән берлектә, Финляндия татарлары арасында латин хәрефләрен куллану киң таралыш алган. Шуңа бәйле рәвештә, бер үк басмада һәм гарәп, һәм латин графикасында язмалар күрергә мөмкин. Төрле буын укучылары өчен текстны аңлау мәсьәләсе шулай җайга салынган.

4. Латин орфографиясе

Иң башта Финляндия татарларының латин алфавиты төрек теленең латин алфавитына нигезләнгән. Төрек алфавитының «ğ» (йомшак «г») хәрефе кайбер очракта гына кулланылган, ә швед-фин алфавитының «q», «w», «x», «å», «ä» хәрефләре төрки булмаган сүзләрне һәм исемнәрне язу өчен кулланылган. Гомумән алганда, төрек теленең абруе бик зур һәм кайбер сүзләрнең орфографиясендә татар теленә хас булмаган төрек язуы кагыйдәләре файдаланылган. Бу хәл орфографиядәге эзлексезлеккә һәм төрле хилафлыкларга китергән.

ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ИҖАТЫ ТУРЫНДА КҮЗАЛЛАУ

Хәсән Хәмидулла белән Садри Хәмиднең Финляндиядә уңышлы иҗат иткән язучылар булуы турында әйткән идек инде. Аларның һәм татар телендә иҗат итүче башка язучыларның үзенчәлекләренә тукталыйк.

5. Хәсән Хәмидулла

Хәсән Хәмидулла үзенең туган авылы Актук авылында указлы мулла Гарифулла мәктәбенә йөргән. 1915 елда Х.Хәмидулла Россиядән Финляндиягә күчеп килә һәм 1923 елда Оулу һәм Кемидә урнашып сәүдәгәрлек итә башлый. 1926-1927 елларда Төркиядә яши, 1950 елда гаиләсе белән Хельсинкига күчә һәм мәркәздә үзләренең электротоварлар сата торган «Tehowatt» кибетендә эшли.

Х.Хәмидулла шәхси басмаханәсендә күп кенә китап һәм брошюралар чыга-

ра, соңрак «Хәсән Низаметдин Хәмидулла әсәрләре» (5 томда. Хельсинки, 1975 ел) исеме үз китапларын бастыра. Монда аерым басмалар берләштерелгән. Х.Хәмидулла туган төбәге Сергачта кулланылган мишәр диалектын, төрекчә һәм гарәпчә терминнарны катнаштырып язган.

«Актук (Яңапар) авылы тарихы: 1667-1919 еллар» (1954) хезмәтендә Х.Хәмидулла Актук (Яңапар) авылының үткәнен камил сурәтләү өчен җирле сөйләм һәм рәсемнәрне мул куллана. Автор әлеге авылда яшәүче күпчелек гаиләләрнең Финляндиягә күченү сәбәпләрен аңлата. Авыл Түбән Новгород өлкәсенең Сергач районында, Мәскәүдән 500 чакрым көнчыгышта урнашкан. Җыентыкта халык авыз иҗаты традицияләре сакланып калган. Бу — киләчәк буын өчен бай мирас.

Х.Хәмидулланың бай иҗаты автобиографиядән, җиде бүлектән торган «Финляндия мөселманнары тарихы материаллары»ннан (1962-1977), «Мәккәгә Хаҗ кылу хатирәләре»ннән (1968-1971) һәм Финляндия Ислам җәмгыятенең имамы буларак (1973) язган ун җомга хөтбәсеннән гыйбарәт.

6. «Мәгърифәт» (1925) — Финляндиядә татар телендә чыгарылган иң билгеле һәм иң борынгы журнал

Х.Хәмидулла — Финляндия татарларының беренче журналы мөхәррире дә. «Мәгърифәт» атна саен җомга көнне чыга торган сәяси, милли һәм әдәби басма исәпләнгән. Көн кадагына тугры журнал бераздан сәяси һәм мәдәни булып калган. Ул 100 данә тираж белән чыккан. Атналык журналның берничә абоненты булган, татар теле фин цензурасы астында булганлыктан, журнал хөкүмәт тарафыннан ябылган. Х.Хәмидулланың аннан соң чыгарган «Симал очкыннары» исемле журналы Финляндия Ислам җәмгыятенең милли мәгърифәт һәм дини гыйлем мәйданы ролен үтәгән. Ул 1945-1977 еллар арасында чыккан, ләкин нибары 8 номеры дөнья күргән.

1943 елда Х.Хәмидулла хатыны

Садри Хәмид

Гөлсем белән бергә Кемидә факсимиль Коръән бастырып чыгара. Бу 1897 елда басылган Коръәннең фотомеханик редакциясе 20 мең данә тираж белән дөнья күрә. Басма бабасының Финляндиягә килүенең 75 еллыгына багышлана һәм Финляндия белән Германиядә әсир төшкән мөселманнарга бушлай таратыла. Х.Хәмидулла 1969 елда бастырган икенче Коръән дә шулай ук факсимиль һәм ошбу матур басма бабасының Финляндиягә күченеп килүенең 100 еллыгына багышланган.

Х.ХӘМИДУЛЛАНЫҢ ШИГЫРЬ ҺӘМ ХИКӘЯЛӘРЕ ТУРЫНДА

Татарлар арасында көннәргә, финнарга хас булганча, исем бирү традициясен кертергә теләп, Хәсән Хәмидулла мөселманнар өчен «Исем көннәре календаре»н төзи (Кеми. 1948), ләкин бастырып чыгара алмый. Шулай да татар һәм фин шрифты белән язылган әлеге календарь Финляндия татарларының балаларына исем куюда бик файдалы булды.

1971-1980 еллар берничә тапкыр нәшер ителгән «Финляндия мөселманнарының телефон каталогы» шулай ук бик кирәкле булды.

7. Садри Хәмид

Хәсән Хәмидулланың туганнан-туган абыйсы Садри Хәмид тә иҗади

кеше була. Ул да — абыйсы кебек шагыйрь, Актук авылында туган. С.Хәмид тәрҗемәсе бик катлаулы булган рифмалы шигърият өлкәсендә белгеч исәпләнгән. Аның күп кенә брошюралары актуаль вакыйгаларга багышланган. С.Хәмид үз карьерасын 1946 елда «Дәфтәр» дип исемләнгән шигырь җыентыгы сериясен чыгарудан башлый. Аның башка шигъри әсәрләре татар теленә мәдхия, Закир исемле бер фәкыйрь кеше шигыре (1946), «Фәкыйрьлек» (1950) һәм «Дәҗҗаллар» (Аллаһны сүгүчеләр) дип аталган шигырьләреннән тора (1951). 1951-1979 елларда С.Хәмид Хельсинкида һәм Оулуда актуаль темаларга багышланган 23 шигырь бастырып чыгарган. Шулай ук 1950 елда булган яңалыклар, 1952 елда Хельсинкида узган Олимпия уеннары турында һәм «Утыз ел Финляндиядә» (1954) исемле хатирәләр дә бар.

1929 елда Төркия Европа алфавитын кабул иткәннән соң, Финляндиядә дә «иске» белән «яңа» арасында мәдәни көрәш кыза. Бу көрәштә алфавит мәсьәләләре, татар теле белән төрек теле арасындагы «ярыш»та көн кадагында тора. С.Хәмид, алфавит алмаштыру телнең һәм диннең юкка чыгуына китерәчәк, дип, гарәп алфавитын латин алфавитына алыштыруга каршы чыга. Ислам теологиясе һәм хокукын, гарәп һәм фарсы әдәбиятын яхшы белүче әдип халык арасында бик танылган була. Садри Хәмид бу тартышта 1972-1975 еллар арасында гарәпчә язылган рисаләләр белән терәк булды. Рисаләләр иҗади исемнәре ягыннан да аерылып тора: «Гәүһәр хәрефләр», «Изге хәрефләр», «Энҗе хәрефләр».

Финляндиядә татар телен саклап калуга ярдәм итеп, С.Хәмид тарату өчен ике татарча сүзлек һәм мәкальләр җыентыгын бастыра — «Кушымлы сүзләр» һәм «Туган илдәге сүзләр». Бу басмаларда 1700 халык мәкале тупланган.

1967 елда С.Хәмид ике журнал чыгара башлый. Беренчесе — «Тавыш», беренче елны ук алты номер чыгаргач ябыла, икенчесе исә — «Ак юл» — 1977 елга хәтле чыга. Ике журналда да төрки халыкларның тарихы һәм фольклоры турында рәсемле хикәяләр, аһәңле хроника һәм сүзуйнаткычлар туплап бирелә.

ФИНЛЯНДИЯДӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ХАКЫНДА

8. Ахсен Бөре

Мәсләге буенча сәүдәгәр булган Зиннәтулла Ахсен Бөре (1886-1945) Актук авылында туып, Тамперда яши. Үзенең әдәби эшчәнлеген 1934 елда латин графикасы белән төрек яки фин телендә язылган буклетларны бастырудан башлый.

1931 елда Ахсен Бөре Лорд Хэдлиның бер гасыр элек Көнбатышта ислам дине көчәячәген фаразлап язган китабының фин теленә тәрҗемәсен нәшер итә. 1943 елда: «Без уңышлы җәмгыять кордык, ни өчен шулай ук уңышлы итеп фин-төрек башлангыч мәктәбен оештыра алмыйбыз?» — дип исемләнгән бик кызыклы брошюра бастыра. Аның тырышлыгы белән Тампереда фин телендә беренче «Коръән» басыла. Георг Пименоффка инглиз редакциясеннән фин теленә тәрҗемә итү өчен 6-10 ел кирәк була. Фин хөкүмәтенең рәсми җавабы өчен борчылган җәмгыятьне Ахсен Бөре Коръәннең фин теленә тәрҗемә ителүе фин хөкүмәте белән тулысынча килешенгән, дип тынычландыра, нәтиҗәдә, тәрҗемә мәсьәләсе уңай хәл ителә. Соңыннан Ахсен Бөрегә Маннергейм һәм Рютидән рәхмәт хатлары тапшырыла. 1957 елга кадәр фин профессорлары Коръәнне гарәпчәдән фин теленә тәрҗемә итеп бетермәгән була, өченче басма Йаакко Хамеен-Анттила тәрҗемәсендә өченче буын Финляндия татары Бату Самалетдинның Басам нәшрият йортында бастырылды.

9. Гәүһәр Туганай

Хатын-кыз язучылар арасыннан Самарада дөньяга килгән Гәүһәр Туганайга (1911-1998) аерым тукталырга кирәк. Аның ике шигырь җыентыгы ба-

сыла. Шигырьләре күбрәк багышлаулар рәвешендә яки бәйрәм уңаеннан языла.

Шагыйрә һәм язучы Сания Гыйффәт Кадыйри (1899 ел; Чистай — 1957 ел; Анкара) ире Закир Кадыйри белән татар җәмгыятендә укытучы булып хезмәт иткән, шулай ук профессиональ булмаган театр өчен пьесалар язган. Аның 4 акттан торган «Тормыш көзгесе» исемле пьесасы 1937 елда Финляндиядә басыла.

Наилә Бинарк, мәсәлән, Казан чыганакларын кулланып, 1500 мәкаль тупланган җыентык бастырган.

Фәзилә Насретдин һәм Сайнур Имадетдин балалар өчен «Җыр кесәм ертылды» һәм «Сандугачым, син дә сайра» исемле җыр буклетлары чыгарган.

Башка татар хатын-кыз язучылар тел укытучылары буларак Төркиядән килә. Алар татар теле дәреслекләрен төзи.

Милли аш-суга килгәндә, Дәрья Самалетдин мөхәррирлегендә 1990 елда басылган «Милли ашларыбыз» җыентыгында традицион татар ризыкларының рецептлары китерелгән.

Бу уңайдан хәзергә йөздән кимрәк әгъзаны берләштергән Тампере Ислам җәмгыятенең матур эшләрен ассызыклап үтәсем килә. Тампере Ислам җәмгыятенең тарихы турындагы китап (Tampereen Islamilainen Seurakunta: juuret ja historia) 2004 елда Муаззез Байбулат тарафыннан языла. Хезмәт фин, татар һәм инглиз телләрендә чыкты. 300 биттән торган җыентык җәмгыятьнең оешу тарихын, шулай ук кайбер шәхесләрнең биографияләрен үз эченә алган. Бәйрәмнәр, уеннар, документлар, төрле иҗат коллективлары, мәктәп дәреслекләре, төрле спорт чаралары тасвирланган зур фотосурәтләр җыентыкка ямь өсти.

10. Су Анасы

Хәзерге заманның башка үрнәкләреннән 2010 елда Фәзилә Насретдин һәм Фәридә Нисаметдин тарафыннан бастырылган «Су Анасы» әкиятен һәм татар телендә балалар өчен төрле халыкларның тупланган «Әйлән-бәйлән» CD-язмасын әйтергә була.

ФИНЛЯНДИЯ ТАТАР ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ ХАКЫНДА

Хәсән Хәмидулла һәм Садри Хәмид заманы белән чагыштырганда, татарча китап язу һәм бастыру традициясе юкка чыгып бара, дип әйтергә мөмкин. Татар яшьләре язма туган тел кирәген тоймыйлар һәм мөмкинлекләре дә юк. Күбесе грамматик дөреслек өчен борчыла. Бу шартларда татарлар туган телне саклауның әһәмиятен әдәбиятта түгел, ә телдән аралашуда күрә.

Финляндия татарларына татар телендә язылган хәзерге заман әдәбияты җитми. Әгәр берәү татарча китап яки журнал укырга тели икән, алар бүгенге Татарстаннан алынган булырга тиеш. Финляндиядә иҗат ителгән әдәбият белән дә кайбер кыенлыклар бар, чөнки заман татар яшьләре, кагыйдә буларак, иске гарәп алфавитын белми. Иске китапларны табу да бик катлаулы. Бүген татарча китапларның күбесе кириллицада, димәк, укырга теләгән кеше әүвәл алфавитны үзләштерергә тиеш. Финляндия татарлары арасында үз ана телләрен җитәрлек дәрәҗәдә үзләштерергә мөмкинлек булмау каршылыгы да бар. Күптөрле алфавитлар куллану бу каршылыкны җиңүдә ярдәм итә алмый. Татар әдәбияты зур һәм бай булуга карамастан, аерым шартлар таләп иткән кечкенә этник төркемнәрнең хәле әдәби телебезнең абруе мактанырлык түгеллекне күрсәтә. Аерым ачышлар хакындагы белем һәм мәгълүмат фин, швед яки инглиз телендә язылган китаплардан килә. Татар телендә яңа шигырь һәм роман җыентыклары Финляндиядә күп еллардан бирле бастырылмый инде.

Татарстанда татар тарихы һәм мәдәниятенең Ренессансы якынаюы сизелә. Туган телебезнең аралашу өчен уңайлылыгы, төрле буын милләттәшләребезне берләштерә алырлык көчкә ия булсын иде.

Инглизчәдән ***Булат Ногманов*** *тәрҗемәсе*

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

Сәхифәне филология фәннәре докторы ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

ШӘРИФӘ КАРЧЫК (? — ?). Кушлавыч авылы кешесе, Тукайны вакытлыча асрамага алган фәкыйрә карчык. Тол калган Мәмдүдә, Сасна авылы мулласы Мөхәммәтшакир Фәйзуллинга кияүгә киткәндә, 1888 елның декабрь ахырында (1889 елның гыйнвар башында) Габдулланы Өчиледән Кушлавычка илтеп, бер кибән арыш биреп, Шәрифә исемле карчыкка тапшырып калдырырга мәҗбүр була (ул вакытта Тукайга ике яшь тә сигез ай ярым). Бу карчыкта ничек яшәве турында ул «Исемдә калганнар» автобиографик повестенда: «Мин бу карчык ханәсендә кадерсез, артык бер бала булганлыктан, ул мине, әлбәттә, тәрбияләмәгән; тәрбияләү түгел, яшь балаларның иң мохтаҗ булдыклары ачык йөзне дә күрсәтмәгән», — дип яза. Авылдашларының сөйләүләренә нигезләнеп: «Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк, күлмәкчән көенчә тышка чыгам икән дә бераздан, өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. Кыш көне авыл ызбаларының ишекләрен ачмак, балага түгел, шактый үсмер кешеләргә дә мәшәкать вә көч булганлыктан, табигый, мин ишекне ача алмыйм вә ишек төбендә аякларым бозга ябышып катканча көтеп торам икән. Карчык исә үзенең: «Кадалмас әле, килмешәк!» — диган «шәфкатьле» фикере илә мине үзе теләгән вакытта орыша-орыша кертә икән», — дисә дә, — «ул карчык үлгән инде; Алла аңар рәхмәт итсен», — дип язып калдыра. Шәрифә карчыкның Габдулланы ничек тәрбияләве хакында башка төрле мәгълүматлар сакланмаган. Аның әдәби образы исә Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романында чагылыш тапты. Анда «Шәрифә карчык күптән ире үлгән һәм ир баласыз көе ике кызы белән торып калган бик ярлы бер карчык» итеп сурәтләнә. «Карчыкның да, кызларының да закон буенча җир биләү хокуклары булмау аркасында, мәрхүм иреннән дүрт таяк җир белән калган Шәрифә карчык янына Мөхәммәтгарифның кече абзасы, авыл старостасы белән килеп: «Киләсе елга җир бүлү була бит. Кызлар җиткерәсең, гомер буена дүрт таяк җир белән яши алмассың... Ал син бу ятимне! Үзе мәхзүм, үзе ир бала. Җирле булырсың. Дөньялык өчен ул синә дәүләт китерер, ахирәтең өчен бер догачың булыр», — дип, карчыкны күндереп кайталар».

Р.Батулланың «Апуш-Тукай» кыйссасында (әдәби әсәрендә!) исә Шәрифә карчыкның өе бик фәкыйрь итеп тасвирлана: «Өй тараканнар катып үләрлек суык иде. Мичтә чи усак чыш-пыш килеп, янарянмас пыскый. Түр сәкедә ертык юрганга уранган Габдуллаҗан калтыранып утыра». Мәмдүдә ире Мөхәммәтшакир белән Габдулланы үзләренә алдыру хакында сөйләшеп, күп кенә күчтәнәчләр (сумсалар, ике таяк казы, бер таба гөбәдия) тотып, Габдулланы алырга киләләр һәм баланы карап торган өчен рәхмәт йөзеннән илле тиен көмеш бирәләр. Шәрифә карчык рәхмәтләр әйтеп, күз яшьләре белән озатып кала.

Чыганак
Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. — 5-т. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. — Б.10-11.
Әдәбият
Фәйзи Ә. Тукай. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1952. — Б.16-17; Нуруллин И. Габдулла Тукай. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1979. — Б.14-15; Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. — Б.7; Батулла Р. Шайтан таягы: кыйссалар. — Казан: «Илһам» нәшр., 2011. — Б.20-21.

ШӘМСЕТДИНОВА ФАИЗӘ МӨХӘММӘТГАЛИМ КЫЗЫ (1838-1922). Габдулла Тукайның әтисенең бертуган апасы. 1870 еллар тирәсендә Кушлавыч авылыннан Җәләлетдин Шәмсетдин улы Шәмсетдиновка (1837-1922) кияүгә чыгып, 1870 еллар тирәсендә элеккеге Казан губернасының Казан өязе Кармыш волосте Югары Масра авылына килә. Фаизәнең туганы Ж.Нуриев язуына караганда, бу авыл бик кечкенә һәм ярлы яшәгән. Авыл халкының күбесе кышны уздырырга читкә — башкорт, Пермь якларына чыгып китеп, кайсы итек басып, кайсы тегү тегеп, кайсы кырык тартмачы булып гомер иткән. Ире Җәләлетдин мулла да бик ярлы булып, халыктан килгән садака

белән генә яшәгән. Бу еллардагы ачлык аларның тормышын тагын да авырайткан. Өстәвенә, үзләре дүртәү, тол калган ике сеңлесе икешәр бала белән кайтып, гаиләләре ун кешегә җиткән. Шуңа да ятим калган Тукайны үзләренә ала алмагач, Фаизә Җаекта яшәүче, бай сәүдәгәргә кияүгә чыккан, үзенең бертуган сеңлесе Газизә Госмановага хат яза. Габдулланың ятим калуын, чит кешеләр кулында гомер итүен аңлатып, аны балалыкка алуларын сорый. Галиәсгар белән Газизә Габдулланы Кырлайдан Җаекка алдыргач, Фаизә әби ире Җәләлетдин, уллары Габдрахман белән Җаек шәһәренә кунакка бара. Казаннан килгән кунаклар хөрмәтенә Галиәсгар Госманов зур мәҗлес тә җыя.

Әдәбият
Рәсүлова З. Тукай эзләреннән. — Казан: Татар. кит.нәшр., 1985. — Б.24-26.

Эльмера Галимҗанова,
филология фәннәре кандидаты

СОЛОВЬЁВ ТИМЕРША САЛАВАТУЛЛА УЛЫ (1875-1947). Журналист, нашир, язучы, педагог. 1906 елның 20 июленнән 1910 елның маена кадәр «Чүкеч» исемле сатирик журналның мөхәррире (73 санның 41ендә) һәм нашире булган Т.Соловьёвның үз мәкаләләре анда «Шуширминский» имзасы белән басылган. Тукай Уральскида «Уклар» журналында, «Фикер» газетасында эшләгән чорда «Чүкеч»не дә игътибар белән күзәтә, журналдагы кайбер сатирик яктан үткен материаллар белән төп эшне үзе башкарган «Уклар» журналының укучыларын да таныштыра. Шул ук вакытта Тукай «Чүкеч»не ачы тәнкыйть тә итә («Тимерче», «Телеграмнар»). Аның гел бер үк мәсьәләләр тирәсендә әйләнүенә, материалларның бертөрлелегенә канәгатьсезлек белдерә: «Чүкеч» журналы һаман шул иске-мосКы тимерләрне сугып шакылдый. Эшли-эшли, көне буе эшләгәне 3 тиен көмешлек булмый», «Чүкеч»нең хуҗасы «Сандугач» фамилиясеннән булып, ала карга төсле сайравы «тәкый гаҗәб»рәктер», — дигән сүзләрдә журналның тел-стилендәге тупаслыклар, әдәпсез сүзләр кулланып язуы күздә тотыла. «Чүкеч»нең кайвакыт һөҗүм объектын дөрес сайлый алмавы, дуамаллануы, сатира утын тиешсез җиргә юнәлтүе дә Тукай тарафыннан тәнкыйтьләнә: «Чүкеч» журналының ияләре, бәгъзе вакыт, чүкечләре бик авыр булганлыктан, урынына төшерә алмый, ялгышлык илә икенче җиргә төшереп куялар...» («Телсез телеграф хәбәрләре»). «Дусны дошманнан аермаенча, кем очраса, шуны чүкечләре илә кундыра башламасалар ярар иде...» «Уклар»ның 6 нчы санында: *«И тимерче, тимерче! / Тимереңне кимерче. // Каты тимер тешли-тешли, / Теш казнаңны җимерче. /.../ Соңгы көндә чүкечләргә / Тимер тапмый тилмерче»,* — дип яза.

«Яшен» белән «Ялт-йолт»та эшләгәндә дә, Тукай «Чүкеч»не еш кына чеметеп ала. Ул башлыча аның ямьсез «сүгенүләрен» («Чүкеч» һаман сүгенә»), «тәмсез» сүзләрен («Ит базарында тәрәкъкый») тәнкыйтьли, әдәпсез бер эпиграммасында «Нәҗес вулканы» дип тә атый («Ник? Нигә?»).

Тукай сатирасына «Чүкеч» һәм аның мөхәррире күп тапкырлар юлыга. Үзенә карата юнәлтелгән хаксыз чыгышларга («чүкечләүләргә») мөхәррир Т.Соловьёвны да җаваплы итеп санап, ул аны төрле яклап мыскыллый: Соловьёвны «Тимерче Сандугач», «Сандугачев» дип атый, «псевдонимнарыннан образ ясап, шуның ярдәмендә сатирик эффект тудыра» (Ф.Әгъзамов); «Төшендә дә чүкеч, өнендә дә чүкеч, язганы да чүкеч, сызганы да чүкеч, журналы да «Чүкеч», — бу нинди бетмәгән чүкеч икән! Тимерче Соловьёвның үз башына булган чүкеч булмаса гына ярар иде», — дип көлә. Тимерша Соловьёв үз чиратында Тукай тәнкыйтенә ничек җавап биргәндер — бу ачык түгел. Әлеге эшне З.Бәшири үтәгән булса кирәк.

Әдәбият
Рәсүлева З. Тукай эзләреннән. — Казан: Татар. кит.нәшр., 1985. — Б.58-59; Әхмәтҗанов М. Соловьёв Т. // Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы). — Казан: [Г.Ибраһимов исем. ТӘһСИ], 2005. — Б.178-179; Гыймадиев Ү. Сатира коралы белән. — Казан, 1977. — Б.71-141; Тукай Г. Әсәрләр. 6 томда: Т.3. — Казан: Татар. кит.нәшр., 1985. — Б.223, 245, 247; Т.4 — Казан: Татар.кит.нәшр., 1985. — Б.73, 91; Әгъзамов Ф. Тукай — журналист. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. — Б.31-32.

Гөлназ Хөснетдинова,
филология фәннәре кандидаты

Сәнгать

Җир һәм Күкләр сүзсез-өнсез генә
Бер-берсенә сеңеп, тартылып,
Бар моңнарын гүя үткәрәләр
Минем кайнар йөрәк аркылы!

Салисә Гәрәева

АЙДАР ХАФИЗГА 70 ЯШЬ

БЕЗ КАЙЧАНДЫР ЛӘЙЛӘ БЕЛӘН МӘҖНҮН ИДЕК...

ЛУАРА ШАКИРҖАН,
Татарстанның халык артисты,
Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрының музей мөдире

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК АРТИСТЫ АЙДАР ХАФИЗ 70 ЯШЬЛЕК ЮБИЛЕЕН БИК МАТУР, БӘХЕТЛЕ КЫРШЫЛЫЙ: ТОРМЫШ-КӨНКҮРЕШЕ ДӘ, ИҖАТЫ ДА, ТЫШКЫ КЫЯФӘТЕ ДӘ, МАТУРЛЫГЫН САКЛАГАН ХӘЛДӘ, МӘҺАБӘТ БУЛЫП ҮЗГӘРДЕ АНЫҢ.

Сөбханалла, киләчәге дә шулай булсын. Әтисенең туксан бишкә кадәр, әнисенең бер гасырдан артык яшәгәнен беләм, Айдарга да йөз яшь юрыйк. Дөресрәге, язның матур бер көнендә тулды инде аның җитмеше. Паспортында 20 май диелгән, әмма анда бераз хата китүенә Айдар шикләнми. 1943 ел. Сугыш афәтенең иң яман көннәре. Бала тугач та, көнендә «кәнсәләргә» барып яздырып кайту турында уйларга да җае юк. Әле барсаң да, кирәкле кәгазьләре юк. Әнисе әйтүе буенча, кар эреп, гөрләвекләр ага башлаган чак була ул. Ә авыл советы кенәгәсенә теркәлгән көндә инде алмагачлар шау чәчәктә утыра. Ни генә булмасын, Айдар авыр заманда, әмма ышанычлар, өметләр алып килә торган ямьле яз фасылында аваз сала дөньяга һәм, еллар үткәч, үзенең талантлы исеме белән туган җирен — Питрәч районының Күн авылын тарихка кертә.

Айдарның шәҗәрәсендә кайсыдыр бер әбисе я бабасы, һичшиксез, артист таланты белән тугандыр. Җырга, моңга, җор сүзгә бай булгандыр. Югыйсә, аның абыйларының балалары да, үзе дә мондый сәнгать җанлы булмаслар иде. Татарстанның халык артисткасы Раушания Юкачева да инде утыз елдан артык Камал театрында. Ул — Айдарның Хөснетдин исемле абыйсы кызы. Фарзетдин атлы абыйсының малае Фердинанд Хафизны тамашачылар театр һәм филармония аша, һәм дә үз җырларын башкаручы буларак беләдер.

Юбилярыбызның әти-әнисе Садретдин абзый белән Зөлкагъдә апа балаларына (ә алар сигез булган!), иманлы булсыннар дип юрап, чын милли исемнәр кушканнар. «Советтан» яшереп булса да, намазын, уразасын калдырмаганнар. Бәдретдин булырга тиешле төпчек малайның исемен исә заманча Айдар дип үзгәрткәннәр. Артистыбызның исемендә «дин» кушымчасы булмаса да, ул да инде хәзер биш вакыт намаз укучы, ураза тота торган динле кеше — Хаҗи абзый. Афәрин!

...Айдар, Айдар! Без яшьлектә синең белән Ләйлә, Мәҗнүн булып, берберебезне өзелеп сөйгән идек. Кияү белән кәләш булып, туй киемнәрен дә кигән идек. Ярый, бу турыда соңрак. Барысын да тәртип белән шәрехлик.

Казан театр училищесында безнең курска килеп кушылганда, инде ул күпне күргән, төзүче дә булган, солдатта да хезмәт иткән, гастрольләрдә йөргән, бөтен артистларны, җырчыларны белгән (хәтта Илһам Шакировның үзен!), театрда рольләр уйнаган Айдар Хафизов иде. Төз, мәһабәт буй-сынлы, чибәр йөзле, ачык, дөрес итеп сөйли торган, бик матур тавышлы Айдар — коеп куйган әзер артист иде инде. Әле, җитмәсә, оста итеп баянда уйный.

Безнең курс җитәкчеләре Камал театрының яңа баш режиссёры, таләпчән Марсель Сәлимҗанов һәм тамашачының мәхәббәтен казанган артист, режиссёр Рәфкать Бикчәнтәев иде. Башка остазларыбызны да телгә алып китим (рухлары шатлансын). Сәхнә хәрәкәте дигән дәресне мәшһүр Шәхсәнәм Әсфәндиярова укытты, сәхнә теленә Асия Хәйруллина өйрәтте. Алар барысы да Тукай бүләге лауреатлары иде инде, өчесе дә Мәскәү театр институтында белем алган. Соңрак безгә үзе галим, үзе шагыйрь-мәсәлче, тәрҗемәче, Ленинны да, Хуҗа Насретдинны да уйнаган Габдулла ага Шамуков (СССРның халык артисты) та дәресләр бирде. Олы остазлар иде! Кыскасы, мөгаллимнәребезне гомер буе рәхмәт белән, «без аларның шәкертләре идек», дип горурланып искә алабыз.

Әйе, без инде ел ярымлап укыган идек. Шулвакытта яңа егет килде. Яңа дигәнебез инде театр училищесының «иске» студенты икән. Ул атаклы Ширияздан ага Сарымсаковта ике ел укыган һәм армиягә алынган. Аның сабакташлары булган Наил Әюпов, Хәлим Җәләлов, Наил Шәйхетдинов инде сәхнәдә — рольләргә чумып иҗат итәләр! Студентлар арасында яшь аермасы тигезләнә: апа, абый дип дәшүләр юк. Бездән шактый өлкән Айдар абыебыз да шундук безнең «үзебезнекенә», яшьтәшкә әйләнде.

Ул туганда, әнисенә кырык өч тулган, әтисе алтынчы дистәне ваклаган, шуңа да сугышка алынмаган. «Авылда, өйдә уздырган Ватан сугышы чоры, ачлык, барыннан да авыррак булды, теңкәгә тигән хәлләр бик күп иде», — дип сөйли торган булган патша армияләрендә хезмәт иткән, Беренче Бөтендөнья сугышында катнашкан, революцияне, гражданнар сугышын үз җилкәсендә татыган карт солдат. Татбригада белән Урта Азия якларында совет власте урнаштырышып та йөргән. Бу тарихи сәхифәләрнең дәреслекләр буенча без белмәгән бик күп сәяси нечкәлекләрен соңгы елларында улына сөйләгән ул. Садри абзый заманында танылган каһарман Фрунзе белән дә еш күрешкән. Татарның Якуб Чанышевы белән якын көрәштәш, иптәш булган. Айдар әтисен данлыклы генерал белән очраштырырга өлгергән исән чакларында. XX гасырның ничә афәтеннән исән калуларына исләре китеп, күп истәлекләр актарган алар. «Гомер соңында әти сөйләгәннәр — алар бөтенләй башка тарих, осталыгым булса, китап язар идем», — ди Айдар.

Өлкән ата-анадан туганга да микән, Айдар кечкенәдән бик мөстәкыйль, акыллы малай була, йорт тирәсендәге һәр эштә атасының уң кулына әйләнә, хәтта ишек-тәрәзәләр дә ясый һәм балта остасы булырмын дип уйлый. Айдар кечкенәдән музыкальлеге белән дә аерылып торган. Гармунда уйнарга өйрәнә. Аулак өйләр, мәктәптә кичәләр, авылда концертлар ансыз узмаган. Ләкин аңа шушы юлдан китү насыйп булмаган. Әгәр дә ул бүгенге шәһәр шартларында үскән бала булса, үзенең мөмкинлекләрен әллә кайчан ачып, музыкаль конкурслар, фестивальләрдә катнашып, җиңү яулар иде!

Җидееллыкны тәмамлаган үсмернең 60-70 яшьлек әти-әни өстенә салынып яшисе килми — көтү көтәргә яллана.

Айдар 100 яшьлек әнисе белән. 2000 ел

Ниһаять, малай ямаулы киемнәрдән котыла, хромка гармун, хәтта велосипед сатып ала. Чын гармунчы егеткә әйләнә! Аннан, әти-әнисе янында армиядән кайткан абыйсын калдырып, Юдинода тимер юлчылар техникумында укый башлый. Ник дисәң, әлеге дә баягы, заманасы шул. Укырга, һөнәр сайларга ниятләгәндә, кайда стипендиясе, торыр урыны бар, шунда омтылган авыл баласы. Эчке хисләр, уй-хыяллар турында уйлап тору кайда?! Ә монда ашаталар, кием дә бирәләр икән. Техникумда укыганда да, гармунчы егет һәр чарага кирәк була, алыштыргысызга әйләнә. Хромкада гына түгел, оста итеп баянда уйнарга да шунда өйрәнә. Нәтиҗәдә, яңа ачылган мәдәният сараена студентны баянчы итеп эшкә дә алалар. Агитконцертларда башлап йөрүче була ул — әле, җитмәсә, оста сөйли дә, җырлый да, бии дә! Төзүчеләр бүлеген тәмамлап, һөнәр алып, Муромда эшли башлый.

Беркөн талант дигән чишмә, ниһаять, үз юлына бора, язмыш үзгәрә. Аны берничә генә концертта баянчы бул инде, дип үтенеп, үгетләп, кабат Юдиногa чакыралар. Шушы форсаттан файдаланып, ул инде сәхнәдә кала, урыны да, ризыгы да шул дөнья икәнен тәмам аңлап, карар кыла. 1961 елда озак тәнәфестән соң кабат ачылган театр училищесында укый башлый. Аннан — Польшада совет армиясе сафларында өч ел ярым хезмәт итү. Шунысы яхшы: Айдар биредә дә сәнгать өлкәсенә — бию ансамбленә эләгә, концертлар белән Европа илләренә дә аяк баса, дөнья күрә. Кайткач, Күчмә театрга артист булып эшкә керә, ник дисәң, яңадан театр училищесының беренче курсында йөрисе килми, укуын соңрак безнең белән дәвам итә.

Кап-кара кашлы, кара күзле «яңа» егеткә кызлар гашыйк була алмый калды. Җәйге ялдан килгәндә, безнең курста укыган, әле унсигезе дә тулмаган Фәридәбезнең инде бу егеткә кияүгә чыгып өлгергәнен белдек! Фәридә берничә ел элек үк Казанда яши башлаган, интернатта укыган һәм шәһәрчә матур киенеп йөри торган, инде егетләргә назлы карашлар ташлый белүче курчак кебек кызыбыз иде. Без, Казан буйлап фатир эзләп, кеше почмакларында торып интеккәннәр, имтиханнар бетүгә, ел буе сагынган әти-әниебез янына авылга «очтык». Фәридә бу вакытта Күчмә театр белән бер артистка урынына гастрольгә чыгып киткән һәм менә шунда инде ике яшь йөрәк табышкан, кавышкан! Күкләрдә үк никах укылган булган ахры аларга. Гомерләренең ләйсән яңгырлы ямьле язларын, күкләр күкрәткән, болытлы да, чәчәкле дә җәйләрен, мул көзләрен бергә каршы-

«Гаугалы гаилә» спектакленнән күренеш. Пеппино – А.Хафиз; Роза – Р.Мотыйгуллина. 1999 ел

«Моңлы бер җыр» спектакленнән күренеш. Ланфредини – А.Хафиз; Муса Җәлил – Р.Таҗетдинов. 1981 ел

«Ат карагы» спектакленнән күренеш. Листунов – А.Хафиз. 1989 ел

лады, бергә уздырды алар, инде менә ак кышларга таба да бергә атлыйлар. Фәриданең яшьлек мәхәббәте мәңгелек һәм тирән булды. Айдар да ярәтты аны, әлбәттә! Шушы изге хис саклады бу гаиләне. Ире кайда — хатыны шунда булды. Киңкырлы талантка ия артистка күп аралашырга, күп юллар кичәргә, сәнгатьнең төрле урыннарында эшләргә туры килде, халык театрларында да режиссёрлык итте. (Укыганда да тик тормады, институтларда театр түгәрәкләре җитәкләде — гаилә башлыгы бит, акча эшләде.) Филармониядә нәфис сүз сөйләүче булып та танылды, радиода да аның бәрхет тавышы еш яңгырады. Иренең уңышларында Фәриданең өлеше зур. Ул — уңган хатын гына түгел, Камал театрында озак еллар эшләгән тәҗрибәле режиссёр ярдәмчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Төрле кичәләрдә режиссёрлык иткән иренә дә беренче ярдәмче. Репетицияләрдә, спектакльләрдә, гастрольләрдә — бергә, кыскасы, театр бу гаилә өчен икенче өй кебек. Шундый шартларда алар ике кыз үстерделәр (өч оныклары бар). Ләйсән — финансист, Айсылу — журналист (хәзер Мәскәүдә, Россия телевидениесендә эшли).

Театр училищесында Айдар белән

диплом спектаклендә партнёрлар булган идек. А.Островскийның «Төшемле урын»ында ул өлкән яшьтәге бай Вышневский иде. Мин — көчләп кияүгә бирелгән яшь хатын. Габдулла абый ясаган репетицияләр, дәресләр һаман күз алдында. Әйткәнемчә, Айдар әзер артист иде инде. Укытучы өйрәткәнне генә көтеп тормый, үзе дә роль буенча күп нәрсәләр тәкъдим итә, безгә дә булыша иде. Гомумән, ул партнёр буларак сәхнәдә ярдәм итеп уйный белә. Бу бик мөһим сыйфат һәм ул артистның үзе турында гына түгел, гомум спектакль турында кайгыртуын да күрсәтә. М.Горькийның «Васса Железнова»сында Прохор иде. Роль өчен шундук гитарада уйнарга өйрәнде.

Укуны тәмамлагач, 5-6 елдан соң тагын партнёрлар булдык әле. Айдар Камал театрында калды. Мин — филармониядә. Аннан шул ук елны Ленинград театр институтына китеп бардым. Укып кайткач, Күчмә театрда янә бергә уйный башладык. (Аның Камал театрыннан китеп торган чагы иде.) Директорыбыз Сәет Шәкүров Айдарны Батулланың «Туйлар узгач» музыкаль комедиясенә төп рольгә чакыртты. Р.Бикчәнтәев куйган бу әсәр еллар буе сәхнәдән төшми барды. Рәфкать абый үзе дә уйнаган иде анда. Искиткеч матур, кызыклы спектакль иде. Бер бай гаиләнең иркә кызы Ләйлә (анысы мин) һәм ярлы артист Мәҗнүн мәхәббәте турында. Аңа кадәр минем Мәҗнүнем башка артист иде. Айдар шундук рольгә керде. Бу образга килеш-килбәте бик килеште. Спектакль тагын да баеп, җанланып китте.

«Ак тәүбә, кара тәүбә»дә (Т.Миңнуллин) ул — гармунчы Нәҗип, моңлы күңелле көтүче егет. Айдарның үзенә дә охшаган, ләкин ул аңа бөтенләй башка характер тапты: йомшак, юаш табигатьле, аю сыман иплəп кенә атлый, кызлар белән бик «борчагы пешми». Ышандырды! Бу спектакль белән дә бергә гастрольләрдә йөрдек.

Юлда йөргәндә, кеше күп як-



«Кылый Кирам балдагы» спектакленнән күренеш. Ир – А.Хафиз; Егет – Р.Бариев. 1996 ел

тан ачыла. Мин Айдарның нииндидер кимчелекләрен бер дә хәтерләмим. Буш вакытларда газета-китап күп укый, гармунында уйный, мөмкин булганда, кайдадыр елга буенда балык тота. Туры сүзле, гадел, яраклаша белми, тыңлата белә, һәрвакыт үз фикере бар, таләпчән, тәртип ярата, чын профессионал, кызып китәргә дә мөмкин, юмор хисе дә көчле. «Алай түгел, болай ул» спектаклен автор Т.Миңнуллин үзе куйды. Шушы спектакльне карарга килгән М.Сәлимҗанов Айдарны кабат үз театрына чакыра. 1978 елдан бирле 35 ел инде А.Хафиз Камал театрында. Барлыгы алтмыш роль уйнаган. Айдар сәхнәдә, төрле кыяфәтләргә кереп, төрле заман, төрле милләт кешеләрен тасвирлады. Уңай геройларны да, тискәре, усалларны да күп уйнады. Аңа ни кисә дә килешә — шәрык киемнәре чын шаһзадә, патша, хан яки вәзир ясый. Хәрбиләрне дә күп сурәтләде ул — төгәл хәрәкәтләр, баш югары, гәүдә төз. Кияү егетләре киеме дә сокландыргыч итә иде аны; йолкыш, алама киемле Дәрвише дә сәнгатьчә эшләнгән тулы

А.Хафиз, Т.Миңнуллин тәнәфес вакытында

образ булып истә калды («Ай тотылган төндә»). Шулай ук Җиһангир («Хуҗа Насретдин»), Ланфредини («Моңлы бер җыр»), Ир («Кылый Кирам балдагы»), Пеппино («Гаугалы гаилә»), Нургали («Шулай булды шул»), Гайни бай («Курчак туе»), Алтын хан («Хан кызы Турандык»), Зәйнулла («Арбалы хатыннар») һ.б. — аны төрле яктан ачкан рольләр.

«Мин язган пьесада Айдарга роль бирсәләр, аның теләсә кайсы рольне менә дигән итеп уйнаячагына аз гына да шикләнмим. Айдар күп уйнады, шәп уйнады, тик үз талантына тиң рольне уйнамады әле, көчле рухлы, акыллы, әүкатьле, дөнья үзәгендә торучы гадел татар абзыен Айдар өчен махсус язарга кирәк», — дигән иде моннан егерме ел элек Айдарның 50 яшенә багышланган мәкаләсендә Туфан абый. Әйе, Айдар данлыклы драматургның уннан артык әсәрендә уйнады. «Үзебез сайлаган язмыш»ны Камал театры сәхнәсендә куйды да. «Ходай Тәгалә бу дөньяга аны артист итеп яраткан; артистлык Айдарның йөрәгендә ята; төс-кыяфәтендә олпатлык, вәкарьлек, затлылык бергә кушылган; ул сәхнәдән сөйләгәндә, колакка рәхәт; аның сәхнәдә ышандыру сәләте шундый көчле; елмайса, дөнья яктырып киткәндәй була, акаеп караса, куркудан җиргә сеңәсең, валлаһи; ул иҗат кешеләрендә булырга тиешле интуициягә бай». Болар да Туфан абый фикерләре. Театр белгече Д.Гыймранова исә аның уйнау манерасын Г.Кариев, З.Солтанов, К.Тинчурин, Ш.Шамильский кебек күренекле артистларыбыздан килгән үзенчәлекле реалистик сәхнә мәктәбенең матур дәвамы итеп күрә. «Тарихи һәм милли характер сыйфатларын табигый итеп, ачык төстә сурәтли. Ул иҗат иткән образларның рухи дөньясы бай. Логик эзлеклелек, тормыш дөреслеген табу — Айдарның уенына хас төп сыйфатлар», — ди. Бу нәкъ шулай, дип кенә өсти алам.

Әле тагын артист талантының, аның иҗат биографиясенең республика мәдәни тормышы өчен дә мөһим булган, бик уңдырышлы бер ягына тукталыйм. Мәшһүр әдәбият-сәнгать әһелләренең түгәрәк даталарына багышланган гаять күп кичәләрнең режиссёры булып танылды Айдар. Камал театры артистларының юбилейларын гына түгел, Н.Исәнбәт, С.Сәйдәшев, Һ.Такташ, Х.Туфан, Ә.Еники, С.Хәким, М.Хәбибуллин, Р.Харис, А.Хәлим һ.б. кичәләре... Бу исемлек озын. Күптән түгел Р.Фәйзуллинның М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында узган юбилей тантанасының да режиссёры, «Пар канатлар» исемле кичәне даими сәхнәләштерүче, «Казан утлары» журналының да, Татарстан радиосы юбилеен да куючы. Әлеге чараларда аның белән еш эшләгәнгә, шуны әйтим: ул беркайчан да әзер сценарий белән генә чикләнми, аны баета, кирәкмәсен кыскарта. Авторга, үзе белгән бай материалдан чыгып, өстәмәләр керттерә. Таләпчән режиссёр артистларның, бигрәк тә яшьләрнең шигырь укуын дөресләргә дә өлгерә. Беравык ул, булачак артистларга актёрлык осталыгы

Гаиләсе белән. Болгария, Варна шәһәре. 2013 ел

дәресләре биреп, мөгаллимлек тә иткән иде. Жәл, никтер даими алынмады бу эшкә. Вакыт җитмәгәндер. «Яшьләр язмышына бик җаваплы карарга кирәк. Алар өчен тырышып, мин ун сәгать урынына егерме сәгать эшлим», — дигән иде бер.

Кемдер: «Чын остазның көче өйрәтүендә түгел, аннан өйрәнүләрендә», — дигән. Айдар: «Минем бит махсус белемем юк, мин Ш.Сарымсаков, Г.Юсупов, П.Исәнбәт, М.Сәлимҗанов, аталы-уллы Бикчәнтәевләр кебек шәп режиссёрларны карап кына сабак алдым», — дисә дә, ул инде профессиональ режиссёр. Тагын бер мисал. Күренекле татар шагыйре, фәйләсуф Мөхәммәдьярның 500 еллыгы (1997) уңаеннан үткәрелгән кичә камил бер спектакль иде (Ф.Яхин поэмасы буенча). А.Хафиз анда үзе режиссёр, үзе үк шагыйрьне уйнады — Туфан абый күрергә теләгән акыллы, көчле рухлы татар образын тудырды. Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә күрсәтелгәнгә, милли һәм сәяси бу вакыйганың әһәмияте дә, җаваплылыгы да югары дәрәҗәне сорый иде һәм ул шундый бәя алды да — Айдарның оста режиссёр, оештыручы, тарихны да белүче һәм, әлбәттә, зур артист икәнен янә исбатлады.

Сәхнәдәге образның бай рухлы булуы артистның үз күңел байлыгына бәйле. Айдарның асылы нык, эчке дөньясында мәгънә мул, кыйбласы туры. Быел җәйге ял вакытында ул гаҗәеп гыйбрәтле, изге гамәл кылды. Абыйларының улларын ияртеп, Смоленск якларына китте. Нияте — унтугыз яшендә сугыш кырында гомере өзелгән, әти-әнисенең мәңгелек йөрәк ярасына әйләнгән иң олы абыйлары Нуретдин яткан җирне, каберен табу. Һәлак булуы, җирләнгән урыны хәбәр ителгән «кара хат»ны укып-өйрәнеп, интернеттан карап, юлга чыгалар. Һәм!!! Аллаһ ярдәм иткәндер! Йөзләгән, хәтта меңләгән исемнәр язылган күпме туганнар каберлеген карап йөри торгач, табалар алар «Хафизов Нуретдин» дигән язуны... Бу тәэсирләр турында язып я сөйләп аңлату мөмкинмени... Яңгыр сибәләп торган тып-тын һавада, Айдар укыган ясин тавышлары да тынгач, каяндыр очып килеп чыккан карлыгач, җиңнәренә бәреләбәрелә, Айдар тирәсендә бөтереләбашлый... Моны да аңлатып булмый...

Тагын бер кат афәрин сиңа, сабакташым! Синең тууың, булуың, яшәвең юкка түгел! ■

ЯҢА КИТАПЛАР



ТҮРКІЛІК ТӘРБИЕ. АНТОЛОГИЯ. TURKIC UPBRINGING. ANTHOLOGY. –
Алматы, 2013. – 1004 б.
(Казах, азәрбайҗан, кыргыз, татар, төрек, үзбәк һәм инглиз телләрендә).

Казахстан башкаласы Астанада 2010 елда гына эшли башлаган Төрки академия кыска гына вакыт эчендә күптөрле китаплар бастырып чыгарды. Шуларның берсе – «Төрки тәрбия» («Түркілік тәрбие»), зур форматлы (25х30 см), каты тышлы, рәсем-иллюстрацияләргә гаять бай, полиграфия техникасының соңгы казанышларын файдаланып нәшер ителгән 1000 битлек бу антология – тугандаш төрки кавемнәр, җөмһүриятләр, галимнәр хезмәттәшлегенең, уртак проектны бергәләп гамәлгә ашыруның бик тә күркәм бер үрнәге. Ул 2013 елның августында төрки дәүләт башлыкларының Азәрбайҗанда үткәрелгән Саммитында да югары бәя алды.

Җыентыкта казах, азәрбайҗан, кыргыз, татар, төрек, үзбәк кавемнәренә, ягъни алты төрки халыкка хас тәрбияви система, чаралар яктыртыла. Бишек тәрбиясе, белем бирү, ватанпәрвәрлек, әдәп-әхлак, акыл, дини, эстетик, экологик, физик һәм тәрбиянең кайбер башка төрләре карала. Фольклордан, язма әдәбияттан, төрле чыганаклардан аларга туры килешле текстлар китерелә. Мисаллар оригиналда алына, латинча графикага күчерелә, кайберләре тәрҗемә дә ителә. Гомуми кереш, бүлек һәм бүлекчә башларындагы белешмәләр казахча һәм инглизчә бирелгән.

Антологиядә төрки дөньяның күренекле вәкилләре, аларның тәрбиягә мөнәсәбәтле фикерләре, әсәрләре дә гәүдәләнеш тапкан.

Җыентык татар материалларына да зур урын биргән. Анда, темага туры китереп, татар фольклорыннан, язма әдәбиятыннан күпсанлы, төрледәнтөрле мисаллар китерелә. Болар арасында «Идегәй», «Камыр батыр», «Гыйса углы Әмәт» кебек дастаннар да, С.Сараи, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, К.Насыйри, Р.Фәхреддин, Р.Зәйдулла әсәрләреннән өзекләр дә, Г.Исхакыйның «Кәҗүл читеге» дә бар. Аеруча М.Гафури һәм Г.Тукай иҗатыннан мисаллар күп. Бу ике шагыйрь һәм Г.Ибраһимов төрки дөньяның күренекле затлары исемлегенә дә кертелгән. Аларның тәрбиягә кагылышлы күпләгән шигырьләре һәм Г.Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясе дә укучыларга тәкъдим ителә.

Альманах өчен татар текстлары, материаллары профессор Хатыйп Миңнегулов тарафыннан әзерләнгән. Аның җыентыктагы татар тәрбия системасын яктырткан мәкаләсе «Әбибабаларыбызның гыйбрәтле сабаклары» исеме астында «Чын мирас» журналының 2013 елгы 8 нче санында да басылып чыкты (95-105 битләр).

Бу китап аерым төрки халыкларга хас милли тәрбия тәҗрибәсен күзалларга, төркиләр өчен уртак, охшаш тәрбияви чараларны ачыкларга, аларны гамәлдә кулланырга да ярдәм итәчәк.

Хатыйп Миңнегулов,
филология фәннәре докторы, профессор

Бронза йозак. Идел Болгарстаны.
XII гасыр — XIII йөз башы

Индекс 54132
70275



Халкыбыз тарихы, әдәби, мәдәни мирасыбыз, тәнкыйди фикер һәм заманча караш – барысы да «ЧЫН МИРАС» журналында

ИНДЕКС

ТАТАРСТАНДА – 54132

ЧИТ ТӨБӘКЛӘРДӘ – 70275

БЕЗ МИРАСЛЫ ХАЛЫК. «ЧЫН МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!